ҖИР СУЛЫШЫ

Соңгы арада күзәтелгән экологик үзгәрешләрнең сәбәпләрен барладык

> 7

МЫЛТЫКСЫЗ ХЕЗМӘТ

Ватан алдындагы бурычны тагын ничек кайтарырга?

> 15

ФИРАЯ ӘКБӘРОВА:

«Театр ул – бик көнчел бала»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 77 (28850) | Җомга | 3 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

tatarstan.ru

МӘХӘББӘТЛЕ ГОМЕР

ТАТАРСТАНДА ТӘҮГЕ МӘРТӘБӘ «АТА-АНА ФИДАКАРЬЛЕГЕ» МЕДАЛЕ ТАПШЫРЫЛДЫ

Мәхәббәт, сабырлык, тәрбия, бәхет үрнәге. Шушы көннәрдә Казан Кремлендә әнә шундый төшенчәләрне тормыш мәгънәсе иткән гаиләләр кунак булды. Республиканың күпбалалы биш гаиләсенә «Ата-ана фидакарьлеге» медале тапшырылды. Шунысын да әйтергә кирәк: бу дәүләт бүләге тәүге тапкыр тапшырыла. Үрнәк парлар аны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кулыннан алды. Гаиләләрнең һәркайсы да бүләкне дулкынлану, әмма берничә масаюсыз кабул итте. «Бер без генә түгел, республикабызда андый үрнәк гаиләләр күп», – диләр. Әмма, билгеле, күпләр арасыннан аларны сайлап алуларына шатлануларын да яшермәделәр.

> 5

Ишетми калмагыз

Татарстанда социаль ипотека программасы буенча торак лы булган гаиләләр ел башыннан бирле балалары өчен 205,6 миллион сумлык субсидия алган инде. Бу хакта Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды матбугат хезмәте хәбәр итә. Бала туганда түләнелә торган акча күләме 200 мең сум тәшкил итә. Гыйнвар аеннан бирле 1035 гаиләгә субсидия юлланган.

Субсидия торак алу буенча исәпкә куелганнан соң туган яки уллыкка (кызлыкка) алынган һәр бала өчен түләнелә. Акчаны беренчел взнос итеп кертергә яки социаль ипотеканың бер өлешен каплау өчен тотарга мөмкин. Аны алу өчен баланы социаль ипотека килешүенә кертергә кирәк.

ДРКБның Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургиясе үзәгендә сөяк җелеге күзәнәкләрен күчереп утырту буенча операцияләр ясый башлаячаклар. Бу хакта ДРКБ баш табибы Айрат Зиатдинов белдергән. Аның әйтүенчә, мондый операцияләргә быел көздән тотыну планлаштырыла. Сырхаулар инде сайлап алынган, аларны планлы операциягә әзерлиләр. Табиблар, үз чиратында, белемнәрен чарлап, хәзерге вакытта илнең төп клиникаларында практика уза.

Мондый сырхаулар өчен махсус микроклиматлы 7 палата әзерләп куелган.

Россиядә үлем җәзасын кире кайтару көн тәртибендә тормый һәм, гомумән, әлеге мәсьәлә каралмый. Россия Президенты матбугат секретаре Дмитрий Песков шулай дип белдергән. «Кремльдә бу җәһәттән берничә фикер үзгәрмәде. Гомумән, әлеге мәсьәләне карамыйбыз», – дигән Песков, үлем җәзасын кире кайтару ихтималына кагылышлы сорауга җавап биреп.

Быел Татарстанда яңа 3 балалар бакчасын ачу күздә тотыла. Мәгариф һәм фән министры урынбасары – Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты башлыгы Рәмис Мөҗипов туры эфирда белдергәнчә, соңгы өч елда 60ка якын яңа бакча төзелгән. 2019 елда – 30, 2020 елда – 28 (5 мең урынга – шуның яртысы ясле төркемнәре өчен). Узган елда исә 3 мең урынга 17 бакча (шул исәптән 1,2 мең урын – ясле төркемнәре өчен) ачылган. Инде быел яңа уку елына Казанның 59 нчы кварталында, Буа һәм Түбән Кама районнарында балалар бакчалары сабыйларны тәүге тапкыр кабул итәчәк.

Министр урынбасары сүзләренә караганда, соңгы 3 ел эчендә мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен 14 меңнән артыграк урын булдырылган. Республикада төрле профильдәге 2 меңгә якын балалар бакчасы эшләп килә. Аларга 215 меңнән артыграк сабый йөри. Бакчалар 50–300 урынга исәпләнгән.

Районнарда ни хәлләр?

Мөслим

«Мәгариф объектларына – капиталь ремонт» программасы буенча Салауз-Мухан төп гомуми белем бирү мәктәбендә ремонт бара. Программа ярдәмендә мәктәпнең керү өлешен эшләү, тәрәзә-ишекләр алыштыру, ашханә өлешен төзекләндерү планлаштырыла. Мәктәп ашханәсенә яңа җиһазлар да алыначак. Ремонт чыгымнарын республика бюджеты күтәрә, финанслау күләме 28 млн сум тәшкил итә. «1989 елның 4 ноябрендә беренче тапкыр укучылар кабул иткән мәктәпкә ремонт бик кирәк иде. Класс бүлмәләрендә тәрәзәләрне ачу түгел, тузанын сөртергә дә курка идек. Тәрәзәләрнең рамнары череп беткән иде», – ди мәктәп директоры Динар Мәгалимов. Салауз-Мухан авылында мәктәп яшендәге – 22, мәктәпкәчә яшьтәге 14 бала яши.
(«Мөслим-информ»)

Әлмәт

Майның соңгы көнендә Әлмәт ЗАГСында игезәк балаларга туу турында таныклыклар тапшырылды. Ел башыннан бирле дөньяга тәүге аваз салган сигезенче пар игезәк инде бу. Нәни кызчыклар 27 май көнне Олеся һәм Александр Беженцевлар гаиләсендә беренче һәм икенче бала булып дөньяга килгән. Нарасыйларга Дарья һәм Арина дигән исем кушканнар.
(«Знамя труда»)

Апас

Апас мәчетендә оештырылган матур язу сыйныфының тәүге чыгарылышы булды. Каллиграфия сыйныфы биредә моннан ярты ел элегрәк булдырылган иде. Җиде яшьтән зуррак балалар һәр якшәмбе саен мәчеткә матур язу серләренә өйрәнергә йөрде. Аларга өлкәннәр дә кушылды. Шулай итеп, балалар кыска гына вакыт эчендә ак кәгазьгә хәрефләр төшереп һәм аларны рәсемнәр белән тулыландырып, матур язарга өйрәнде. Үзешчән рәссамнар – Каратуннан Илгиз Маликов һәм район үзәгендә яшәүче Суфия Сәлахова балаларны сынлы сәнгатькә җәлеп итүгә үзләреннән зур өлеш кертеп килә. Укучылар, рәсем ясау белән беррәттән, гарәп язуын, ислам дине тарихын да өйрәнә.
(«Йолдыз»)

Түбән Кама

Март аенда Украинада махсус хәрби операция барышында һәлак булган лейтенант Александр Михайлович Осиповның Батырлык орденын аның хатыны Полина Осиповага һәм әнисе Галина Купцовага тапшырдылар. «Солдат әнисенә зур рәхмәт әйтәсем килә: улыгыз белән горурлана аласыз. Сез чын кеше, герой тәрбияләгәнсез. Аның исеме Бөек Ватан сугышы геройлары исемнәре белән һәрвакыт бергә булачак», – диде район башкарма комитеты җитәкчесе Рамил Муллин. Александр Осипов 2015 елда Идел буе федераль округының Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллин исемендәге Татарстан кадетлар корпусын һәм Рязань югары һава-десант команда училищесын бик яхшы билгеләренә тәмамлаган. Спецназ төркеме командиры була.
(e-nkama.ru)

ТӘТЕШТӘ БЕР КӨН

Сез биредә алган белем белән горурланачаксыз! Россия Иминлек советы секретаре Николай Патрушев Тәтеш кадет-интернат мәктәбендә укучылар белән очрашуда шулай дип белдерде. Районны Патрушев Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров белән бергә карап кайтты. Алар Тәтештә механика заводы эшчәнлеге белән дә танышты, Бакырчы авылында да булды.

tatarstan.ru

Кадет-интернат мәктәбендә бүген 129 бала белем ала. Шуларның 18е – кызлар. Биредә Тәтеш кенә түгел, күрше-тирә районнар, Казан, Санкт-Петербург, Ульян, Чувашия, Мари Иленнән килгән балалар укый. Рөстәм Миңнеханов республикада кадет хәрәкәте үсешенә зур игътибар бирелүен искәртте. «Чыгарылыш сыйныф укучыларының төп өлеше киләчәктә югары хәрби уку йортларын сайлый. Бу биредә системалы эш оештырылуын күрсәтә», – диде Рөстәм Миңнеханов. Россия Иминлек советы секретаре Николай Патрушев кадетлар өчен тудырылган шартларны югары бәяләде. «Сез монда алган белем белән горурланачаксыз. Укытучылар сезгә белем бирде, ләкин киләчәк үзегездән тора. Һәркем үз-үзеңне әзерләү, тәрбияләү белән шөгыльләнергә тиеш. Шул чакта сез үз алдыгызга куелган барлык максатларга ирешәчәксез», – диде ул.

Тәтештә кунаклар Казан вертолет заводының районда урнашкан механика заводында да булдылар. Биредә вертолетлар өчен комплектлау детальләре җитештерелә. Завод директоры Сергей Федотов сүзләренә караганда, соңгы биш елда җитештерү күләме 4 тапкыр арткан. 2008 елда заводта яңа корпус төзелгән. Җитештерелә торган продукция күләме артуда биредә кулланылган заманча технология, станокларның да өлеше зур, ди Федотов. Бүген заводта 130 кеше эшли.

Николай Патрушев, Рөстәм Миңнеханов һәм Игорь Комаров Бакырчы авылында да барып күрде. Биредә алар заманча спорт залын һәм универсаль мәйданчыкны карады. Ул иганәчеләр ярдәмендә төзелгән. Спорт комплексында көрәш белән шөгыльләнү өчен тренажер залы урнаштырылган. Спорт мәйданчыгында волейбол, футбол, баскетбол уеннары өчен шартлар тудырылган, шулай ук кардио һәм көч тренажерлары булачак.

Кунаклар җирле мәдәният йортында Бакырчы авылы тарихы музее белән дә таныштылар. Аннары Николай Патрушев, Рөстәм Миңнеханов һәм Игорь Комаров Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган сугышчылар һәйкәленә чәчәкләр салдылар.

Дару бетмәячәк

Татарстанда ел ахырына кадәр җитәрлек күләмдә дару запасы бар. Хәзерге вакытта белгечләр киләсе елга дару әзерли башлаган.

Һәрхәлдә, «Таттехмедфарм» оешмасы генераль директоры Олег Акберов шулай дип ышандыра. Йөз кат ишеткәнче, бер кат күр дигәндәй, бу көннәрдә Россия Дәүләт Думасы депутатлары Максим Топилин белән Айрат Фәррахов җитәкчелегендәге бер төркем депутат, оешмага килеп, республиканың дарулар белән ни дәрәҗәдә тәэмин ителгәнлеге белән танышып китте.

– Чикләүләр дарулар белән медицина эшләнмәләренә кагылмады. Бер генә чит ил оешмасы да Россия базарыннан китмәде. «Таттехмедфарм» чыгарган дарулар исә үзебездәге чималдан җитештерелә, – ди Олег Акберов. – Дәвалау оешмаларын дару белән тулысынча тәэмин иттек. Алар Казанда, Чаллыда, лицензиягә ия булган өстәмә складларда саклана. Быелга план тулды.

Җитәкче сүзләренең хаклыгына депутатлар үз күзләре белән инана алды. «Таттехмедфарм» оешмасы буйлап уздырылган экскурсия барышында депутатлар даруларның кайда, ни рәвешле саклануы, маркалаштырылуы, дәвалау оешмалары белән даруханәләргә нинди машинада озатылуын да күзәтте. «Даруларның җитәрлек икәнлегенә тагын бер кат инандык. Нинди генә хәл килеп чыкса да, запас дару һәрчак булырга тиеш», – диде Айрат Фәррахов журналистлар белән аралашканда.

Максим Топилин исә республикада бу эшнең җентекле рәвештә оештырылуына игътибар итте. «Татарстанда дарулар алдан әзерләнә. Дәүләт Думасына керткән закон проектында да без нәкъ менә шушы системаны саклап калырга тәкъдим итәбез. Ул бар эшне алдан башкаруны күздә тота. Юкса эшнең гел соңгы минутта башкарылуына зарланабыз», – ди Максим Топилин.

Билгеле булганча, узган ел депутатлар Максим Топилин белән Айрат Фәррахов Дәүләт Думасына җитештерүче, ягъни даруны сатып кына калмыйча, аларны үзе үк җитештерүче даруханәләргә кире кайтару турында закон проекты тәкъдим иткән иде. Былелның мартында аның беренче укылышы узды.

– Дарулар белән тәэмин итүнең мондый системасы илнең 10–12 төбәгендә гамәлдә. Бу даруларның хакына да, сыйфатына да йогынты ясый. Бу система федераль канун ярдәмендә яңартылырга тиеш. Без аның саклануын телибез һәм шул юнәлештә эшлибез дә, – диде Айрат Фәррахов.

ӨЙДӘН ЧЫГЫП ТОРАСЫ ЮК

Россия халкы тагын җиде төрле хезмәттән онлайн рәвештә файдалана алачак. Шул рәвешле Дәүләт хезмәтләре порталында яңа бүлекләр пәйда булачак. Бу хакта карарны Россия Хөкүмәте Михаил Мишустин имзалаган.

Шул рәвешле якын киләчәктә әлеге портал аша нотариуска да язылып булачак. Бу хезмәт үзе ике төргә бүленә. Беренче бүлек аша нотариуска васыятьнамә, мирас, милек мәсьәләләре буенча йомышы төшкән кешеләр языла ала. Башка сораулар буенча нотариуска икенче төймәгә басып язылырга булачак. Моннан тыш, Дәүләт хезмәтләре порталы ярдәмендә кредит тарихлары бюросыннан белешмә дә алырга мөмкин булачак. Яңа хезмәтләрнең бер ише эшмәкәрләргә кагыла. Аерым алганда, алар аудитор оешмалары, инвестиция мәйданнары реестры кебек чыганаклардан үзенә кирәкле мәгълүматны онлайн рәвештә алачак.

«Яңа хезмәтләр порталда тәүлек әйләнәсе эшләячәк. 2023 ел азагына бик күп дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне тәүлек әйләнәсе электрон рәвештә алып булачак», – диелә Россия Хөкүмәтенең матбугат хезмәте хәбәрендә.

БУ – ЯРАТУ БӘЙРӘМЕ

1 июнь – Халыкара балаларны яклау көнендә Татарстанда яшәүче күп бала үстерүче 260 гаиләне Казан циркына җыйдылар. Тамашаны алар бушлай карады. Республика күләмендә узучы «Ел хәйриячесе» бәйгесендә җиңүче игелек иясе бәйрәм көненә сабыйларны шулай сөендерде. Сер түгел, хәйриячеләр болай да күп бала үстерүче, тәрбиягә бала алган, имин булмаган гаиләләрдә үсүче сабыйларга һәрдаим ярдәм итеп тора. Ә бу чара сабыйлар күңелендә озак саклаңыр, мөгаен.

Цирк тамашасы башланганчы, аларны Татарстан Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева бәйрәм белән котлады.

– Балаларны яклау бәйрәме иң матурыдыр, – диде ул. – Без, өлкәннәр, алар каршында җаваплы. Без аларны саклап, яклап торырга тиеш. Бәйрәм уңаеннан республикада төрле чаралар уза. Парк-скверлар балаларның шат тавышыннан гөрләп тора. Аларның сәламәтлеге хакында сөйләшәбез. Иң алдынгыларга премияләр дә бирелә. Кыскасы, балалар һәрчак игътибар үзәгендә.

Ләйлә Фазлыева бу бәйрәмне ярату бәйрәме дип тә атады. Аның фикеренчә, ана белән бала яратуы әллә нинди могҗизалар тудырырга сәләтле. Дөрестән дә шулай. Залда утыручы өч бала анисе – Тәтештән килгән Ирина ханым да, яратмасаң, күп бала алып кайтмыйсың, ди.

– Өч баламны да бик яратам. Алар өчен борчылып яшим. Шөкер, дәүләт безнең кебекләргә һәрчак ярдәм итеп тора. Авыр яшибез, дип әйтә алмыйм. Сабыйларым да яратканны аңлый. Инде хәзердән рәхмәтле була беләләр, – ди ул. – Минем балаларымның яшь аермалары бик якын. Кечесенә – 2, олысына 6 яшь кенә әле. Әмма аларга карап, туганлыкның көчен, бер-берләрен яратуларын сизәм. Сабыйларны картлык көнебезгә терәк булсын дип үстерәбез. Игелекләрен күрсәк иде.

Залда кемнәр генә юк. Күкрәк сабыйларын алып килгән әниләр дә, өчәр бала иярткән әтиләр дә бар. Ни гаҗәп, ник бер тавыш ишетелсен. Сабыйлар йотлыгып тамаша карый. Аларның күзләре, йөзләре елмая. Шатлыктан нишләргә белмиләр. Моннан 8 ел элек Кыргызстаннан Казанга күченеп килгән Кузбәковлар гаиләсе өчен бу беренче шундый тамаша.

«Татар-информ» / Рамил Гали

– Казанга күченүебезгә сөенеп бетә алмыйбыз. Рәхәт шәһәр. Балалар үстерү өчен бөтен шартлар бар. Иң мөһиме – безнең кебек гаиләләрне гел яклап, саклап торалар, – ди Данияр Кузбәков. – Хатыным белән 5 бала үстерәбез. Иң олысына – 13, кечесенә 3 яшь тулды. Шалтыратып, монда чакыргач, иң матур киемнәрен киделәр. Ул-кызларым тамашаны шулкадәр яратты. Үзебез дә балачакка кайткандай булдык.

Тамашачылар арасында имин булмаган гаиләләрдә яшәүче сабыйлар да бар иде. Казанда яшәүче Гөлнара ханым ялгызы гына өч бала үстерә икән.

– Тормышта төрле чаклар булды. Әмма балаларым миңа яшәргә көч бирде. Хәзер мин һәр туган таңга рәхмәтлемен. Иң мөһиме – сабыйларым минем янда, – ди ул.

Циркка килгән гаиләләргә Татарстан Президенты исеменнән конкүреш җиһазлары алу өчен сертификат та таратылды.

ҮЗЕБЕЗДӘН БАШЛЫЙК

«Ата-аналар җыелышы» онлайн проектының иминлек культурасына багышланган эфиры шундый нәтиҗә белән тәгәлләнде. Катнашучылар, ай саен очрашып, балаларга бәйле актуаль сорау һәм проблемаларга җавап эзләячәкбез, дип сүз куешты.

Мондый фикер алышуларны оештыру идеясен Татарстанның ата-аналар берләшмәсе тәкъдим иткән. Бала – безнеке, акылы – үзенеке, дигән бит халык. Әти-әниләргә кайбер мәсьәләләрне хәл итүдә ярдәм кирәк. Белем бирү системасында эшләүчеләргә дә файдасы тими калмас. Шул җәһәттән «Ата-аналар җыелышы» һәркем өчен уңайлы форматта – туры эфир рәвешендә уза. Теләгән һәр кеше үз соравын юллый ала.

Әйткәнебезчә, 1 июнь – Халыкара балаларны яклау көнендә узган очрашу иминлек, балалар арасындагы низаглар, буллинг (балаларның мәктәптә һәм интернет челтәрендә эзәрлекләнүе) кебек мәсьәләләргә багышланган иде.

Экспертлар балаларга һәм үсмерләргә психологик ярдәм күрсәтү, шулай ук буллингка каршы көрәш ысуллары турында фикер алыштылар. Балалар үз борчулары турында сөйләсен өчен алар белән уртак тел табу мөһим. Республиканың яшьләр эшләре буенча министр урынбасары Алла Кондратьева фикеренчә, баланың мәктәптәге психолог булмәсенең кайда урнашуын һәм ышаныч телефонын белүе дә – мөһим нәрсәләр.

Мәгариф министрының беренче урынбасары Андрей Поминов исә, баланың белем бирү оешмасы эчендә һәм виртуаль киңлектә үз-үзен тотышына да игътибарны көчәйтү зарур, дигән фикердә. «Татарстанда игълан ителгән цифрлаштыру елы кысасында мәктәпләрдә «Цифрлы дәресләр» уза, анда балалар һәм мәктәп укучыларының интернеттагы куркынычсызлыгы, шулай ук буллинг, төрле чатларда, берләшмәләрдә үзара мөнәсәбәтләр һәм финанс грамоталылыгы мәсьәләләре турында сөйләшәләр», – дип аңлатты Поминов.

Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева сүзләренчә, балаларга иң зур йогынты ясаучылар – өлкәннәр. «Балаларыбызның иминлек культурасы турыдантуры безгә – әти-әниләргә, укытучыларга, алар тирәсендәге кешеләргә бәйле. Балаларны контрольдә тотарга тиешбез икән, без, һичшиксез, үзебездән башларга тиеш. Алар белән вакыт уздырабызмы, ягымлы сүзләр әйтәбезме, бер кәефтәме без – барысы да бик мөһим», – диде ул, очрашуны йомгаклап.

Айдар ШӘЙХИН

ХАЛЫКАРА һӘМ БАШКАЛАР

Милләтара, халыкара, динара кебек сүзләрнең дөрес язылышына карата мөхтәрәм академик Рузәл Юсуповның үзгә фикере булса да, гамәлдәге орфография кагыйдәләренә буйсынырга мәҗбүрбез. Ә гамәлдәге кагыйдәләр бу мәсьәләдә катгый тора: барлык сүзлекләрдә дә норматив вариант буларак милләтара, халыкара, динара, төбәкара, районара һ.б. язылышлар күрсәтелгән. Милләт-ара яки милләт ара дип язылмый.

Монда бәхәсләр барыбер кала. Мәсәлән, халыкара сүзенең кабул ителгән язылышы телдәге башка кагыйдәнә боза: халык+ара кушылмасы саңгырау тартыкның яңгырау тартыкка әверелүенә китерә, язуда бу халыгара дип бирелергә тиеш. Әмма 1940 нчы еллардан ук килгән язу традициясенә таянып, халыкара, төбәкара кебек вариантны сакларга тәкъдим ителә. Һәрхәлдә, орфографик сүзлекләр яңартылганчы, рәсми матбугат һәм рәсми эш кәгазьләрен язучылар стандартны сакларга бурычлы.

Шул ук вакытта мондый сүзләр белән чамадан тыш мавыгу да урынлы түгел. Әйе, халыкара мөнәсәбәтләр дип сөйләшергә күнегелде. Әмма диннәр арасындагы мөнәсәбәт, диннәр арасында татулык дигән матур тезмәләр дә уйлап табып була. Между сүзе ара, арасында, арада, ике арада, арасындагы дип тәрҗемә ителә. Бу синонимнарны мәгънәсе дөрес туры килерлек итеп кулланырга тәкъдим итәм.

Күпсанлы, күбурынлы кебек сүзләр белән дә шул ук хәл. Кызганыч, бу очракта орфография сүзлекләре һәм башка сүзлек авторлары белән килешәсе килми (сүз уңаеннан, 1940 елда кириллицада чыккан беренче сүзлекләрдә күп сүзе кергән сүзләр аерым язылган). Күп санлы, күп урынлы, күп фатирлы дип язу дөресрәк һәм мәгънәлерәк булыр иде. Ләкин сүзлек ул – Конституция. Димәк, күп сүзе кергән кушма сүзләрне дә кушып язарга мәҗбүрбез: күпфатирлы, күпсанлы, күпкүзәнәкле, күпкыйммәтле һ.б.

КИРЕДӘН / ЯҢАДАН

Кайбер якларда яңадан сүзе урынына киредән сүзе активрак кулланыла. Чыннан да, бу сүз яңадан, яңабаштан мәгънәсендә килә. Хәлбуки, заново родился тезмәсен татарчага тәрҗемә итеп, киредән тудым дип әйтү сәеррәк тоела. Иркә җырындагыча «яңадан тудым» дип язу хәерлерәк булыр. Кире сүзенең төгәл билгеләнгән тискәре мәгънәсе дә, яңадан кайтып башкару мәгънәсе дә бар. Әмма беренчел тискәре төсмере аркасындамы, ул икенче мәгънәсендә кулланылган чакта да урынсыз яңгырый.

ЯПОН БАСКАКЛАРЫ

Бер газетада «Япон баскакларына каршы көрәшкән» дигән җөмлә очрады. Икенче Бөтендөнья сугышының ахыргы этапы, милитарист Япониягә каршы барган сугыш хәрәкәтләренә карата кулланылган гыйбарә бу. Җөмләдә хата бар, ул беренче карашка ук күренеп тора. Типик күренеш булмаса да, башкалар кабатламасын өчен, бераз гына аңлатып китик.

Баскак кем ул? Тарих дәресләрендә игътибарлы булучылар сүзнең Алтын Урда чоры белән бәйле икәнен яхшы хәтерлидер. Баскаклар дип башлыча ханның аерым җирлектәге вәкилләрен һәм салым җыючыларны атаганнар (русча наместник дип аңлатырга була). Элегрәк Россия тарихы дәреслекләрендә баскакларга карата тискәре караш тәрбияләнә иде, баскакларның рус кенәзлекләрендә халыктан ясак җыю мизгелләре сурәтләнгән рәсемнәрне дә очратырга мөмкин иде. Мөгаен, шуңа да журналист япон милләтле басып алучыларга (хәер, совет – япон сугышы контекстында басып алу сүзе гомумән урынлы түгел) карата баскак сүзен кулланырга булгандыр. Яңгыравыклы сүз булса да, тарихи яктан да, мәгънәви яктан да зур хата бу.

Әйтеп кенә бактым

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

«Возраст»

Соңгы вакытларда үземдә үзгәрешләр сизә башладым: ашап алдыммы – йокыга тарта. «Ни хикмәт икән бу?» – дип дуслардан да сораштыргалыйм. Барысы да диярлек беравыздан: «Возраст», – диләр.

Бер уйлаганда, картаерга иртә кебек, гомер көзенә кереп кенә барыш. Ну, шулай да уйландыра. Өйдә түшәмгә карап ятам. Көпәкөндез диванга тарта, заразы. Әле кайчан гына баскан җирдә биеп тора идем.

Колакка бик тә таныш җыр ишетелде. Телевизордан концерт бара икән. Бер егет хәрбиләрнеке сыман кием кигән дә «Солдатта булган диләр» җырын суза. Без яшь чакта бик популяр иде ул җыр. Радиодан ике тавышка җырлауларын гел бирәләр иде. Сүзләрен шагыйрь Шамил Маннапов, көен Гариф Нигъмәтҗанов дигән кеше язган. Бу композитор турында мин берни дә белмим диярлек. Яшь чакта белә идем кебек, хәзер онытылган – возраст.

Яткан җирдән берәм-берәм яшьлек җырларын барлыйм. Безнең заманда әле «Үсә кукурузларым» дигәне дә бар иде. Вәт, малай, элек идеологияне пропагандалау ничек көчле булган, Хрущев идарә иткән елларда бөтен ил диярлек кукурузга дан җырлады. Без ул чакта сәясәт белән артык кызыксынмадык, «Кукуруз шулай үсә ул, сөйсәң ферма кызларын...» дигән сүзләрнең мәгънәсен дә аңлап бетермәдем. Возраст инде. Тик менә ферма кызларын сөйгәнгә кукурузның биек булып үсүе барыбер сәеррәк тоела иде. «Ферма кызлары» дигәч, борынга сыер тизәге, тирес исе дә килеп китә кебек иде. Композиторларыбыз, шагыйрьләребез һәр яңалыкка багышлап җырлар язып барганнар бит. Ул: «Көтүче белән сыер савучы» җырын гына ал! Аның авторларын шулай ук хәтерләмим, әмма сүзләре дә, көе дә хәтердә. Бер уйлаганда, «Су буенда яшел үлән, Чирмешәндә – тәмле су, фән кушканча тәрбияләү – икебезнең бурыч ул...» дигән сүзләр җыр өчен бик ятышлы түгел. Әмма бу җырны яратып җырлыйлар, яратып тыңлыйлар. Авыл яшьләре көтүче һәм сыер савучы булып киенеп башкарса, сәхнәгә кат-кат чакыралар иде.

Мондый җырлар ни өчен хәтердә калган соң? Хикмәт баш миенең әле бик чүпләнмәвендә, ягъни «возраст»та гына түгел. Элек җырларны, нигездә, чын профессионаллар иҗат итә иде. Бу үзенчә, дәүләт заказы буенча язылгандыр, әлбәттә. Чөнки СССР заманында һәр нәрсә: әдәбияты, мәдәнияте, сәнгате дә идеологиягә хезмәт итте.

Бүген без нинди идеологиягә хезмәт итәргә тиеш икән? Бүген эстрада мәхәббәт хисләреннән ташый. Башка тема юк, дисәң, әле авылны сагынып өзгәләнү бар икән. Хәтта балалар да мәхәббәт җырлары җырлыйлар. Ә заманында Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Рөстәм Яхин, Заһид Хәбибуллин, Александр Ключарев, Арслан Батыршин кебек танылган композиторлар балалар өчен җырлар иҗат итеп аерым җыентыклар чыгара иде.

Һади Такташ «... мәхәббәт ул үзе искә нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта...» дип язган үзе. Тик бу шигырьдә «Тиле яшьлек ярты гомерен бирә аның хисе белән яңарга...» дигән сүзләр дә бар шул. Димәк, эстрада яшьләр һәм «ярты гомер» яшәгән яшьләр өчен генә булып чыга. Ә безгә нишләргә? Көе дә, сүзләре дә истә калмый торган җырларны тыңлап утыру бер дә кызык түгел икән ул. Нишлисең инде, возраст.

БЕЗНЕ АЛДА НИ КӨТӘ?

Юк, бу юлы автор киләчәккә фаразлар язарга җыенмый әле. Агымдагы вазгыятьнең саннарын һәм фактларын гына китерә һәм фаразларны рәсми җитәкчелектән бирдертә. Язганнардан чыгып, ахыргы нәтиҗә һәм фараз ясауны укучының үзенә калдырабыз.

Махсус хәрби операция башлангач та, без нигез фаразны бирдек инде: «Безнең барлык оптимизмыбыз бүгенгенең иртәгесе көннән яхшырак булуын аңлауда гына. Март апрельгә караганда яхшырак, апрель – майга караганда», – дип яздык. Рәсми статистика саннары безнең ул фаразны тулысынча раслыйлар. Үзәк банк рәисе Эльвира ханым Нәбиуллина да нәкъ безнеңчә уйлый: «Якындагы кварталлар гади булмаслар, икътисад яңа шартларга ияләнгәнче тормыш компанияләр өчен дә, гражданнар өчен дә катлаулы булыр», – диде. Әгәр дә рәсми вазыйфа биләмәсә, Эльвира ханым кискенрәк итеп тә әйтә алыр иде. Рәсми затлар да каты-каты сүзләр әйтеп ташлыйлар хәзер. Сенатор Андрей Клишас: «Импортны алыштыру программасы тулысынча тар-мар ителде. Тармак ведомстволарының дәртле отчетларыннан башка берни дә юк», – дип ярсып әйтеп ташламадымыни?

Россиянең бүгенге технологик үсеше озак вакытлар санкцияләр басымы астында яшәгән һәм артта калган дип саналган Иранныкыннан күпкә калыша. Әле менә май ахырында гына Мәскәү белән Тәһран бартер килешүләре төзеделәр. Иран нәрсә бирә дә, Россия нәрсә озата? Россия металлургия продукциясен Иранның турбиналарына алыштыра. Фарсылар тагын автозапчастьлар да бирергә вәгъдә итәләр, бездән цинк, алюминий, кургаш сорыйлар. Әйе, әйе, искелек вәкилләре булган азиятлар безгә технологик продукция озаталар, Россия аларның чимал кушылдыгы ролендә чыгыш ясый. Беләсездер инде: чимал сату һәрвакытта да оттырышлы, ә бартерга алыштырганда сәүдә бөтенләй бөлдерә торганга әйләнә.

Россиягә каршы санкцияләр боҗрасы кысылганнан-кысыла бара. Россия нефтенең өчтән икесенә эмбарго керткән Көнбатыш тагын да мәкерлерәк яңа планны тормышка ашырырга әзерләнә. Федераль бюджет исә нефть һәм газ сәүдәсенә тулы бәйлелеккә төшеп бара. Хәзер бюджетта аларның өлеше 63 процентка җитте. Үткән ел 40 процент булган. Каты итеп углеводородлар экспортына суга алсалар, бюджет күпме югалтачак? Кимендә ике тапкыр киметелгән казна акчасы белән эш итәргә туры киләчәк. Газета хәбәрчесе: «Евросоюз Россиянең нефть танкерларын иминиятләштерүгә тыю кертү турында сөйләшүләр алып бара», – дигән хәбәрен укып кына өлгерде, мәгълүмат кырына пылт итеп: «Financial Times газетасы Бөекбритания һәм Евросоюзның нефть төягән Россия корабларын иминиятләштерүне тыю турында килешүләре турында яза», – дигән хәбәр калкып чыкты. Иминиятләштерелмәгән танкерлар белән нефть ташырга беркем дә риза булмаячак. Хәтта Кытай белән Һиндстан да. Димәк, «кара алтын»ны бары тик торба аша Европага гына кудырып булачак. Ә торбага башка чикләүләр кертелде инде. Бик аз гына нефтьне көнбатышлылар куйган бәядән сатып булачак. Россия нефте болай да зур дисконт белән, 35–40 долларга арзанрак сатыла.

Санкцияләр европалыларның үзләре өчен дә кыйбатка төшә, билгеле. Әмма углеводород базары тирәсендә зур уен оештырылды. Байден эмиссарлары Әр-Риядта яшерен сөйләшүләр алып баралар. Согудиягә Кызыл диңгездәге ике утрау – Тиран һәм Санафир утрауларын бирергә, Мисыр һәм Израиль белән мөнәсәбәтләрен көйләргә вәгъдә бирәләр дигән хәбәрләр килә. Әр-Рияд әлегә кадәр «кара алтын» чыгаруны арттыруга каршы, ОПЕК+ Россиядән башка булмый дигән позициядә торды. Әмма соңгы көннәрдә Якын Көнчыгыштан инде картель килешүендә Россияне катнаштырмау хакында сигналлар килә башлады. Бу гарәпләрнең инде җир маен чыгаруны кискен арттырачакларын аңлата. Бу юллар язылганда, Россиянең тышкы эшләр министры Лавров та – Әр-Риядта. Ләкин Мәскәү гарәпләргә нәрсә вәгъдә итә ала соң? Бөртекле ашлык озатырга була. Тик аның өчен рөхсәтне Вашингтоннан алырга туры киләчәк. Байденның рейтингы бик түбәнәйде Америкада. Хәтта үз партиясендә дә аны сөймәүчеләр саны кискен арта. Абруй ягулык бәяләре күтәрелгәнгә күрә төшә, шулай булгач, Байден нефть бәясен төшерү өчен барысын да эшләячәк. Ел ахырына без ягулык базарында бөтенләй башка вазгыять белән очрашырбыз, мөгаен.

Экспортны Көнчыгышка – Кытайга юнәлтербез дигән өметләр дә кысыр. Кытай безгә дус, билгеле, әмма Америка диктатына буйсына. Статистика безгә, Россиянең импорты 89 процентка кимеде, ди. Тыелган товарларны безгә дус илләр дә сатмыйлар. Яисә телиләр, әмма сата алмыйлар. Акча күчерү проблемалы чөнки. Ә экспортка килсәк... Әйдәгез сүзне металлургларга бирәбез. «Русская сталь» ассоциациясе башкаручы директоры Сентюрин әфәнде Кытай һәм башка Азия базарларына металлны бик арзанга, күп кенә очракларда хәтта үзкыйммәттән түбән бәягә сатарга туры килүен әйтә һәм хөкүмәттән салымнарны киметүне, сумны девальвацияләүне сорый. Металл җитештерүчеләр продукция озатуны 40 процентка киметкәннәр инде. Вазгыятьнең шулай булачагын без махсус хәрби операция башлануга ук әйткән идек. «Кытай, Һиндстан, Төркия кебек гигантлар әлегә безгә артлары белән борылмады. Зур потенциал бу. Әмма алар безне файдаланырга, үзләренә бәйлелектә тотарга тырышачак. Башка базарларның ябык булуы аларга шундый мөмкинлек бирәчәк. Алар хәтта бездән чималны арзанга алып, Көнбатышка кыйммәткәрәк сатарга омтылачак», – дип язганбыз «Үзебезнекен үзебез ашасак, көчебез артырмы?» дигән язмада.

vk.com

Россия икътисады кискен түбәнәюдә. Җитештерүнең бер төп күрсәткече бар: ул – өстәмә кыйммәт салымы (НДС). Апрель аенда НДС җыю 54 процентка кимеде, диләр. Озакламый май күрсәткече дә килеп җитәр. Югары күтәрелүе икеле. Халыкның да финанс хәле кыен. Апрельдә ипотека алучылар саны март белән чагыштырганда дүрт тапкыр диярлек кимегән. Юк, бу юлларны язучы ипотека алуны яакламый, әмма сан кешеләр кесәсендә җилләр уйнавын раслый, шуңа әҗәткә алудан халык та курка, банклар да, түләү сәләтенең түбәнәюен аңлап, кредит бирмиләр.

Безнең импортка бәйлелек исә фаҗигале рәвештә көчле. Азык-төлек сәнәгате җиһазлары 59 процентка тузган. Кайбер тармакларда тузу дәрәҗәсе 70–90 процентка җитә. Ә җиһазларның 90 процент тирәсе – импорттан. Хәтта эремчек һәм каймак җитештерү өчен оеткы да (закваска) чит илләрдән китерелә, диләр. Бу соңгыларын үзебездә җитештерүне җайга салу катлаулы булмастыр, әлбәттә. Ә менә җиһазлар мәсьәләсе катлаулы һәм авыр.

Уңай мәгълүматлар да бар. Бензин арзанаерга мөмкин, чөнки нефтьчеләр эчке бәяләрне тышкы базарныкына тиңләштерергә тырыша иделәр. Хәзер тышкы базар алар өчен ябыла, үзебезнең базарда тәкъдим арта. Йөк ташу бәяләре ике тапкыр кимеде дигән хәбәрләр дә ишетелә. Элек Краснодардан Петербургка бер машина продукция төяп илтү йөз мең сумга төшсә, хәзер илле меңне генә сорыйлар икән. Җитештерүчеләр өчен зур плюс бар монда, әмма ул плюс та түбәнгә тәгәрәү нәтиҗәсе генә.

Гыйнвар – апрельдә аракы сату – 7,1, коньякныкы 2,4 процентка арткан. Мәскәүдә һәр сигезенче кеше депрессиядән дәвалана. Авыррак хәлдәге төбәкләрнең санын эзләп тормадык. Топ-менеджерларның чит илгә бару юлына билетлар сатып алуы мартта 70 процентка җиткән, кайту ягына алмыйлар. Германия Россия галимнәренә, мәдәният эшлекләренә, журналистларга җиңеләйтелгән юл белән виза һәм яшәү хокукы бирергә ниятли. Креатив сыйныфтан башка гына без ничек итеп киләчәкне корырбыз – әйтүе кыен.

Боларның берсе дә булмаса да, санкцияләр һәм «миләр качу»дан башка гына да безгә бик авырга туры килер иде, чөнки финанс министры Силуанов әфәнде: «Махсус операция үткәрү гаять зур финанс ресурслары таләп итә», – дип белдерде.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

МӘХӘББӘТЛЕ ГОМЕР

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Ата-ана фидакарьлеге» медален гамәлгә кую карарын Татарстан Президенты гаилә һәм ата-аналарның абруен күтәрү максатыннан кабул итте. Әлеге дәүләт бүләге җиде һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләп үстергән гаиләләргә тапшырыла.

– Балаларны яклау көнендә тәүге тапкыр «Ата-ана фидакарьлеге» медален тапшырабыз, аңа республиканың биш гаиләсе лаек булды, – диде Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә җыелган гаиләләргә мөрәҗәгать итеп. – Гаилә иминлеге өчен шартлар тудыру – дәүләтнең төп бурычы. Һәр гаилә гармониядә, татулыкта, уңайлы шартларда яшәсен иде, аларның киләчәккә ышаныч белән каравы мөһим.

Татарстан Президенты әйтүенчә, соңгы 10 елда күпбалалы гаиләләр саны 66 процентка арткан. «Мондый гаиләләр күбрәк булган саен, республикабыз да, илебез дә көчлерәк була», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, гаиләне ныгытуга һәм саклауга аерым игътибар бирү хәзер аеруча мөһим.

– Баланы әхлакый һәм рухи яктан тәрбияләү – ата-ананың уртак җаваплылыгы, – диде республика җитәкчесе. – Сез гаилә институтының абруен ныгытуда лаеклы үрнәк булып торасыз, ата-аналар абруен арттыруга зур өлеш кертәсез. Сезгә гаилә бәхете, иминлек, үзара аңлашу телим.

«Ата-ана фидакарьлеге» медаленә республикада яшәүче төрле милләт гаиләләре лаек булды. Бу – удмурт, татар, рус, мордва вәкилләре. Болар – Казаннан Раиса һәм Леонид Верниковскийлар (10 бала тәрбияләүләр), Баулыдан Татьяна һәм Юрий Фәрваевлар (9 бала ата-анасы), Сабадан Гөлнара һәм Фәргать Сәгыйтовлар (9 бала үстерәләр), Кукмарадан җиде бала ата-анасы Ирина һәм Юрий Искандировлар, Чистайдан Лариса һәм Андрей Рыбочкиннар (7 бала ата-анасы).

Сәгыйтовлар гаиләсе белән «ВТ» хәбәрчесе дә аралашты. Гаилә учагын сүндерми саклаучы Гөлнара апа белән гәпләшәбез. Фәргать абыйны да әңгәмәгә кушарга иде бит тә, ир-атларга хас сыйфаты бар икән шул: аз сүзле. Аның каравы эшчән, тыныш. Хәер, сөйләшә торгач, 9 балага гомер биргән ике йөрәкнең башка искитәрлек сыйфатлары да ачыкланды. Бәлки, әнә шулар бәрабәренә 29 ел бергә мәхәббәт дигән диңгездә Сәгыйтовлар корабы йөзәдер дә инде.

Әңгәмәдәшләрем икесе дә – Сабадан. Бер урамның бер очыннан. Ничек танышканнар, ничек кавышканнар – иң элек шуны сорашабыз.

– Ирем Фәргать миннән 11 яшькә олырак, – дип хәтер йомгагын сүтәргә керешә Гөлнара апа. – Танышуыбыз турында көлешеп искә алабыз. Аның армиядән кайткан чагы, ә мин мәктәптә укыйм. «Бантик таккан бер кыз мәктәпкә бара», – дип хәтерендә калдырган ул мине. Бантикларым төрле төстә, бик күп иде шул. Менә башта шул бантикларга кызыгып, сокланып йөргән инде ул. Яз аенда кавыштык. Без өйләнешкәндә миңа – 20, аңа 31 яшь иде инде. Әтиәниләр аңлап кабул итте. Үземнекеләрнең дә яшь аермасы – 9 ел.

Айзат, Айрат, Айгиз, Фәридә, Сафия, Булат, Айдар, Фәрит, Азимурат. Сәгыйтовларның тормыш чәчәкләре – балаларының исемнәре бу. Олы балаларына – 28, кечесенә августта 5 яшь тула. Җиде баһадир һәм ике гүзәл кыз. Тугызы да тугыз төрле дияр идең, Гөлнара апа аларны берләштергән бер нәрсә – мөстәкыйльлек бар, ди.

Айзат, Айрат – Казанда эшли. Айгиз белән Фәридә – студентлар. Сафия, Булат, Айдар Саба гимназиясендә белем ала. Фәрит белән Азимурат балалар бакчасына йөри. Гөлнара апа балаларын барысын да үзе тапкан, операция белән дөньяга килгәннәре юк. Соңгысын тапканда исә әңгәмәдәшебезгә 44 яшь була инде.

– 9 бала әнисе булырмын дип башыма да китермәгән идем. Беренче балабыз – улыбыз туды. Ул вакыт калыбы буенча без инде соңарып бәби алып кайтучылар рәтендә идек. Озакка сузмыйча, бер-бер артлы тагын икене алып кайттык, – дип сөйли Гөлнара апа.

Яшьлеге белән ул вакытлардагы авырлыкларга, сизелсә дә, исе китмәгән әңгәмәдәшебезнең. 90 нчы елларны кичкән буын югыйсә.

– Акчабыз да булмаган вакытлар. Ирем ул вакытта Туктар кирпеч заводында эшли. Хезмәт хаклары да юк. Мин исә белемем буенча пешекче, хастаханәдән декретка чыктым. Әти-әниләр булышып торган, бакчада яшелчә үскән, чебиләр асраганбыз, шулай яшәлгән инде, – ди ул.

– Ул чакта бер дә зарланылмаганмы әллә? Ышанасы килми! Монда әле бар да җитеш булган заманның да китек ягын табарга тырышабыз ич! – дибез.

– Мин – тормыштан канәгать һәм тормышка позитив карый торган кеше. Әтием шундый иде. Шулай тәрбияләде дә. «Кеше сөйләп йөрмә, ыгы-зыгы чыкса, алар дәрәҗәсенә төшмә», – дип әйтә иде. Бу сүзләрне әле дә истә тотам. Ярып пешергән бәрәңгегә дә шат-риза була белде эти. Миндә менә шундый характер, кешедән көнләшмим, үземә максат итеп нидер куям икән, шуны эшлим! – дип җаваплый Гөлнара апа. – Өченче баладан соң төрле сүзләр ишетә башлыйсың инде ул. Әмма без балаларыбызны акча өчен дип тә, башкасы өчен дә тапмадык. Ул чорда аның акчасы да юк бит инде. Кайберәүләргә каты әйтергә дә туры килгәли.

Сөйләшә торгач, әңгәмәдәшебез мәктәп чорындагы бер хатирәсен дә ачып салды.

– Мәктәп бетергәндә, укытучыбыз анкета тутыртты. Классташлар очрашуында шуларны укыдык. Мин нәрсә язган дип уйлыйсыз? – дип сорый Гөлнара апа.

– Тугыз бала алып кайтам дип түгелдер инде, шәт...

– Яраткан эшем, яраткан гаиләм һәм күп балаларым булачак дип язганмын. Һәр пункт та үтәлде. Язылганнарым тормышка ашты.

Бер-бер артлы бәби алып кайтуына карамастан, белем арттыру турында да онытмаган ул. Вакытны һәм вазыйфаларны дөрес бүлсәң, барысына да өлгереп була икәнен дәлилли әңгәмәдәшебез.

– Укырга яраттым. Укырга түләр өчен, пешекче булуым да ярап куйды: кабартма пешереп, базарга алып чыгып сата торган булдым. Күз алдыгызга китерегез: бер кулда чана белән бала, икенчесендә кәстрүл белән кабартма! Машина йөртергә дә укыдым. Безнең шул икебезгә бер «Ока» иде, ирем велосипедта йөреп торды. Кибеткә бараммы, башка җиргәме – балаларны үземнән калдырмадым. Алар белән озак вакытка аерылышып торган көнемне хәтерләмим. Берничә көнгә Казанга китәсе булса да, көнендә кайтып, икенче көнгә яңадан китә торган булдым. Аннан, балаларыбыз шәһәр күреп үстеләр. Казанның балалар мәйданчыклары, төрле чаралар, кибетләр, цирк – барысына да йөрдек. Автобуска төяләп, төшеп китә идек, ирем эштән кайтып, төнлә килеп ала иде. Без балаларның күңелләрен күрергә тырыштык, – ди Гөлнара апа. – Безнең өйдә дисциплина. Балалар да моны белә. Берәр кая барасы булса, алар инде киенеп, җыенып торалар иде. Өченче малаебыз бәләкәй вакытта инша язган иде. «Минем әти күркәм холыклы, әни – кырыс» дигән бу. Менә шуннан аңлагыз. Сөйләшкәндә дә балаларым: «Әни, син безне нык тотып үстердең», – диләр. Мин исә: «Шулай дөрес булганмы соң?» – дип тә сорыйм. Балаларым шундый тәрбия алуларына сөенә, аның дөрес булуын аңлый. Хәзер син бәләкәй балаларыңны иркәлисең әле, дип тә әйткәлиләр!

Хатын-кызның күп вакыты аш-су бүлмәсендә үтүен исәпкә алып, әңгәмәдәшебездән шул хакта да сорашабыз. Ишле гаиләгә бергә җыелганда ризык әзерләү өчен бер тәлинкә-кашык белән генә чикләнеп булмавы көн кебек ачык лабаса.

– Тәмле ашарга яратабыз. Гадәттә, ашны 5 литрлы кәстрүлдә пешерәм. Кайбер очракларда 10 литрлысы да эшкә җигелә. Әйтик, фаршланган борыч әзерлим икән, анысын өч кәстрүл әзерлим. Гел шулай! Бәлеш икән, аның эчлеге бер чиләклек була инде, – дип сөйли Гөлнара апа. – Коймак, кекс ише нәрсәләрне Фәридәбез пешерергә ярата. Алар – кул арасында кайнашкан балалар. Киленебез Диана кайткан вакытта, шулай ук үзенчәлекле ризыклар әзерләргә тырышалар. Дөресен әйткәндә, хәзер минем вазыйфам – продукция белән тәэмин итеп тору гына. Духовка кырыена сирәк басыла.

Гөлнара апа тормыш иптәше Фәргать абый турында да бары яхшы сүзләр генә әйтә. «Ул ял белмәде, эшләде дә эшләде. Мине бала табу йортыннан төшке ашка кайтышлый гына ала иде, дип шаяртам. Безнең, мөнәсәбәтләрне ачыклап, тәлләшеп утырырга вакыт булмады», – ди ул.

Ишле гаиләнең хуҗабикәсеннән бәхетле гаилә рецептын да сорыйбыз.

– Иремнең дә, минем дә уртак бурыч – балаларны кайгырту. Без шуның белән бергә 29 ел буе барабыз да инде. Без үзебез турында уйламагандыр да, – диде Гөлнара апа. – Бәби табарга җыенганнар мине искә алсын иде. Куркыныч түгел ул.

P.S. *Гөлнара апага: «10 нчы, кем әйтмешли, «юбилейный» баланы алып кайтырга уйламыйсызмы соң?» – дигән булабыз. Кәкре атып, туры тигезәбез әле, әй!*

– Фәргать абыең белән әле берсендә шул хакта сөйләштек. Үкенече калган икән. Унынчысын да алып кайтасыбыз калган, диде. Анысы кыз булыр иде төсле, ди, – дип җаваплый әңгәмәдәшебез.

Үкенеч түгелдер бу, Гөлнара апа, Фәргать абый! Ул-кызлар сөендерер әле сезне. Оныклар сөясе бар бит! Өегездән бала тавышы өзелмәс, димәк. Алар исә, һичшиксез, әби-бабаларының матур дәвамы булыр.

КҮПБАЛАЛЫ ГАИЛӘЛӘРГӘ – МАТДИ ЯРДӘМ

Россия Президенты Владимир Путин күпбалалы гаиләләр өчен яңа акчалата түләү булдырырга тәкъдим итте. Бу хакта ул «Ата-ана даны» ордены медаленә лаек булган күпбалалы гаиләләр белән очрашуда белдерде.

Сүз 200, 500 мең һәм 1 млн сум күләмдә акчалата ярдәм турында бара.

Әйтик, 200 мең сум акчаны «Ата-ана даны» ордены медале ияләре ала алачак. Ярты миллион сумны орденлы гаиләләргә бирәчәкләр. 1 млн сум күләмендә акчаны исә «Герой Ана» исеменә лаек булган ханымнарга тапшырачаклар.

Искәртеп узыйк: «Ата-ана даны» ордены медаленә дүрт һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче (яисә тәрбиягә алучы) ата-аналар лаек була. «Ата-ана даны» ордены белән җиде һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләр бүләкләнә. Аларның барысы да Россия гражданнары булырга тиеш.

Киссәң генә яңара

Тиздән урман хуҗалыгында гаиләләре белән эшләүчеләр артырга мөмкин. Моңарчы да династияләп эшләүчеләр күп булган. Әмма дәүләт хезмәтендәге закон туганлык җепләре булмауны таләп итә. Урманчылар исә, элеккеге традицияне торгызып, законга үзгәрешләр кертмәкче. Аларны Президент Рөстәм Миңнеханов та хуплаган.

Әлеге тәкъдимне Мәскәүгә дә җиткергәннәр. Бу хакта Кукмара районының Лубян бистәсендә Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты белән аның каршындагы эксперт советының уртак күчмә утырышында сөйләштеләр. Шулай ук биредә бакчачылыкка ярдәм итү, авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын арттыру турында республика законнары проектлары һәм «Татарстанда урманнарны саклау» төбәк проектын гамәлгә ашыру мәсьәләсенә дә тукталдылар.

– Элек урманда гаиләләр белән эшләү тәҗрибәсе бар иде. Без моны кире кайтарырга кирәк дип уйлыйбыз. Урманчы һөнәре үз вазыйфаңны үтәү генә түгел, ул табигатькә хезмәт итү дә. Бу эшкә урманны яраткан кешеләр генә килә. Әгәр без киредән династияләп эшләүне кайтара алсак, кадрлар кытлыгы кимер иде, – диде фикердә Татарстанның урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров.

Утырышның Лубян урман-техник көллиятендә узуы да юкка түгел. Әлеге уку йорты урманчылар әзерли. Бүген биредә дүрт белгечлек буенча 320 студент белем ала. Көллиятнең йөз ел эшләү дәверендә 10 меңнән артык белгеч әзерләнгән.

Кукмара районы башлыгы Сергей Димитриев та Лубян белән горурлануын яшерми.

– Район өчен бу бистә аерым әһәмияткә ия, – ди ул. – Урман хуҗалыгы тармагы үзәкләренең берсе булганга, анда тормыш гөрләп бара. Лубян яңара һәм үсеш кичерә. Биредә төзекләндерү, юл төзелеше һәм су белән тәэмин итү мәсьәләләренә зур игътибар бирелә.

Утырышта депутатларга «Татарстанда урманнарны саклау» төбәк, «Урманнарны саклау» федераль, «Экология» илкүләм проектын һәм республикада урман законнары нормаларын гамәлгә ашыру турында урман хуҗалыгы министры урынбасары Илгизәр Зарипов сөйләде.

– Республика җирләренең 1 млн 269 мең гектар мәйданын урманнар тәшкил итә. Биредә үскән агачларның уртача яше – 54 яшь. «Татарстанда урманнарны саклау» проектының төп максаты – 2024 елга урманнарны кисү һәм яңадан торгызуны тигезләштерү. Күпме кисәбез, шуның кадәр утыртачакбыз, – диде ул.

Илгизәр Зарипов урманнарын саклау буенча башкарылган эшләргә дә тукталды. Урман янгыннары хакында да сөйләде. Республикада янгынга каршы тору өчен мөмкинлекләр җитәрлек, дип ышандырдылар. Июнь башыннан урманнарны һавадан күзәтә башлаганнар.

Равил Кузюров урманга сакчыл караш таләп ителүен искәртте.

– Агач үсү өчен тиешле шартлар юк икән, урман үзен начар хис итә башлый. Авырулар күбәя, янгын куркынычсызлыгы туа. Урманның һәр почмагына урманчы кулы тиярге тиеш. Әлегә закон урмандагы агачларны кисүне тыя. Әмма без үзгәрешләр кертүне сорадык. Кисеп торганда гына урман яңара, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сәрия МИФТАХОВА

БЕЗНЕҢ ЫЗАН

Бәйрәм ашы – кара-каршы. Узган ел Актанышта Башкортстан һәм Татарстан депутатлары туган телләрне саклау һәм үстерү мәсьәләләре турында фикер алышкан иде. Бу юлы Нефтекама шәһәрендә Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты һәм Башкортстан Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның Мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт буенча комитетының уртак күчмә утырышы булды. Ике күрше алга таба нәрсәләргә игътибар бирергә җыена?

tatarstan.ru

«Татарлар – кардәшләр». Әле сишәмбе көнне генә Казанга килгәч, Президент Рөстәм Миңнеханов белән очрашуда Башкортстан башлыгы Радий Хәбиров әнә шулай диде. Казан Кремлендә ике республика арасындагы чикнең урнашу урынын билгеләү турындагы килешү имзаланды. Хезмәттәшлекне тагын үстерү өчен тормышка ашырыласы чаралар турында да килештеләр.

Дуслык белән көчле без

Актаныштан Нефтекама шәһәре ерак түгел. Агыйдел елгасын кичүгә без башкорт тирмәсенә килеп чыктык. Монда ут күршеләребез курай уйнап, җырлап-биеп, ипи-тоз, якты йөз белән каршы алды. Башкорт йортында тугандаш халыкның борынгыдан килгән шөгыльләре, яшәү рәвеше белән таныштык. Тирене дә оста иләгәннәр, мәргәннәре белән дә аерылып торганнар. Бу көнне Нефтекама шәһәрендәге ял паркында «Милли калейдоскоп» бәйрәме дә үтте. Монда да төрле милләтләр үз гореф-гадәтләрен тәкъдим итте. Башкортстанда 160тан артык милләт вәкиле яши.

– Һәрбер очрашу ике якны да баета. Кыйммәтен әйтеп бетереп булмый. Бик кирәк эш бу. Ике арадагы дуслыкны тагын да ныгыта. Очрашкан саен – мәдәният булсынмы, мәгарифме, телне, гореф-гадәтләрне саклап калунымы... – барысын да уртага салып сөйләшәбез, – диде Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин. – Милли мәдәниятләрне һәм гореф-гадәтләрне, туган телләрне саклап калу буенча үзара мөнәсәбәтләрне көйләү мәсьәләләре парламент эшчәнлегенең көн тәртибеннән беркайчан да төшми, чөнки күпмилләтле җәмгыятьнең иҗади үсеше нигезе булып тора.

Фәрит Мөхәммәтшин белдергәнчә, соңгы елларда ике республиканың товар әйләнеше күләме дә шактый арткан. Бу ныклы икътисади, мәдәни, рухи һәм гуманитар бәйләнешләр урнашуын тагын бер кат дәлилли.

Башкортстан Дәүләт Җыелышы – Корылтае Рәисе Константин Толкачев яшереп тормады: күршеләре арасыннан иң якын күргәне Татарстан икән.

– Безне, барыннан да элек, уртак тарих, охшаш мәдәният һәм дуслык берләштерә. Иҗтимагый мөнәсәбәтләр өлкәсе бар. Гуманитар дәрәҗәдә хезмәттәшлек мөһим. Без вакуумда түгел, ә иҗтимагый мохиттә яшибез һәм без милләтләр арасында уңайлы мөнәсәбәтләр урнаштырырга тиеш. Республиканың закон чыгару органының барлык профильле комитетларын уртак эшкә җәлеп итәргә, шул рәвешле көн тәртибенә чыгарыла торган мәсьәләләрне киңәйтергә кирәк, – диде Константин Толкачев.

Утырышта Башкортстан һәм Татарстан халыкларының гореф-гадәтләрен, милли мәдәниятләрен саклау һәм үстерү буенча закон чыгару дәрәҗәсендә тәҗрибә алмашуны активлаштырырга дигән тәкъдим булды. Федераль дәрәҗәдәге закон чыгару мәйданчыкларында ике республика депутатлары болай да бер-берсен хуплый. Россия Дәүләт Думасына кертелгән «Россия Федерациясенең матди булмаган этнокультура байлыгы турында» федераль закон проектын әзерләүдә Башкортстан, Татарстан парламентарийлары актив катнашкан.

Телне беләләрме?

Башкортстан мәктәпләрендә туган телләргә карата мөнәсәбәт нинди? Әтиәниләр моңа ни дәрәҗәдә игътибар бирә икән?

Гомумән алганда, республикадагы вазгыятьне түбәндәге саннардан да чамалап була. Туган тел итеп русчаны – 345509, башкортчаны – 105035, татарчаны – 46541, маричаны – 3314, чуашчаны – 3061, удмуртчаны 901 укучы сайлаган.

Башкортстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Әлфия Галиева әйтүенчә, соңгы елларда республикада күп телләрдә белем бирүче 4 мәктәп ачылган.

– Туган телләрдән имтихан бирү мөмкинлеге булмау безне дә борчый. Шулай да быел шунысы сөендерә: беренче тапкыр 9 нчы сыйныф укучылары туган телдән сынау тапшырды. Анда 5400 бала катнашты. Россия Мәгърифәт министрлыгы безне ишетеп, киләчәктә туган телләрдән БДИ тапшыру мөмкинлегә тудырыр дип ышанабыз. Бездә туган телдән бәйгеләрдә җиңгән, призер булган балаларга укырга кергәндә, өстәмә баллар бирелә. Бу төрле вузда төрлечә, 2дән 10 баллга кадәр, – ди Әлфия Галиева. – Бездә дә күптелле мәктәпләр проекты бар. 2019 елда икәү ачылса, бүген 4әү эшли. Анда татар телен дә өйрәнәләр.

Татарстан кунаклары барып күргән Нефтекама гимназиясендә 1200 бала укый. Уку йорты директоры әйтүенчә, укырга теләүчеләр елдан-ел арта бара. Монда әти-әниләрнең 76 проценты башкортчаны туган тел буларак сайлаган. Туган тел атнага өч тапкыр укытыла икән.

Үз казаныбызда гына кайнамыйбыз

Милли белем бирү системасы турында Башкортстан Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның Мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт буенча комитеты рәисе урынбасары Әлфис Гаязовның фикерен белештек.

– Милли мәдәният, телләрне үстерү буенча җитди проблемалар чыгып тора. Шуңа күрә хәл итү юлларын бергәләп эзләү бик файдалы. Элек күп вакытта һәркем үз казанында кайнаса, хәзер алай түгел, – диде ул. – Соңгы вакытта без гуманитар өлкә белән мавыгып киттек. Нинди генә мәктәпкә барма, анда 3–4 тел өйрәнәбез, дип мактанган чаклар бар иде. Хәзер милли техник инженер кадрларның кирәклеге турында уйлый башладык. Нефть, газ чыгару яки башка өлкәләрдә дә үзебезнең кешеләр кирәк бит. Әгәр шул ук башкорт, татар телеме, дөнья системасында үз урынын таба алса һәм ул телдә фәнни дәрәҗәдә сөйләшү булса, укыту файда бирәчәк.

Депутат соңгы вакытта әти-әниләрнең туган телне сайлауга бик риза булмавын әйтте. Бу бар җирдә шулай. «Гаиләдә туган телдә сөйләшмичә, башка телдә аралашу дөрес түгел. Шуңа күрә туган телне белүчеләрнең санын арттырырга кирәк. Шулай булганда, укытучыларга да һәм туган телгә дә ихтирам артачак», – ди ул.

Әлфис Гаязов та киләчәктә туган телләрдән имтихан булыр дип өметләнә. «Үн ел элек бердәм дәүләт имтиханы тәҗрибә формасында узганда бездә төбәк формасы бар иде. Туган телләрдән сынау бирү мөмкинлеге дигән сүз бу. Бүген Россия Болонья процессыннан чыгарга җыена. Бу имтиханнар системасын үзгәртүгә дә китерәчәк», – дип өметләнә депутат.

Татар-башкортлар дус яшибез дигән сүзләрне аз ишетмәдек утырышта. Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов та мондый очрашулар ешрак узарга тиеш дип саный. Бер-беребезне яхшырак белү Башкортстанның да, Татарстанның да үсешенә этәргеч булачак, ди ул.

Нефтекамадагы очрашу фикерләр әйтү, тәкъдимнәр җиткерү, өмет әләшү белән чикләнмәде. Бирегә Актаныш районы күрше республиканың Нефтекама каласы һәм Краснокама районы белән килешү төзеде.

vk.com

ҖИР СУЛЫШЫ

СУЛЫКЛАРДАГЫ ҮЗГӘРЕШЛӘРНЕҢ СӘБӘПЛӘРЕ НИДӘ?

Кайдадыр һич уйламаганда җир убылган, кайдадыр күл юкка чыккан, сулыклар корыган, икенче бер урында тулы бер ял итү зонасы куркыныч астында калган. Табигатьнең мондый көтелмәгән сюрпризлары уйландыра да, гаҗәпләндерә дә, шомландыра да. Соңгы елларда сулыклар нинди үзгәреш кичерә? Аларның сәбәпләре нидә? Әлеге үзгәрешләр кешелек дөньясына нинди йогынты ясый? Галимнәр белән шул хакта сөйләштек.

Тозлы күлгә ни булган?

Россиянең иң популяр ял һәм сәламәтләндерү курортларының берсе булган Тозлы күлдә башка елларда 1 июньдә сезон ачыла торган иде инде. Быел сабыр итеп торалар. Яз айларында, курорт хәтта бөтенләй эшләмәскә мөмкин, дигән хәбәрләр дә таралды. Билгеле, күңелсез яңалыклар эшмәкәрләр һәм Соль-Илецк халкы өчен дә, ял итәргә нәкъ менә шунда барырга тәгаенләп торучылар өчен дә аяз көнне яшен суккан кебек кабул ителде. Берәүләр, акча эшләп калу мөмкинлеген кулдан ычкындырабыз, дип борчылса, икенчеләр сәламәтлекләре турында уйланды. Әлеге күңелсез хәлләрнең сәбәбе – курорт территориясендә урнашкан тозлы күлләрдәге карст процессы. Гади тел белән әйткәндә, җир астында, тоз шахталары тирәнлегендә бушлык барлыкка килеп, җир убылып төшү куркынычы барлыкка килгән. Хәтта бер төркем галимнәр киләчәктә Соль-Илецкиның туристик үзәк булып эшләвенә дә шик белдерә. Тик «Урал56.Ру» порталы хәбәр итүенчә, хәзерге вакытта «Тозлы күл» оешмасы карст упкынын төзәтү һәм ярларны ныгыту эшләре белән шөгыльләнә. Әгәр яңгырлар явып, эшне тоткарламаса, курорт үз эшен 20 июньдә башлап җибәрергә мөмкин.

Шунысын билгеләп узарга кирәк: карст процесслары курорт территориясендә моңа кадәр дә булган. 1979 елда комплексның иң эре Развал күле, тозлылык кимү сәбәпле, төбе юылып, берничә сәгать эчендә тулысынча төпкә төшеп киткән. Ул вакытта аның сулары җир астындагы беренче сортлы тоз эшләп чыгара торган шахтаны батырган. Моннан тыш, зур булмаган үзгәрешләр 2003 һәм 2010 елларда да күзәтелгән. Ул елларда Развал күле янәшәсендәге Городское күленең пляж ландшафты үзгәргән.

Татарстан Фәннәр академиясенең экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институтының гидрология лабораториясе мөдире, география фәннәре кандидаты Асия Горшкова әйтүенчә, «Тозлы күл» курортындагы тоз һәм ләм күлләренең төбендә үзгәрешләр барлыкка килгәч, администрациянең кешеләр гомерен куркыныч астына куймас өчен алдан хәстәрен күрүе, кисәтүе – дөрес адым.

– Карст – нинди дер көтелмәгән күренеш түгел, – ди галимә. – Ул – табигый процесс. Аннан берничек тә качып котылып булмый. Ягъни тау токымнары табигый сулар белән юыла. Әлеге процесслар нәтиҗәсендә рельефта төрле карстлы формалар барлыкка килә: чокыр, упкын, шахталар, каналлар һәм башкалар.

Могҗиза

Кышын халыкны тагын бер вакыйга гаҗәпләндергән иде. Россиянең җиде могҗизасының берсе булып саналган, Мари Иленең иң матур һәм туристлар арасында иң популяр булган Диңгез күзе (Морской глаз) күленең суы кинәт кенә юкка чыгып, зур чокыр гына утырып калган иде.

Билгеле булганча, Диңгез күзе – табигать процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән күл. Аның суы 2014 елдан кими башлаган иде. Ике елдан ул кабат үз хәленә кайтты һәм яңадан суын югалта башлады. Галимнәр ул вакытта су асты гөрләвекләренең юкка чыгуын һәм күлнең су белән тәэмин ителеше бозылуын әйткән иде. Шуңа күрә күлнең юкка чыгу сәбәпләрен өйрәнүче галимнәр беренче сәбәп итеп грунт суларының кимүен күрсәтте. Тик кеше йогынтысы барлыгын да инкарь итмәделәр. Алар фикеренчә, геологик процессларга скважиналарның тәэсире зур булган.

Галимә Асия Горшкова аңлатуынча, Диңгез күзе күле акбур һәм башка яхшы уалучы тау токымнарыннан (табигать процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән бер яки берничә минераль яки органик матдәләрнең массасы яки агрегатлы) тора. Алар исә тиз юыла һәм чатный.

– Кышын күлнең төбе чатнап, суы китте. Әйе, язын күлгә су кабат җыела башлады. Бу – язын күп сулыкларга хас булган, гадәти күренеш. Ләкин алар озак торырмы? Беркем дә әйтә алмый, чөнки бер тапкыр чатнаган ярыктан су кабат агып бетәргә мөмкин, – ди Асия Горшкова.

Кеше көче

Күршеләрдә хәлләр менә шулайрак. Татарстан сулыкларында вазгыять ничек соң? КФУның идарә итү, икътисад һәм финанслар институтының кафедра мөдире, профессор Нәфисә Минһаҗева әйтүенчә, Татарстанда карстлы күлләр юк. Диңгез күзе күленең төсе дә уникаль. Безнең территориядә андый сулыклар шулай ук юк. Үзенчәлекле күл дигәндә галимә Әлмәт районындагы Акташ упкыны (Акташский провал) күлен атады.

– Әлеге күл шулай ук су асты сулары белән тәэмин ителә. Аның тирәнлеге 28 метрга җитә. Ләкин суы күп түгел. Бу суны бакчачылык ширкәтләре алуга бәйле. Бу күл шулай ук үзенчәлекле һәм гаҗәп, ул – Татарстанда бердәнбер, – ди профессор.

Моннан тыш, галимә уникаль табигый сулыклар дигәндә Зәңгәр күлне атады.

Алда язып узган күренешләр Татарстан территориясендә күзәтелмәсә дә, сулыклар дөньясындагы үзгәрешләр уйландыра. 2018 елда басылып чыккан «Татарстан Республикасының су объектлары» белешмәсендә китерелгән мәгълүматлар буенча, республикада 14867 су объекты бар. Аларның 6914е – елгалар, 6621е – күлләр, 1328е – буалар, 4 – эре сусаклагыч. Кечкенә елгаларның саны 5206 тирәсендә тирбәлә.

> Республикада һәр ун ел саен 1500 тирәсе күл юкка чыга. 1994 елдан 2006 елга кадәр – 1425, 2006–2018 еллар эчендә 1681 күл юкка чыккан, – диде география фәннәре кандидаты Асия Горшкова.

Галимә әйтүенчә, сулыкларның агымы формалашуга төп ике фактор йогынты ясый. Беренчесе геологик һәм метеорологик процесслар булса, икенчесе – кеше йогынтысы. Соңгы сулыклардагы үзгәрешләрне берничә тапкыр тизләтә.

– Җирнең географик тышчасы үзгәрүгә сусаклагычлар төзү бик зур йогынты ясады, – дип аңлата галимә. – Татарстан территориясенең 84 проценты сусаклагычларның барлыкка килгән яңа су җыела торган урыннарыннан гыйбарәт. Куйбышев сусаклагычы республиканың гомуми мәйданының 56 процентын, Түбән Кама – 21, Зәй һәм Карабаш сусаклагычлары хисабына үз чикләрен зурайткан Дала Зәе (Степной Зай) тагын 7 процент мәйданны алып тора.

Асия Горшкова сүзләре буенча, табигатьтәге әлеге үзгәрешләр нәтиҗәсендә, кайдадыр күлләр юкка чыга, ә кайдадыр, киресенчә, яңалары барлыкка килә. Мәсәлән, Казансу бассейнында сусаклагыч төзелгәннән соң, 128 яңа агым барлыкка килә. Аның каравы 60ы корыган. Һәм мондый процесслар Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларына да хас.

– Елгалар системасындагы үзгәрешләр аның сыйфатына да йогынты ясый, – ди галимә. – Соңгы 15 елда, гидрохимик һәм гидробиологик анализлар нәтиҗәләре буенча, сулыкларның 40 проценты «бик пычрак», 42 проценты «уртача пычрак» һәм «пычрак» дип табылды. Нибары 18 процентының гына «чиста» булуы ачыкланды.

Сулыкларда баручы үзгәрешләргә сусаклагычлар төзү генә йогынты ясамый, әлбәттә. Әйе, галимә әйтүенчә, бу – төп сәбәп. Тик моннан кала, су җыю урыннарында корылмалар төзү, урманнарны бетерү, сулыкларны бетереп, җирләрне сөрү, тиеш булмаган урыннарда буалар бәяп кую, җиргә чамадан тыш күп ашлама кертү, сәнәгать, авыл хуҗалыгы объектларында, шәһәрләрдә яңгыр канализация системаларында чистарту корылмалары булмау елга-күлләргә тискәре йогынты ясый.

– Хәзерге заманның иң актуаль проблемаларыннан берсе – су белән тәэмин итүнең табигый чыганаклары кимү. Экологиядәге тискәре күренешләрнең нәтиҗәсе нинди буласын алдан фаразлап та бетереп булмый, – дип саный Асия Горшкова. – Экологик-икътисади балансга ирешер өчен әйләнә-тирәдәге вазгыятькә анализ бирергә кирәк. Шул ук вакытта бу эштә дәүләт органнарын да җәлеп итү, тиешле законнар кабул итү һичшиксез мөһим.

Җир убылу

Хәер, үзгәрешләр сулыкларда гына түгел, җирдә дә еш күзәтелә. Мәсәлән, күптән түгел Яшел Үзән районының Түбән Вязовые авылы тирәсендә һич көтмәгәндә сөрүлек җире убылып төште. Авыл халкы сүзләренчә, аның тирәнлеге өч катлы йортка тәңгәл. Убылган җирнең гомуми мәйданы 200 квадрат метр чамасы тәшкил итә. КФУның гомуми геология һәм гидрология кафедрасы доценты Айрат Латыйпов сүзләренчә, моның сәбәбе – җир асты суларының тау токымын юып, аста бушлык барлыкка килү. Киләчәктә чокыр су белән тулырга мөмкин дигән фаразлар да бар.

Әлеге хәлне урынга чыгып тикшергән галимнәр, тора-бара чокыр тагын да зураерга мөмкин, дигән фикер әйткән иде. Без исә Түбән Вязовые авылы советының башкарма комитеты җитәкчесе Айрат Гыйниятовка шалтыратып, шул хакта белештек.

– Әлегә бернинди дә үзгәреш юк. Убылган җирнең мәйданы шул килеш тора, су да күренми. Киләчәктә бу урынны нәрсә эшләтербез – әйтә алмыйм. Хәзер күзәтүдән ары берни дә эшләп булмый, – диде ул безгә.

Зәһрә САДЫЙКОВА

6 июнь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 16.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл батл» 0+
17.00 «Татарлар» 12+
17.30 «Трибуна «Нового Века» 12+
19.00, 20.00, 01.05 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Каравай». Весенние проталины 6+
00.15 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Фирдәвес Хәйруллина турында телеочерк 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Дмитрий Дюжев, Екатерина Гусева, Евгений Дятлов, Дмитрий Назаров, Александр Лазарев. «ТОБОЛ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков, Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Ольга Будина. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
02.45 Мария Порошина, Вячеслав Разбегаев, Владимир Епифанцев. «ПО ГОРЯЧИМ СЛЕДАМ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.35, 15.00, 20.55 Новости
06.05, 16.05, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.40 Спец. репортаж 12+
09.30 Футбол. Лига чемпионов. «Спартак» (Москва, Россия) – «Реал» (Мадрид, Испания) 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.05 «АПОСТОЛ» 16+
16.40 Лёгкая атлетика. Мировой континентальный тур. Прямая трансляция из Нидерландов
18.45 «Громко». Прямой эфир
19.50 Смешанные единоборства. UFC. Александр Волков против Жаирзиньо Розенстрайка. Трансляция из США 16+
21.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
23.40 «Есть тема!» 12+
00.00 «ВПРИТЫК» 16+
01.45 Американский футбол. Лига легенд. Женщины. «Остин Акустик» – «Чикаго Блисс» 16+
02.35 «Драмы большого спорта. Владимир Смирнов» 12+
03.00 «Диалоги о рыбалке» 12+
03.25 Новости 0+
03.30 «Неизведанная хоккейная Россия» 12+
03.55 Лёгкая атлетика. Мировой континентальный тур. Трансляция из Нидерландов 0+
05.05 «Громко» 12+

НТВ

05.05 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) (6+
09.20, 10.30 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.40 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Детектив «ДЕЛЬФИН» (S) 16+
22.00 «ГЕНИЙ» (S) 16+
00.00 «ПЁС» (S) 16+
03.25 «ШАМАН» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Предсказания: 2022» 16+
07.05 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «Кризисный центр» 16+
19.00 «ЗА ВИТРИНОЙ». 1-я – 4-я серии 16+
22.50 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 4». 11-я и 12-я серии 16+
00.35 «АНЖЕЛИКА – МАРКИЗА АНГЕЛОВ» 16+
02.25 «Понять. Простить» 16+
03.15 «Порча» 16+
03.40 «Знахарка» 16+
04.05 «Верну любимого» 16+
04.30 «Давай разведёмся!» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «РОЗЫСКНИК» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 23.15 «ДУМА О КОВПАКЕ» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
13.25 «Истребители Второй мировой войны». Док. сериал 16+
14.00 Военные новости 16+
14.15 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+
18.45 «Специальный репортаж» 16+
22.00 «Между тем» 12+
22.25 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Побег из-под носа ЦРУ» 12+
00.55 «ЭТО БЫЛО В РАЗВЕДКЕ» 12+
02.30 «Нюрнберг». Док. сериал 16+
03.45 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+

7 июнь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15, 01.05 «Не от мира сего...» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00, 01.30 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Мы не исчезнем. Династия Габаши 12+
00.40 «Каравай». Национальные мотивы в творчестве композитора Ш.Тимербулатова 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Мәңгелек... Ирек... Хисләр...» Ирек Баһманов турында телеочерк 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «ТОБОЛ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков, Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Ольга Будина. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
02.45 Мария Порошина, Вячеслав Разбегаев, Владимир Епифанцев. «ПО ГОРЯЧИМ СЛЕДАМ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.35, 15.05, 20.55 Новости
06.05, 16.10, 20.10, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.40 Спец. репортаж 12+
09.30 Футбол. Лига чемпионов. «Манчестер Сити» (Англия) – ЦСКА (Россия) 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.10 «АПОСТОЛ» 16+
16.55 «Неделя лёгкой атлетики». «Мемориал братьев Знаменских». Прямая трансляция
21.00 Футбол. Лига Европы. «Зенит» (Россия) – «Ливерпуль» (Англия) 0+
23.40 «Есть тема!» 12+
00.00 «СКАНДИНАВСКИЙ ФОРСАЖ» 16+
01.45 Американский футбол. Лига легенд. Женщины. «Сиэтл Мист» – «Омаха Харт» 16+
02.35 «Драмы большого спорта. Евгений Белошейкин» 12+
03.00 «Диалоги о рыбалке» 12+
03.25 Новости 0+
03.30 «Неизведанная хоккейная Россия» 12+
03.55 «Неделя лёгкой атлетики». «Мемориал братьев Знаменских» 0+
05.05 «Несвободное падение. Олег Коротаев» 12+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 19.00, 23.35 Сегодня
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) (6+
09.20, 10.30 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.40 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Детектив «ДЕЛЬФИН» (S) 16+
22.00 «ГЕНИЙ» (S) 16+
00.00 «ПЁС» (S) 16+
03.25 «ШАМАН» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Свадебный саван» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «Кризисный центр» 16+
19.00 «ЗА ВИТРИНОЙ». 5-я – 8-я серии 16+
22.50 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 4». 13-я и 14-я серии 16+
00.35 «ВЕЛИКОЛЕПНАЯ АНЖЕЛИКА» 16+
02.15 «Понять. Простить» 16+
03.05 «Порча» 16+
03.30 «Знахарка» 16+
03.55 «Верну любимого» 16+
04.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.15, 23.15 «ДУМА О КОВПАКЕ» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25 «Истребители Второй мировой войны». Док. сериал 16+
14.00 Военные новости 16+
14.15 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+
18.45 «Специальный репортаж» 16+
22.00 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
22.25 «Улика из прошлого». Премьера! 16+
01.00 «МИНУТА МОЛЧАНИЯ» 12+
02.35 «Нюрнберг». Док. сериал 16+
03.50 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 6–12 июнь

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Кайбер җитешсезлекләрне күрмәмешкә салышсагыз да ярый: сәламәтлекне һәм нерв күзәнәкләрен саклау кайчандагыга караганда да кирәгрәк хәзер. Атна уртасында көтмәгәндә генә керемле булып куярсыз. Булдыклылык һәм осталыгыгыз белән кемнәрнеңдер борынына чиертеп куанырсыз.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Борчу-мәшәкатьләр, ниһаять, узганда калып бара. Хәзер инде тынычланырга да мөмкин. Гәрчә әле төгәлләнмәгән эшләрегез байтак булса да. Хәер, бөтен көчне бер йодрыкка төйнәп, аларны җәһәт кенә башкарып чыгачаксыз һәм дә үзегезне мактап туя алмаячаксыз!

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Бу атнада барысы да планлаштырылган булсын. Шулай икән, бөтенесенә өлгерәчәксез. Әле тагын әйбәт кенә акча эшләү мөмкинлеге бирердәй тәкъдимнәр дә ишетеп сөенәчәксез.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Котыгызны алып торган бер эштә хезмәттәшегезнең ярдәме тиеп, шәп уңышка ирешерсез. Үзегезне чын мәгънәсендә кирәкле, файдалы кеше итеп тою мөмкинлеге бирер бу. Атна ахырында саграк булыгыз: тигез җирдә абынып, аяк-кулны авырттыру куркынычы бар.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Кызыклы вакыйгаларга, дуслар белән очрашу-күрешүләргә, кыска вакытлы сәфәрләргә бай атна. Бер яңа танышыгыз бик дәрәҗәле кеше булып чыгар. Ни хикмәт: танышуның икенче көнендә үк сезгә аның файдасы да тиеп куяр.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Кемнәрнеңдер проблемаларын хәл итәргә тырышып баш катырмагыз. Вакытыгызны бушка гына уздырачаксыз, рәхмәт сүзе дә ишетмәячәксез. Эштә мактаулы хезмәткәр булуыгыз белән тагын да күбрәк горурлану өчен искиткеч шәп сәбәпләр килеп чыгар.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Эштәге кайбер вакыйгалар күңелегезгә хуш килмәс. Ләкин бу хакта сүз әйтү ярамас. Атна ахырында кемнәрнеңдер серен очраклы гына ишетеп, үзегез өчен бик файдалы нәтиҗә ясарсыз.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Җитәкчегез, тырышлыгыгызны күреп, хезмәт хакын күтәрү турында уйлана башлар. Шәхси тормышыгызда да күңелне күтәрердәй, яңа планнар кору мөмкинлеге бирердәй хәлләр булыр. Өстәвенә әле бер танышыгыз шәп кенә керем чыганагы да тәкъдим итәр.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Бер хыялыгызның гамәлгә ашуына өмет-ышанычлар барлыкка киләчәк. Җитәкчегез белән бәхәсләшмәгез – үзегезгә зыян гына ясаячаксыз. Атна ахырында якыннарыгыздан бик матур хәбәрләр ишетәчәксез.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Бу атнада үзегезне ничек тә күрсәтергә кирәк. Җаен туры китереп, эштә алыштыргысыз кеше булып торуыгызга ишарәләү дә артык булмаячак. Хезмәттәшләрегез авызыннан ишетелгән мәгълүматтан файдаланып, менә дигән нәтиҗәгә ирешерсез.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Үзегездән канәгатьсезрәк булуларын тоярсыз, ләкин сәбәбен тиз генә белә алмассыз. Сезгә моны бер хезмәттәшегез җайлы гына төшендерер. Тиешле нәтиҗә чыгаргач, ниһаять, көйле генә эшли башларсыз.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Киеренкелектән, ыгы-зыгыдан качарга вакыт. Юкса эшегездә генә түгел, тормышыгызда да тискәре чагылыш табачак бу. Ял көннәрендәге вакыйгалар күңелегездә оялаган шикне юкка чыгарачак.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте, «Чүпрәле «Мелиорация» ПМК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры

ЯФИЗОВ
Фәгыйл Абдрахман улы

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЛАЗЕР ЯМАН ШЕШ ЧЫГАРМЫЙ

Яз-җәй айларында үзеннән-үзе тышкы-кыяфәтебезгә игътибар арта. Тагын да матуррак, гүзәлрәк буласы килә. Бу очракта, кул астында булган чаралар белән беррәттән, замана косметологиясендә кулланылган техникалар да ярдәмгә килә. Лазер эпиляциясе – шулар арасында иң киң таралган, популяры. Аны ничә яшьтән ясатырга ярый?

Лазер эпиляциясе яман шеш китереп чыгарамы? Табиб-дерматолог, косметолог Айрат КАМАЛОВ әлеге сорауларга ачыклык кертте.

▶ **НИДӘН ГЫЙБАРӘТ?** Лазер эпиляциясе кирәкмәгән җирдәге йон бөртекләрен юкка чыгару өчен ясала. Нәтиҗәсе аны ничә тапкыр ясауга, лазерның нинди төре кулланылуга бәйле. Хәзерге вакытта аның фотоэпиляция, диодлы лазер, александрит дигән төрләре кулланыла.

▶ **НИЧЕК УЗА?** Ул кирәкле зонага ультратавышлы гель тидерү хисабына уза. Лазер эпиляциясенең никадәр озак ясалуы аның кайсы җиргә башкарылуына бәйле. Әйтик, кайбер урыннарны 2–3 минутта чистартып булса, балтыр, бот, аякны артык йоннардан арындыру өчен 40 минут вакыт кирәк булырга мөмкин.

▶ **НИЧЕК ӘЗЕРЛӘНЕРГӘ?** Әлеге процедурага ничек әзерләнергә кирәклеге дә нәкъ менә лазерның кайсы төре кулланылачагына бәйле. Кайберсе алдыннан вак йоннарны кырырга яки, киресенчә, үстерергә кирәк.

▶ **ЛАЗЕР ЭПИЛЯЦИЯСЕ ЯМАН ШЕШ КИТЕРЕП ЧЫГАРА АЛАМЫ?** Лазер эпиляциясе яман шеш китереп чыгара алмый. Ник дигәндә, лазер утының асылы аның нәрсә тарафыннан булса да йотылуыннан гыйбарәт. Безнең очракта ул йон фолликуласы пигменты тарафыннан йотыла. Ул шушы фоллекулада кала, тән тиресенә үтеп керми. Лазерның бөтен энергиясе шушы йон төгеннән дә ары узмый. Тирегә үтеп керә калса, ул аны тулысынча яндырачак.

▶ **КОЯШТА КЫЗЫНГАННАН СОҢ ЯСАТЫРГА ЯРЫЙМЫ?** Яңа гына кояшта кызынган кешегә бер ай дәвамында лазер эпиляциясе ясатырга ярамый. Ник дигәндә, болай эшләгәндә тән тиресе пешәргә мөмкин. Сүз уңаеннан, лазер эпиляциясе ясаткач, бер ай кояшта кызынырга, бу урынны кырырга да ярамый.

▶ **КЕМНӘРГӘ ЯСАТУ ТЫЕЛА?** Хроник чирләр баш калкыткан чорда, йөкле хатын-кызларга, тире авыруларыннан интеккән, яман шеш диагнозы куелган кешеләргә лазерлы эпиляция ясату тыела. Миңе булган кешеләргә куркырга кирәкми. Лазер эпиляциясе ясаганда белгеч андый урыннарга кагылмаячак.

▶ **ЯШЬ ЧИКЛӘВЕ БАРМЫ?** Лазер эпиляциясен 18 яше тулган һәркем ясата ала. Бу яшькә җитмәгәннәргә исә ул ата-ана рөхсәте белән, алар каршында ясала.

▶ **ИР-АТЛАР АРАСЫНДА ДА ПОПУЛЯРМЫ?** Хатын-кызлар белән чагыштырганда ир-атлар арасында лазер эпиляциясе ясатучылар сирәк. Әмма әлеге процедура көчле затлар арасында да популярлаша бара. Лазер эпиляциясе ясатучы ирләр саны елдан-ел арта.

Үзем сынадым

Геморройдан котылдым

Озак еллардан бирле геморройдан интегәм. Даруханәдән алган шәмнәр вакытлыча гына ярдәм итә. Күптән түгел түбәндәге рецептны табып, кулланып караган идем, файдасын күрдем. 100 г даруханәдә сатыла торган яшь имән кайрысы, 1 кап лавр яфрагы, 1 уч сары мәтрүшкә, 1 уч бөтнекнең барысын да бергә бутап, 10 л суда кайнатырга, аннары томалап куярга кирәк. Икенче көнне аны сөзеп, шушы суда утырасы булачак. Суның җылылыгы тән температурасыннан артмаска тиеш. Анда күпме озак утырсаң, шулхәтле әйбәтрәк. Бу процедураны 10 көн эшләргә кирәк.

Әлфия ИБРАҺИМОВА

Киңәш-табыш

ЙӨТКЕРҮДӘН – ЧӨГЕНДЕР ШИРБӘТЕ

Уртача зурлыктагы чөгендерне яхшылап юып, өстен капкач кебек итеп кисеп алыгыз. Зур булмаган чокыр ясап, 2 чәй кашыгы шикәр комы салыгыз. Микродулкынлы мичтә 5 минут пешереп алыгыз. 20–25 минут духовкада пешерсәң дә ярый. Барлыкка килгән сокны кичен, иң яхшысы – йоклар алдыннан эчегез. Беренче тапкыр эчкәннән соң ук файдасы тия.

ЧЕРКИ ТЕШЛӘП ИНТЕКТЕРСӘ

Серкә. 1/3 стакан суга бер аш кашыгы 9 процентлы серкә салып болгатабыз. Черки тешләгән урыннарны шушы катнашма белән эшкәртәбез. Серкә составындагы кислота кычытуны баса. Черки тешләгән урын кызармый.

Пакетлы чәй. Чәй пакетына кайнар су агызып суытабыз. Шуны черки тешләгән урынга 10–15 минутка куеп торабыз. Чәй составындагы танин дигән матдә черки тешләгән урынны ялкынсынудан саклый, кычытуны баса.

Сорау – җавап

БАЛА ГЫРЛАСА...

Балабызга 4 яшь. Йоклаганда гырлый торган гадәте бар. Салкын тигәндә генә түгел, көнаралаш шул хәл. Бала өчен нормаль күренешме икән бу?

Зәлия ИДРИСОВА. Казан

Сорауга Казан дәүләт медицина академиясенең госпиталь һәм хастаханә терапиясе кафедрасы доценты, медицина фәннәре кандидаты, терапевт **Регина АХУНОВА** җавап бирә:

– Безнең ил табиблары китергән мәгълүматлардан аңлашылганча, 4–6 яшьлек балаларның 10 проценты төнлә гырлый. Андыйлар малайлар арасында ешрак очрый. Балаларның гырлавын еш кына мышнау белән бутыйлар. Сабыйларда бу күренеш, гадәттә, борынга томау төшкәндә, йөткылык бизләре зурайганда, сулыш юлларында хилафлыклар булганда, артык авырлыктан интеккәндә күзәтелә. Бу халәт хроник дәрәҗәгә житсә, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ник дигәндә, вакытында дәваламаган очракта гырлау баланың физик һәм психик үсешенә йогынты ясый. Тора-бара ул баланың тәртибендә, укуда проблемалар китереп чыгарырга мөмкин.

Бу кызык!



Ит ашаган кешедә өмет бар

✓ Ит ашау сөякләрне ныгыта. Аны үз итүчеләр арасында остеопороз, сколиоз очраклары сирәгрәк очрый. Сөяк сыну куркынычы да 69 процентка кими. АКШ галимнәре күпсанлы тикшеренүләрдән соң шундый нәтиҗәгә килгән. Шуңа күрә белгечләр климакс чорына аяк баскан хатын-кызларга да күбрәк ит ашарга киңәш итә. Билгеле булганча, андый чакта гүзәл затларның организмындагы гормонаРь фон тамырдан үзгәрә. Шул рәвешле сөякләрнең ныклыгы да кими.

✓ Кош ите, бигрәк тә аның бот һәм балтыр өлешләре иң аз калорияле ит санала. Шуңа да карамастан, ит ашагач, шундук туклык хисе пәйда була. Кешенең алдагы 3–4 сәгатьтә бөтенләй тамагы ачмаска да мөмкин. Ашауга булган ихтыяҗ 10–15 процентка кими. Шуңа күрә ябыгырга уйлаган кешегә кош итенә өстенлек бирергә кирәк, ди Яңа Зеландия галимнәре.

✓ В витаминына бай булганлыктан, ит баш мие эшчәнлегенә дә уңай йогынты ясый. Даими рәвештә ит ашаган кешенең хәтере, фикерләү сәләте яхшыра. Ит ашау Альцгеймер кебек картлык авыруларын да кисәтә. Күптән түгел Бөекбритания галимнәре ит ашаган кешенең стресс һәм депрессияләргә дә сирәгрәк бирешүен ачыклаган.



ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

АДЫМ САЕН ШАУРМА: КУРКЫТМЫЙМЫ АШАРГА?

Шаурма «чыгышы» белән – Ливаннан. Камырга төрелгән ит һәм яшелчә кайчандыр анда кунак сые, иң затлы ризык булып саналган. Россиягә ул узган гасырның 80 нче елларында килеп керде. Шуннан бирле бездә шаурманың файдасы-зыяны турында бәхәсләрнең тынып торганы юк. Сәбәбе аңлашыла: бу ризык башлыча урам ларекларында – «шаурмичка»ларда сатыла. Ә анда төрле хәлләр булырга мөмкин...

Табиблар мактый

Диетологлар әйтүенчә, шаурма – файдалы ризык. Итендә аксым күп, яшелчәсе – клетчатка һәм витаминнар чыганагы, ә соусы белән ләвәше – тиз эшкәртелә торган углеводлар. Болар, тамакны туйдырып, асылда көн дәвамына җитәрлек көч-энергия бирә. Шуңа күрә шаурма – спортчыларның яраткан ризыгы да. Табиблар, шуны истә тотып, физик көч куеп эшләүчеләргә аны даими ашарга киңәш итә хәтта.

Кайда сатыла?

Ләкин әлеге күпләр яратып ашый торган ризык еш кына кайбер күңелсезлекләргә дә сәбәп булырга мөмкин. Иң элек шаурманың кайда сатылуына игътибар итәргә кирәк. «Куркыныч» урыннар – метро станцияләре, вокзал һәм базарлар. Халык күп йөри торган җирләрдә, экономияләү өчен, майлы ит (бер порциягә 120 грамм чамасы май) кулланалар. Ә мондый шаурманың ашкайнату органнарына «бәрүен» көт тә тор! Даими кулланганда, симерүгә китерергә һәм эчәкләрдә төрле авырулар китереп чыгарырга да мөмкин. Вокзал, базар тирәсендәге ларекларда пешекчеләр кетчуп белән майонезны кызганмый. Әлбәттә инде, иң арзанлысын, составында тозы күп булганын күп итеп салалар. Бу продуктлар, организмда сыеклыкны тоткарлап, кан басымын күтәрә. Шуны истә тотыгыз: санитария кагыйдәләре санга сугылмаганноктадан сатып алынган шаурма ашказанына «бәрү» генә түгел, хәтта йогышлы авырулар да «бүләк итәргә» мөмкин.

Майлы булмасын

Әлбәттә инде, шаурманың составына игътибар бирми калмагыз. Аны әзерләүдә майсыз ит – сыер, тавык яки күркә ите кулланылырга тиеш. Мондый иттә зарарлы майлар юк, аның каравы А, В, Е витаминнары һәм протеин күп. Көнчыгыш традицияләре буенча, шаурманың эчлеге сарык итеннән торырга тиеш. Алдан маринадланган ит катламнарын таякка пирамида кебек өеп, вертикаль грильдә әзерлиләр. Пешкәч, итне телемләп кисеп алалар. Бу ысулны бездә дә кулланалар.

Көнчыгышта майонез һәм кетчуп урынына һәрвакыт йогырт соусы кулланыла. Ә ул күпкә файдалырак һәм тәмлерәк. Ларекта шаурманың шундый соуста әзерләнгәнен алырга тырышыгыз.

ТАВЫК ИТЕ ҺӘМ ЯШЕЛЧӘ БЕЛӘН

Шаурма ясау остасы Усман Арилов рецепты

Кирәк булачак: *1 кап юка ләвәш, 180 грамм тавык филесы, 100 грамм кәбестә, 1 тозлы кыяр, 1 помидор, 2 аш кашыгы кетчуп яки томат пастасы, 2 аш кашыгы майонез, кыздыру өчен үсемлек мае, тәменчә тоз һәм борыч.*

Кәбестәне салам рәвешендә юка гына турыйбыз. Бераз тоз өстәп, болгатабыз. Кыярны ваклап шакмаклап турыйбыз. Суланып, ләвәшне йомшартмасын өчен помидорны орлыкларыннан чистартабыз һәм бокралап турыйбыз. Һәр бокраны дүрткә бүләбез. Соус ясау өчен майонезга кетчуп кушып, борыч сибәбез һәм болгатабыз. Тавык филесын юып, тизрәк кызсын өчен, уртасыннан ярып җибәрәбез (күбәләк рәвешен ала).

Табага үсемлек мае салып, тавык итенең ике ягын да 7шәр минут кыздырып алабыз. Суынгач, итне 1–1,5 см калынлыкта телемләп турыйбыз.

Шаурманы ясау. Ләвәш уртасына кәбестә, кыяр һәм томат кисәкләрен катламлап урнаштырабыз. Өстенә тавык ите тезеп, соус агызабыз. Ләвәшкә сеңмәсен өчен, соуска бер-ике кашык яшелчә катнашмасы өстибез. Ләвәшнең кырыйларын эчкә бөкләп, рулет рәвешендә төрәбез.

Шаурманың «тышкы кыяфәте»нә дә игътибар итегез. Ләвәше – аксыл да, көйгән дә, эчлеге әз дә, артык күп тә булмасын. Бу билгеләр аның сыйфатсызлыгына ишарәли. Ә «ләвәше сырдан ясалган» дип, купшы сүзләр белән «төреп» сатылганнарына да саграк карагыз. Мондый очракларда камыр өчен сыр яки башка «тәмле әйбер» урынына химик тәмләткечләр генә кулланыла.

Һәм соңгысы. Арзанлысына кызыкмагыз. Беркем дә бәяне тикмәгә генә арзан куймый. Очсызлы ризык гадәттә искергән иттән яки бозыла башлаган яшелчәдән әзерләнә.

Бакчачыга

Пычкы чүбен куллана беләсезме?

Кайбер бакчачылар ашлама сыйфатында пычкы чүбе куллана. Ләкин аның файдасына караганда зыяны күбрәк булырга – туфрак ундырышсызга әйләнергә мөмкин.

Пычкы чүбендәге микроорганизмнар, җирдәге азотны «ашап», аны ярлыландыра. Хәер, пычкы чүбе кызыл балчыклы яки комлы туфрак өчен бик әйбәт ашламага да әйләнергә мөмкин. Ләкин аны башта минераль яки органик ашлама белән эшкәртергә кирәк. Моның өчен 10 литр суга 150 грамм суперфосфат, 100 грамм аммиак селитрасы һәм 50 грамм хлорлы калий салып эремә ясарга. Шуннан эремәне пычкы чүбенә сибәргә. Бер чиләк эремә өч чиләк пычкы чүбенә җитә.

Пычкы чүбеннән компост ясарга да була. Ә терлек астына җәю өчен кулланылган пычкы чүбен эшкәртмичә генә бакчага кертергә мөмкин.

Укучы хаты

«Итәкле» кәбестә

Күршемнең киңәшен тыңлап, кәбестәнең аскы яфракларын – «итәге»н йолкып тору гадәтенә ияләшеп киткән идем. Янәсе, кучән шулай тизрәк «авырлык җыя»... Ләкин бу ысулның файдасы әллә ни сизелмәде бугай.

Соңыннан гына белдем: кучәннең әйбәт үсүе өчен аскы яфраклары кирәк икән бит! Әле кечкенә булганда, кәбестәгә алар туклыклы матдәләр биреп тора, кайбер корткычлар һәм авырулардан саклый. Моннан тыш, яфракларны йолкыганда, кучән өчен кирәкле согы агып чыга. Өстәвенә «ярасы» аша инфекция дә кереп калырга мөмкин.

Шуңа күрә хәзер кәбестә үсеп утырган бер мәлдә бары тик корыган, корткычлар зарарлаган яфракларын гына йолкып ташлыйм. Ә «итәге»н кәбестә үсеп туйгач кына «салдырам». Кучән сыйфатына искиткеч әйбәт йогынты ясый бу.

Әлфинур НӘҖМЕТДИНОВА. Казан

Белсәң, зыян итмәс

ТУҢМАГЫЗ!

Җылылык бирү тукталгач, юыну бүлмәсен җылытуның бер сере бар. Душ кабинасы стеналарына эчке яктан кайнар су бөркергә кирәк. Болай эшләгәндә, «җылылык экраны» һәм кайнар пар барлыкка килеп, тән рәхәт җылылыкка күмеләчәк.

КЕЛӘМ ЧИСТАРТУ СЕРЕ

Синтетик келәмне тузан суырткыч белән чистартканда, электрлану сәбәпле, вак чүпләр тиз генә «йотылмый». Шуңа күрә щетканы кат-кат йөртергә туры килә. Келәмгә антистатик бөркегән очракта, эшегез бермә-бер җиңеләячәк.

КАРТЛЫК – ЗУР ҖАВАПЛЫЛЫК

Картлык шатлык түгел, ди халык. Ләкин, уйлап карасаң, гомер көзенә җитә алу үзе үк шатлык бит. Яшьлек һәркемгә диярлек бирелә, картлык сайлап кына килә. Шушы чорны лаеклы рәвешле, мәгънәле итеп уздыруның сере нидә? Картлыкка ничек әзерләнергә?

«Рөстәм» мәчете имам-хатыйбы Исмәгыйль хәзрәт БИККИНИН белән шул хакта сөйләшәбез.

:: Исмәгыйль хәзрәт, картлык – шатлыкмы?

– Моннан 30 ел элек 40 яшьлек кешене дә картлыкка авышкан дип әйтергә була иде. Хәзер бу яшьтә кеше тормыш башлап кына җибәрә әле. Шуңа күрә бүген картлык 70 яшьтән башлана дип әйтергә кирәк. Өлкән яшьнең билгеләре бар. Шуның беренчесе – ак чәч. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ак чәч турында: «Үзегезнең ак чәчләрегезне йолкымагыз. Чынлыкта ул кыямәт көнендә сезгә бер нур булачак. Ул сезгә бер игелек белән язылачак һәм булган хаталарыгыз гафу ителәчәк. Кыямәт көнендә дәрәҗәләрегез шуның белән үсәр», – дигән. Ак чәчләр – безгә картлык килүгә ишарә. Шушы вакытка кеше үзенә күрә бер җаваплылык белән килергә тиеш. Ул гомерен төгәлләгән вакытта үзеннән соң нинди эзләр калдырачак? Сәламәтлеге, яшьлеге киткәч, Аллаһ каршына ул үзенең хезмәте, җәмгыятькә, гаиләсенә, Аллаһы Тәгалә каршындагы хезмәте белән килеп басачак.

Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә: «Аллаһы Тәгалә кыямәт көнендә шул кешеләр белән сөйләшмәс, кайсы инде өлкән яшькә җитеп, фәхеш гамәлләрдә булса. Шулардан берсе ул – зина һәм ачыктан-ачык гөнаһ кылып, урамда үзен тәртипсез хәлдә күрсәтеп, җәмгыятьне бозып йөрү», – диелә. Ни сәбәптән? Чөнки өлкән яшьтәге кеше тормыш тәҗрибәсе ала, белеме бар, шуңа да карамастан, үз кулы белән үзен шундый түбәнчелеккә төшерә. Андыйлар, акылсыз гамәлләр кылып, кирәкмәгән сүзләр сөйләп, кайсылары үзләрен сабый бала кебек тота башлый.

Шул ук вакытта ислам дине өлкәннәргә карата да таләпләр куя. Алар үзен дәрәҗәле, абруйлы тотарга, яшьләр белән мөнәсәбәт вакытында матур сүзләр кулланырга тиеш. Ул яшь кешене дә ярдәмгә килергә этәреп торачак. Шул рәвешле өлкән кешенең үз-үзен тотышы да ислам дине кануннарына туры килергә тиеш.

:: Картлыкка ничек әзерләнергә?

– Картлыкка гомер буе әзерләнәбез. Бу иң элек ата-ананың баласына яхшы исем бирүеннән башлана. Ул кешегә, өлкән яшькә җиткәч, матур итеп эндәшерлек күркәм булырга тиеш. Алга таба белем алу, һөнәр үзләштерү кебек дөньяви эшләр белән беррәттән дини белем дә алырга кирәк. Өлкән яшькә җиткәндә кешенең гомер сандыгында намаз, ураза, зәкят, хаҗ дигән байлыклар булырга тиеш. Утырып бер дога да укый алмаган кешене ничек картлыкка әзерләнгән дип әйтеп булсын? Без картлыкка сәламәтлек ягыннан да әзерләнергә тиеш.

Аны сакларга кирәк. Кеше өлкән яшькә барып җиткән вакытта мәчеттә, мәхәлләдә: «Без андый кешене белмибез», – дигән сүз яңгырамаска тиеш. Ислам дине безне көн-төн мәчеттә утырырга мәҗбүр итми. Ләкин җомга намазына, ике гаеткә бару мөһим булып тора. Картлыкка әзерләнү акча, мал-мөлкәт туплау гына түгел. Моңа дини яктан үзеңне дә, тирә-юньдәге якыннарыңны да, туганнарыңны да әзерләргә кирәк. Бу дөньядан киткәч, без балаларыбызның догасын өмет итәчәкбез. Алар моны эшли беләме? Картлык көнгә әзерләнгәндә әнә шуларны да истә тотарга кирәк.

:: Кайберәүләр картлыгын, вакыт узу белән сәламәтлеге какшавын, егәре бетүен кабул итә алмый. Аллага канәгатьсезлек белдерергә дә күп сорап тормыйлар. Бу гөнаһ саналамы? Ни өчен?

– Билгеле, яшь барган саен, сәламәтлек какшый. Тимер дә туза бит. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Безнең өммәтебезнең яшәү озынлыгы 60–70 ел булачак», – дигән. Пәйгамбәребез үзе дә 63 яшькә кадәр яшәгән. Аның да сәламәтлегенең какшап алган вакытлары булган. Вафат булыр алдыннан җәмәгать каршына намазга да чыга алмый башлаган. Шуңа күрә сәламәтлекнең какшавы – тормышыбызның бер әйләнеше. Шелтә белдерсәң-белдермәсәң дә, тәнең картаячак. Ләкин кеше гел хәрәкәттә булса, дөрес туклanса, гел максат куеп, нидер эшләп, гел нәрсәдер өйрәнеп, ятлап торса, башы да эшләячәк, яшәү дәрте дә сүнмәячәк. Нәтиҗәдә картлык хисе дә китәчәк. Мәчеткә эзне суытмаган кеше дә картлык килгәнгә борчылып, төшенкелеккә бирешми. Картлык җиткәнгә Аллаһы Тәгаләгә шелтә белдерү – хата. Рәхимле, шәфкатьле Раббыбыз безгә болай да күпме мөмкинлекләр – сәламәтлеген, гомерен, аның озынлыгын бирә. Шуңа күрә без бу мәсьәләдә Аллаһы Тәгаләгә шөкер итәргә тиешбез.

:: Карт кешегә бала акылы керә, диләр. Бу чынлап та шулаймы?

– Картлыкта бала акылы керми, өлкән кешенең күңеле нечкәрә. Иман, дин ягыннан да аның күңеле нечкәреп китә. Яшь кеше тоя алмаган әйберләрнең – шул ук намазның, зекернең, балаларын, оныкларын кочаклап үбүнең ләззәтен, ризык тәмен өлкән кеше башкача тоя. Шушы күңел нечкәлеге аркасында алар Ходайга да шөкер итә, балаларга, тирә-юньгә карата да рәхимлерәк, игътибарлырак була башлыйлар. Ләкин күңел нечкәрүнең икенче ягы да бар. Андый кеше тиз үпкәли. Шушы вакытта без, яшьләр, өлкәннәргә рәхимлек белән карарга тиеш. Аларның хәтерсезлеген, таркаулыгын да сабырлык белән кабул итәргә кирәк.

:: Картайгач, кадерсезгә, кирәксезгә әйләнүчеләрне күреп, йөрәк әрни. Аларның күргән кыенлыклары гөнаһларыннан арынырга ярдәм итә, дип тә әйтәләр. Бу чыннан да шулаймы?

– Кадерсезлекнең сәбәпләре төрле булырга мөмкин. Яшьлектәге гөнаһлары аркасында картлык көнендә ялгыз калучылар да була. Кеше гомере буе сәламәт яшәү рәвеше алып бармаган булса, картлыгында саулыкка туймавы да бар. Ул үзе яки башкалар гаебе белән картлыгында фәкыйрь, мескен хәлдә калырга да мөмкин. Сугыш башлану яки якынын югалтуы аркасында ялгыз калучылар да бар. Монда эш гөнаһта гына да түгел. Кеше өстенә авырлыклар төшкәннән соң, сабырлыгы, авырлыкларны Аллаһы Тәгаләгә тел-теш тидермичә, сыкранмыйча, балаларына рәнҗемичә, тормышын алып бара алса, ул гөнаһлардан пакьләнә. Аның Аллаһы Тәгалә каршында дәрәҗәсе үсә.

:: Өлкәннәр кайчак яшьләр арасын, гаиләләрне дә бозарга мөмкин. Мондый вакытта яшьләргә үзләрен ничек тотарга?

– Өлкәннәр бу адымга улын яки кызын тормыш иптәшенә көнләве аркасында бара. Күп очракта алар моны начар нияттән дә эшләми. Бу дөньяда төрле гөнаһлар бар. Ләкин шулар арасында иң зурысы – туганлык җепләрен өзү. Яшьләр арасына кереп, өлкәннәр шушы туганлык җепләре өзелүгә сәбәпче булырга да мөмкин. Ләкин шул ук вакытта, әгәр, әйтик, кияү яки килен кешедингә каршы килеп, гөнаһта, фәхешлектә булса, яман гадәт яки сектага кереп китсә, ата-ананың балалар арасына керергә хаклары бар. Чөнки шул рәвешле алар балаларын саклый. Андый хәлләр килеп чыкмасын өчен ата-ана баласының кем белән гаилә коруына алдан игътибар итәргә тиеш. Шул ук вакытта ир белән хатын бербереннә хөрмәт итеп, яратып, тәртипле генә яшәсә, әтиәнисенә ике арага тыкшынырга ирек бирмәячәк, шул ук вакытта алардан ераклашмаячак та. Моны өлкәннәргә иплəп кенә аңлатырга кирәк.

:: Картайгач, яшьләрчә киенеп, җете бизәнеп, җырлып-биеп йөрүләр гөнаһ түгелме?

– Җырлап-бию гөнаһ түгел. Бу очракта аның кайда эшләнүе мөһим. Гаиләң, якыннарың каршында җырлап бисең икән, бу гөнаһ түгел. Ләкин син картаймыш көнендә бизәнеп, урам буйлап җырлап-биеп йөрсәң, әлбәттә, моны дин хупламый. Өлкән кеше дигәч, күз алдына «мәчет», «мөнбәр», «намаз» дигән төшенчәләр килеп баса. Бу кеше артист яки җырчы булса, ул – икенче мәсьәлә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Хикмәт

✓ Мөхәммәд (с.г.в.) бер сәхабәгә үзенең исемен алмаштырырга киңәш иткән. Сәхабәнең исеме «моңсу» мәгънәсенә туры килгән. Ул сәхабә алмаштырмаган һәм, риваять буенча, тормышын да моңсу яшәгән.

✓ Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Әгәр мөэмин кеше, һичбер гозерсез, аз гына булса да ялганласа, аның ике фәрештәсе аннан чыккан сасы истән качып, берьелдык юл ераклыгына ерагаер. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә шул кечкенә ялганы өчен генә дә аның сиксән хаталы эшенең гөнаһын язар, ә ул хаталы эшенең иң кечкенәсе дә берәүнең анасы белән зина кылуы кебек булыр», – дигән.

Укучы соравы

Ләгънәт төшәме?

– Альцгеймер кебек картлык авыруыннан интеккән карт кешенең каргышы төшәме?

С. ГӘРӘЕВА. Кукмара

Сорауга Исмәгыйль хәзрәт БИККИНИН җавап бирә:

– Бу очракта, Альцгеймер вакытында гына түгел, гомумән, өлкәннәрнең ләгънәте турында фикер йөртергә кирәк. Без алар белән аралашмасак, күрешмәсәк, хәлләрен белешмәсәк, аларның ләгънәте дә безгә төшми. Еш кына кеше үзенең тирәсендә булган кешеләргә карата рәнҗи. Көнкүрешне бергә алып баралар да, берәр нәрсә ошамаса, ләгънәт яудырулар башлана. Пәйгамбәребез ләгънәт кылучыларны сөймәде. «Ләгънәт кылу, сүгенү, акырышып-бакырышып сөйләшү безнең мөселманнарга туры килми», – дигән ул. Шуңа күрә өлкәннәрнең догалы булуы – нәсыйхәт. Шул ук вакытта өлкәннәр белән бер түбә астында яшәгән яшьләр дә шуны истә тотарга тиеш: без аларга карата игътибарлы булсак, хәтта алар авыр сүз әйтеп куйсалар да, ул кабул булмый. Монда аларның үз акылында булу-булмавы мөһим түгел. Ләкин аларны рәнҗетеп яшәсәк, аларның ләгънәте барып ирешә. Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә: «Золым астында яшәгән кешенең догасы да, ләгънәте дә кабул була», – дигән.

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

РӨСТӘМ ЕГОРОВ:

«МИНЕ МИҢГОЛ АБЫЙНЫҢ ЯШЬ ЧАГЫНА ОХШАТАЛАР»

Бүген без «Ни хәл?» сәхифәсенә кунакка талантлы яшь җырчы Рөстәм ЕГОРОВны чакырдык. Күпләр аны Миңгол Галиевнең яшь чагына охшата. Баксаң, Рөстәмнең Ижаудан Казанга күченеп килүе дә аның белән бәйле икән.

:: Ни хәл?
– Әкрен генә. Быел Казан музыка көллиятен тәмамлыйм, инде ике атна гына калып бара. Бик тиздән диплом алабыз. Әлегә, мәш килеп, имтиханнарга әзерләнәбез.

:: Татар җырына, моңына мәхәббәтнең тамырлары кая барып тоташа?
– Заманында әнием ягыннан әбием бик матур җырлаган. Мөгаен, җырлау сәләте, җыр-моңга мәхәббәт аннан күчкәндер. Әтиемнең әтисе бик оста итеп гармунда уйнаган. Бу да эзсез югалмаган – үзем өчен генә булса да, баянны кулга алгалыйм.

:: Рөстәм, белүемчә, син – Ижау егете. Ә нигә Казанга килергә булдың?
– Үземне белгәннән бирле музыка дөньясында «кайныйм» мин. Ижауда яшәгәндә, баян классы буенча музыка мәктәбен тәмамладым, бездә узган чараларны, бәйге-фестивальләрне калдырмадым диярлек. Мин туып-үскән шәһәрдә татарлар бик күпләп яши. Араларында активлары да җитәрлек. Ләкин минем татар җыр сәнгатен, аның тамырларын өйрәнәсем килде.

Ә Казанга килүем остазым Миңгол Галиев белән бәйле. Ижауда узган мөнәҗәтләр бәйгесенә килгән иде ул. Сәхнәгә чыгар алдыннан тамаша залында минем каршымда утырды һәм үз чыгышын видеога төшерергә кушты Миңгол абый. Язмыш үзе булгандыр – шулай танышып киттек. Сәхнә артында җырлавымны тыңлап карады да Казанга чакырды. Килдем. Дөресрәге, әнием белән бергә күчендек. 9 нчы сыйныфны тәмамлаганда, яшем кечкенә иде әле, әнинең ялгызымны җибәрәсе килмәде. Яхшы эшен ташласа ташлады, әмма минем янымда булды.

:: Сине Миңгол абыйга охшатучылар күп. Җырлавың, сәхнәдә тотышыңны да.

– Әйе, мине Миңгол абыйның яшь чагына охшаталар. Укытучыларым да, мине беренче күргән кешеләр дә шулай ди. Мин моның белән горурланам. Миңгол абый җан авазы, күңеле белән җырлый ул. Композиторның әйтәсе килгән фикерен җиткерә белә. Шуңа күрә тамашачыга да бик нык тәэсир итә.

:: Монда килгәч, нинди кыенлыклар белән очраштың һәм үзең өчен нинди мөмкинлекләр ачтың?
– Иң күзгә ташланган кыенлык тел булгандыр. Рус мәктәбендә укыгач, татар теле онытыла язган. Әмма сәхнә теленең нечкәлекләрен өйрәткән остазыбыз Инсаф Абдулла ярдәме белән хәлләр үзгәрде дияргә була. Аның дәресләре бик ярдәм итте миңа. Аннан соң, татар музыкасы әдәбияты минем өчен зур ачыш булды. Рөстәм Яхин, Фәрит Яруллин, Нәҗип Җиһанов кебек композиторларның иҗатын бөтенләй яңа, гаҗәеп яклары белән ачтым. Ә өченче курста белем алганда, Әлфия Айдарская белән таныштым. Ул миңа Сара Садыйкованың бик күп җырларын бирде. Шул исәптән, бөтенләй ишетелмәгән җырларын да. Гомумән, Әлфия Газизовна белән аралашу – үзе бер зур мөмкинлек һәм һәрвакыт зур ачыш ул.

Блиц-сораштыру

– Яраткан җырчыларың?
– Илһам Шакиров, Таһир Якупов, Рафаэль Сәхәбиев.
– Ә хәзерге җырчылардан?
– Зәйнәб апа Фәрхетдинованың җырлавын үз итәм, Ришат Төхвәтуллинның да иҗаты ошый.
– Заманча җырларга мөнәсәбәтең?
– Тыңламыйм. Аларның мәгънә ягы аксый. Кыскасы, бер көнлек җырлар. Сүзләрен дә, көен дә үзе язып, ул җырны үзе башкарган җырчыларны да кабул итә алмыйм. Барысын да димим. Әмма җырга көй иҗат итү өчен композитор дигән исемең, белемең булырга тиеш.
– Сиенчә, тавышыңның көче нәрсәдә?
– Тыңлаучының күңеленә үтеп керә һәм җырның мәгънәсен җиткерә алуда.

:: Киләчәккә нинди планнар, ниятләрең бар?
– Мәшһүр композиторларыбызның әсәрләрен җыентыкка туплыйсым килә. Аларның бит моңарчы беркайда да күренмәгән, ишетелмәгән иҗат җимешләре бар. Шуларны табып, кирәгенчә эшкәртеп, китап итеп бастырырга телим. Бу ниятем Әлфия Айдарская белән аралашканда, аның бу өлкәдә куйган хезмәтен күреп туды. Миңа калса, татар сәнгатен пропагандалауның отышлы юлларының берсе бу. Ижауда укыганда мондый җыентык-китапларны табу проблема иде. Ниятләгән эшемне ахыргача җиткерә алсам, иң беренче эш итеп, туган шәһәремә алып кайтыр идем.

Әлбәттә, җырлау, башкару осталыгын да үстерергә телим. Онытылып бара торган җырларны халыкка кайтарыр идем.

РӨСТӘМ ЕГОРОВНЫҢ ҖЫРЛАВЫН МОННАН ТЫҢЛЫЙ АЛАСЫЗ

Ә СИН ТАНЫЙСЫҢМЫ?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

*Газетабызның узган санында чыккан җырчы һәм җырларны беренчеләрдән булып Саба районының Яңа Мичән авылыннан **Сөмбелә Ибраһимова** танып алды. Афәрин! Бүләк – хуҗасында. Ә рәсемнәр астына без Илһам Шакиров башкаруындагы «Һаман яратам», Рифат Зариповның «Әнкәй алмалары» һәм Ринат Рәхмәтуллин репертуарыннан «Чакыр гына мине» җырларын яшергән идек.*

Аның йөрәге сине үз иткән. Артык сораулар бирмә, сәбәбен сорама, әмма яратуымны бел, ди җырчы.

Чишмә дә шул ук, тугай да үзгәрмәгән, йолдызлар белән ай да. Ләкин без үзгәрдек шул, ди җырчы.

Бу җыр сагышлы мәхәббәт турында. Син инде аның хәтерендә күптән юк, төшенә кереп интектермә.

8 июнь | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00, 00.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия» 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00, 01.35 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00, 23.50 «Соотечественники» 12+
00.15 «Каравай». Хромка. Живая старина 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
09.40 «Ачыктан-ачык» (субтитрлы) 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Баяның кулыннан төшмәде». Татарстанның халык артисты Рәшит Мостафин турында телеочерк 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
04.15 «Баяның кулыннан төшмәде». Татарстанның халык артисты Рәшит Мостафин турында телеочерк 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.25 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
21.45 «ТОБОЛ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков, Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Ольга Будина в телесериале «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
02.45 Мария Порошина, Вячеслав Разбегаев, Владимир Епифанцев. «ПО ГОРЯЧИМ СЛЕДАМ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.35, 15.05, 17.30, 20.55 Новости
06.05, 20.00, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.40 Специальный репортаж 12+
09.30 Футбол. Лига чемпионов. «Барселона» (Испания) – «Рубин» (Россия) 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир.
13.00, 15.10 «АПОСТОЛ» 16+
16.10, 17.35 «РОК-Н-РОЛЬЩИК» 16+
18.35 Смешанные единоборства. UFC. Лучшие бои Валентины Шевченко 16+
19.30 Матч! Парад 0+
21.00 Профессиональный бокс. Дмитрий Дюон против Брейдиса Прескотта. Прямая трансляция из Москвы
23.40 «Есть тема!» 12+
00.00 «СКАНДИНАВСКИЙ ФОРСАЖ: ГОНКИ НА ЛЬДУ» 16+
01.45 Американский футбол. Лига легенд. Женщины. «Лос-Анджелес Темптейшен» – «Атланта Стим» 16+
02.35 «Драмы большого спорта. Мария Комиссарова» 12+
03.00 «Диалоги о рыбалке» 12+
03.25 Новости 0+
03.30 «Неизведанная хоккейная Россия» 12+
03.55 Профессиональный бокс. PRAVDA FC. Вагаб Вагабов против Дамала Шарафутдинова. Вагаб Вагабов против Даниила Шаталова. Трансляция из Москвы 16+
05.05 «Несвободное падение. Кира Иванова» 12+

НТВ

04.45 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) (6+
09.20, 10.30 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.40 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Детектив «ДЕЛЬФИН» (S) 16+
22.00 «ГЕНИЙ» (S) 16+
00.00 «ПЁС» (S) 16+
03.30 «ШАМАН» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Проклятые деньги» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «Кризисный центр» 16+
19.00 «ЗА ВИТРИНОЙ» 16+
22.55 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 4». 15-я и 16-я серии 16+
00.35 «АНЖЕЛИКА И КОРОЛЬ» 16+
02.15 «Понять. Простить» 16+
03.05 «Порча» 16+
03.30 «Знахарка» 16+
03.55 «Верну любимого» 16+
04.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.25, 13.25, 18.45 «Спец. репортаж» 16+
09.40, 23.15 «ДУМА О КОВПАКЕ» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир» 16+
13.40 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
14.15 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+
22.00 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
22.25 «Секретные материалы» 16+
00.40 «В ДОБРЫЙ ЧАС!» 12+
02.15 «Нюрнберг». Док. сериал 16+
03.30 «Москва фронту». Док. сериал 16+
03.50 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+

9 июнь | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Казаннан – казанга» 12+
18.00 «Юлчы» 6+
19.00, 20.00, 01.05 «Точка опоры» 16+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Лилиана Терегулова. Делай добро и бросай в воду 12+
00.40 «Каравай». Новый яблоневый сад творит добро 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Башваткыч» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БиТ шоу» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Ирекле күбәләкләр». Татарстанның халык артисты Луара Шакирҗанова турында телеочерк 6+
15.30 «Халкым минем» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Ирекле күбәләкләр». Татарстанның халык артисты Луара Шакирҗанова турында телеочерк 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «ТОБОЛ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков, Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Ольга Будина. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР» 12+
02.45 Мария Порошина, Вячеслав Разбегаев, Владимир Епифанцев. «ПО ГОРЯЧИМ СЛЕДАМ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.35, 15.05, 17.30, 20.55 Новости
06.05, 17.35, 20.15, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.40 Специальный репортаж 12+
09.30 Футбол. Лига чемпионов. «Спартак» (Москва, Россия) – «Арсенал» (Англия) 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.10 «АПОСТОЛ» 16+
16.10 Профессиональный бокс. Лучшие бои Дмитрия Кудряшова 16+
18.10 «Неделя лёгкой атлетики». Прямая трансляция из Москвы
21.00 Профессиональный бокс. Василий Войцеховский против Гасана Гасанова. Прямая трансляция из Москвы
23.40 «Есть тема!» 12+
00.00 «ПОЛНЫЙ НОКДАУН» 16+
01.45 Американский футбол. Лига легенд. Женщины. «Омаха Харт» – «Нэшвилл Найтс» 16+
02.35 «Драмы большого спорта. Людмила Пахомова» 12+
03.00 «Диалоги о рыбалке» 12+
03.25 Новости 0+
03.30 «Неизведанная хоккейная Россия» 12+
03.55 «Неделя лёгкой атлетики». Трансляция из Москвы 0+
05.05 «Несвободное падение. Елена Мухина» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) (6+
09.20, 10.30 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.40 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Эдуард Флёров. «ВИРУС» (S) 16+
00.00 «ЧП. Расследование» (S) 16+
00.25 «Поздняков» (S) 16+
00.40 «Мы и наука. Наука и мы» (S) 12+
01.30 «ПЁС» (S) 16+
03.15 «ШАМАН. НОВАЯ УГРОЗА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Взрослые дочери» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «Кризисный центр» 16+
19.00 «ЗА ВИТРИНОЙ». 13-я – 16-я серии 16+
22.50 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 4». 17-я и 18-я серии 16+
00.35 «НЕУКРОТИМАЯ АНЖЕЛИКА» 16+
02.00 «Понять. Простить» 16+
02.50 «Порча» 16+
03.15 «Знахарка» 16+
03.40 «Верну любимого» 16+
04.05 «Давай разведёмся!» 16+
04.55 «6 кадров» 16+ Скетч-шоу.
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.30, 13.25, 18.45 «Специальный репортаж» 16+
09.45, 23.15 «ДУМА О КОВПАКЕ». «КАРПАТЫ, КАРПАТЫ...» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.40 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
14.15 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+
22.00 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
22.25 «Код доступа» 12+
00.35 «ПРИКАЗ: ОГОНЬ НЕ ОТКРЫВАТЬ» 12+
02.05 «ПРИКАЗ: ПЕРЕЙТИ ГРАНИЦУ» 12+
03.35 «Алексей Брусилов. Служить России». Док. фильм 12+
04.20 «Хроника Победы». Док. сериал 16+
04.45 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
04.55 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+

10 июнь | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». Телесериал 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Классный час» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00, 03.00 «Аулак өй» 6+
16.30 «Әдәби хәзинә » 6+
18.00 «Туган җир» 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
21.00 «Юлчы» 6+
23.00 «ДВА ДНЯ, ОДНА НОЧЬ» 16+
00.30 «Каравай». Марийские традиции 6+
01.00 «УЕННАН УЙМАК 2» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 15.30 «Көн сәгате» 12+
09.40 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Кырыс җилле дала гөле». Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Гөлсем Исәнгулова турында телеочерк 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 00.40 «Калеб» 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Туган җир» 12+
19.35 «Заман көзгесе» 6+
20.05, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05 «Көн сәгате» 12+
01.05 У.Гибсон. «МОГҖИЗАДАН СОҢ» К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 12+
04.15 «Көн сәгате» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «Две звезды. Отцы и дети» (S) 12+
23.25 Премьера. Розамунд Пайк. «АФЕРИСТКА» (S) 18+
01.25 «Информационный канал» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
00.00 Полина Агуреева, Андрей Щенников, Борис Каморзин, Евгения Дмитриева, Константин Желдин, Евгений Киндинов. «ДОЛГОЕ ПРОЩАНИЕ» 12+
02.00 Екатерина Редникова, Александр Дьяченко. «СЕМЬЯ МАНЬЯКА БЕЛЯЕВА» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.35, 15.05, 20.55 Новости
06.05, 18.25, 20.35, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.40 Специальный репортаж 12+
09.30 Футбол. Лига чемпионов. «Зенит» (Россия) – «Бенфика» (Португалия) 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.10 «АПОСТОЛ» 16+
16.10 Матч! Парад 0+
16.25 Футбол. Суперлига. Женщины. ЦСКА – «Чертаново» (Москва). Прямая трансляция
18.55 «Неделя лёгкой атлетики». Прямая трансляция из Москвы
21.00 Смешанные единоборства. AMC Fight Nights. Нариман Аббасов против Марифа Пираева. Прямая трансляция из Москвы
00.45 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Трансляция из Москвы 0+
01.45 Американский футбол. Лига легенд. Женщины. «Денвер Дрим» – «Сиэтл Мист» 16+
02.35 «Драмы большого спорта. Владимир Крутов» 12+
03.00 «Диалоги о рыбалке» 12+
03.25 Новости 0+
03.30 «Неизведанная хоккейная Россия» 12+
03.55 «Неделя лёгкой атлетики». Трансляция из Москвы 0+
05.05 «Несвободное падение. Оксана Костина» 12+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) (6+
09.20, 10.30 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.40 «ДНК» (S) 16+
18.00 «Жди меня» (S) 12+
20.00 Детектив «ВИРУС» (S) 16+
23.30 «Своя правда» с Романом Бабаяном (S) 16+
01.05 «Захар Прилепин. Уроки русского» (S) 12+
01.30 Квартирный вопрос (S) 0+
02.25 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
03.20 «ШАМАН. НОВАЯ УГРОЗА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Четвёртая отрицательная» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «Кризисный центр» 16+
19.00 «ГОЛОС АНГЕЛА» 16+
23.20 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 4». 19-я и 20-я серии 16+
01.00 «АНЖЕЛИКА И СУЛТАН» 16+
02.35 «Понять. Простить» 16+
03.25 «Порча» 16+
03.50 «Знахарка» 16+
04.15 «Верну любимого» 16+
04.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
06.10 «Предсказания: 2022» 16+

ЗВЕЗДА

06.25 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+
08.35, 09.20 «ОТ БУГА ДО ВИСЛЫ» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
11.45, 13.25, 14.05 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.40 «Легенды госбезопасности. Рэм Красильников. Охотник за шпионами». Док. фильм 16+
19.30 «ЦЕЛЬ ВИЖУ» 16+
21.15 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
22.15 «Легендарные матчи». «Чемпионат мира 1989. Хоккей. Финальный этап. СССР – Канада» 12+
01.20 «Кремль. Страницы истории». Док. фильм 12+
02.05 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
02.20 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+

11 июнь | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Синең Миннән Сәлам». Музыкаль котлаулар 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12 +
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Татар халык җырлары» 0+
11.30 «Казаннан – казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
13.30 «Акча корты». «Мунча ташы» эстрада театры тамашасы 12+
17.00 «Әйдә, шаяРТ!» 12+
18.00 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «Кунак БиТ шоу». Бәширә Насыйрова 12+
23.00 «МАДАМ» 16+
00.30 «Вехи истории». Трагические 20-е 12+
00.55 «Каравай». Хоровод дружбы 6+
01.20 «БИЧАРАКАЙ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Әйдә әле мәхәббәт иленә». Концерт 6+
07.00 «Синең Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Башваткыч» 12+
12.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Сабан туенда». Концерт-тамаша 6+
15.00 «Синең Миннән Сәлам» 6+
17.10 «Казаннан – казанга» 12+
17.45 «Халкым минем» 12+
18.15 «Башваткыч» 12+
19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Очрашулар эзләп». Габделфәт Сафин концерты 6+
22.15 М.Кәрим. «КЫЗ УРЛАУ». М.Гафури исемендәге башкорт дәүләт драма театры спектакле 12+
00.20 «Тынлык эченддәге зилзилә». Рәмис Аймәтнең юбилей концерты 6+
03.00 «Башваткыч» 12+
03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.05 «Халкым минем» 12+
05.30 «Нәсыйхәт» 6+

1 КАНАЛ

06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «Порезанное кино» 12+
11.20 «Видели видео?» 0+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» 0+
14.10 «Янтарная комната» 12+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 «Янтарная комната» 12+
16.30 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 «Пусть говорят» 16+
19.55 «На самом деле» 16+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.00 Лига Бокса. Интерконтинентальный Кубок. Россия – Африка. Прямой эфир из Москвы (S)
00.30 «Олег Видов. С тобой и без тебя» 12+
01.25 «Наедине со всеми» 16+
03.40 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00, 17.00, 20.00 Вести
12.00 Владимир Машков, Сергей Маковецкий, Владимир Меньшов, Михаил Пореченков, Светлана Крючкова, Константин Лавроненко. «ЛИКВИДАЦИЯ» 16+
18.00 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
21.00 Премьера. Елена Великанова, Юлия Галкина, Екатерина Копанова, Виолетта Давыдовская, Владимир Фекленко, Михаил Пшеничный, Алексей Демидов. «ВЫ МНЕ ПОДХОДИТЕ» 12+
00.40 Александр Балуев, Сергей Маковецкий и Елизавета Боярская. «ПЁТР ПЕРВЫЙ. ЗАВЕЩАНИЕ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Джоуи Бельтран против Фрэнка Тейта. Трансляция из США 16+
07.00, 08.55, 12.50, 18.20, 20.55 Новости
07.05, 12.55, 15.25, 20.30, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 23.40 «НА ВСЕХ ШИРОТАХ» 12+
13.25 Регби. Чемпионат России. 1/2 финала. Прямая трансляция
15.50 Автоспорт. Российская серия кольцевых гонок. Туринг. Прямая трансляция из Смоленска
16.55 Пляжный футбол. Белоруссия – Россия. Прямая трансляция
18.25 «Неделя лёгкой атлетики». Прямая трансляция из Москвы
21.00 Профессиональный бокс. PRAVDA FC. Дмитрий Кудряшов против Вагаба Вагабова. Прямая трансляция из Москвы
03.00 «Диалоги о рыбалке» 12+
03.25 Новости 0+
03.30 «Неизведанная хоккейная Россия» 12+
03.55 «Неделя лёгкой атлетики». Трансляция из Москвы 0+
05.00 Смешанные единоборства. UFC. Гловер Тейшейра против Иржи Прохазки. Валентина Шевченко против Тайлы Сантос. Прямая трансляция из Сингапура

НТВ

04.50 «Хорошо там, где мы есть!» 0+
05.15 «ЧП. Расследование» (S) 16+
05.40 «НЕ БОЙСЯ, Я С ТОБОЙ! 1919» 12+
07.30 Смотр (S) 0+
08.00, 10.00, 16.00 Сегодня
08.15 «Поедем, поедим!» (S) 0+
09.20 Едим дома (S) 0+
10.20 Главная дорога (S) 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым» (S) 12+
12.00 Квартирный вопрос (S) 0+
13.05 «Однажды...» (S) 16+
14.00 Своя игра (S) 0+
15.00, 16.15 Следствие вели... (S) 16+
18.00 «По следу монстра» (S) 16+
19.00 «Центральное телевидение» с Вадимом Такменевым
20.10 Ты не поверишь! (S) 16+
21.00 «Секрет на миллион». Светлана Журова (S) 16+
23.00 «Международная пилорама» (S) 16+
23.45 «Квартирник НТВ у Маргулиса». «Делай свое дело»: Сергей Воронов и Ко (S) 16+
00.55 «Дачный ответ» (S) 0+
01.45 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
02.15 «ШАМАН. НОВАЯ УГРОЗА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Предсказания: 2022» 16+
07.55 «ЖЕНСКАЯ ИНТУИЦИЯ» 16+
10.15 «ДЕВИЧНИК» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК» 16+
22.55 «МУЖЧИНА В МОЕЙ ГОЛОВЕ» 16+
01.00 «ГОРДОСТЬ И ПРЕДУБЕЖДЕНИЕ». 1-я – 3-я серии 16+
03.35 «АНЖЕЛИКА – МАРКИЗА АНГЕЛОВ» 16+
05.30 «Лаборатория любви» 16+
06.20 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА-2» 16+
06.50, 08.15, 04.05 «31 ИЮНЯ» 12+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.30 «Легенды кино». Александр Михайлов 12+
10.15 «Главный день». «Атомный ледокол «Ленин» и физик Анатолий Александров» 16+
11.00 «Война миров». Док. сериал 16+
11.45 «Не факт!» 12+
12.15 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным». Премьера! 12+
13.15 «Легенды музыки». «История Гимна СССР и РФ» 12+
13.40 «Круиз-контроль». Премьера! 12+
14.10 «Морской бой». Премьера! 6+
15.10, 18.30 «ДРУЖИНА» 16+
22.20 «ЯРОСЛАВ» 16+
00.00 «Десять фотографий» 12+
00.40 «ОТ БУГА ДО ВИСЛЫ» 12+
02.55 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА...» 12+

12 июнь | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «ВОЛГА-ВОЛГА» 0+
08.00 «Адымнар» 12+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы- шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Аныктан-ачык». Айдар Файзрахманов 12+
11.10 «Татар халык җырлары» 0+
11.30 «Тархан». Историко-культурный конкурс для старшеклассников 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 12+
13.00 «Адымнар» 12+
13.30 З.Хәким. «УТРАУ». Әлмәт татар дәүләт драма театры спектакле 12+
16.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 «Видеоспорт» 12+
17.30 «Соотечественники» 12+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12 +
23.00 «ЛЕВ» 16+
01.00 «Ком сәгате» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
05.50 Татарстан хәбәрләре 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Ватандашлар» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
07.00 «Әниләр һәм бәбиләр». Концерт 6+
09.00 «Су буенда учак яна». Концерт 6+
10.00 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Нәсыйхәт» 6+
13.30, 03.30 Аманулла. «МОҢЛЫ ЯДКӘР». Г. Кариев исемендәге татар дәүләт яшь тамашачы театры спектакле 12+
15.50 Марат Мухин хитлары 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 12+
20.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
21.10 «Китмә, сандугач». Илһам Шакиров эздәре 6+
01.05 «Түгәрәк бәхет». Айдар Тимербаевның иҗат кичәсе 6+
05.35 «Шаян хәлләр» 12+

1 КАНАЛ

06.00 Новости
06.10 «ТОТ, КТО ЧИТАЕТ МЫСЛИ» («МЕНТАЛИСТ») (S) 16+
07.45 «Играй, гармонь любимая!» 12+
08.25 «Часовой» (S) 12+
08.55 «Здоровье» 16+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 К 350-летию Петра Первого. Фильм «Юность Петра» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Юность Петра» 12+
13.15 Фильм «В начале славных дел» 12+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 «В начале славных дел» 12+
16.05 Фильм «СКАЗ ПРО ТО, КАК ЦАРЬ ПЕТР АРАПА ЖЕНИЛ» 12+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Премьера. «Империя: Петр I» (S) 12+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «Империя: Петр I» (S) 12+
23.05 Николай Симонов, Михаил Жаров, Николай Черкасов «ПЕТР ПЕРВЫЙ» 12+
02.30 «Наедине со всеми» 16+
04.00 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.20 Анна Ардова, Ярослав Бойко, Анатолий Лобоцкий. «БЕРЕГА ЛЮБВИ» 12+
07.15 «Устами младенца»
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым»
09.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
12.00 Москва. Кремль. Церемония вручения Государственных премий Российской Федерации
13.00 Владимир Машков, Сергей Маковецкий, Владимир Меньшов, Михаил Пореченков, Светлана Крючкова, Константин Лавроненко. «ЛИКВИДАЦИЯ» 16+
17.00 Вести
18.00 Большой праздничный концерт, посвящённый Дню России. Прямая трансляция с Красной площади
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 Премьера. «А о Петре ведайте...» 12+
02.25 Ольга Красько, Дмитрий Марьянов в фильме «НОЧНОЙ ГОСТЬ» 12+
04.00 Анна Ардова, Ярослав Бойко, Анатолий Лобоцкий. «БЕРЕГА ЛЮБВИ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. UFC. Гловер Тейшейра против Иржи Прохазки. Валентина Шевченко против Тайлы Сантос. Прямая трансляция из Сингапура
08.00, 08.55, 12.50, 18.20, 20.55 Новости
08.05, 12.55, 15.25, 20.25, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 23.40 «НА ВСЕХ ШИРОТАХ» 12+
13.25 Регби. Чемпионат России. 1/2 финала. Прямая трансляция
15.50 Автоспорт. Российская серия кольцевых гонок. Туринг. Прямая трансляция из Смоленска
16.55 Пляжный футбол. Белоруссия – Россия. Прямая трансляция
18.25 Бокс. Bare Knuckle FC. Алан Бельчер против Фрэнка Тейта. Трансляция из США 16+
19.25 Смешанные единоборства. UFC. Гловер Тейшейра против Иржи Прохазки. Валентина Шевченко против Тайлы Сантос. Трансляция из Сингапура 16+
21.00 Футбол. Суперкубок УЕФА. «Манчестер Юнайтед» (Англия) – «Зенит» (Россия) 0+
03.00 «Диалоги о рыбалке» 12+
03.25 Новости 0+
03.30 «Неизведанная хоккейная Россия» 12+
03.55 Автоспорт. Российская серия кольцевых гонок. Туринг. Трансляция из Смоленска 0+
05.05 «Несвободное падение. Борис Александров» 12+

НТВ

05.15 Павел Трубинер. «ВЫЗОВ» (S) 16+
06.45 «Центральное телевидение» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00 Сегодня
08.15 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу (S) 12+
10.00 Сегодня
10.20 «Первая передача» (S) 16+
11.00 «Чудо техники» (S) 12+
12.00 «Дачный ответ» (S) 0+
13.00 «НашПотребНадзор» (S) 16+
14.00 Своя игра (S) 0+
15.00, 16.20 Следствие вели... (S) 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Ты супер! 60+». Новый сезон (S) (6+
22.40 Борис Галкин. «ОТСТАВНИК. ОДИН ЗА ВСЕХ» (S) 16+
00.25 «ОТСТАВНИК. СПАСТИ ВРАГА» (S) 16+
02.05 «ШАМАН. НОВАЯ УГРОЗА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «НЕЗАБЫТАЯ» 16+
10.40 «ЛЮБОВЬ С АРОМАТОМ КОФЕ» 16+
14.30 «ГОЛОС АНГЕЛА» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК» 16+
22.50 «ЖЕНСКАЯ ИНТУИЦИЯ» 16+
00.55 «ГОРДОСТЬ И ПРЕДУБЕЖДЕНИЕ». 4-я – 6-я серии 16+
03.25 «ВЕЛИКОЛЕПНАЯ АНЖЕЛИКА» 16+
05.05 «Лаборатория любви» 16+
05.55 «6 кадров» 16+
06.25 «ОСТРОВА» 16+

ЗВЕЗДА

06.20 «ЯРОСЛАВ» 16+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.15 «СВАДЬБА С ПРИДАНЫМ» 12+
10.20 «ЛЮБИТЬ ПО-РУССКИ» 12+
13.15 «Мифы о России: вчера, сегодня, завтра». «Русская угроза» 12+
14.10 «Мифы о России: вчера, сегодня, завтра». «Немытая и пьющая Россия» 12+
15.05 «Мифы о России: вчера, сегодня, завтра». «Покорность и долготерпение русского народа» 12+
16.05 «Мифы о России: вчера, сегодня, завтра». «Русская отсталость» 12+
17.00 «Мифы о России: вчера, сегодня, завтра». «Тюрьма народов» 12+
18.15 Всероссийский вокальный конкурс «Новая звезда-2022». Финал 6+
20.50 «ЛЮБИТЬ ПО-РУССКИ-2» 16+
22.30 «ГУБЕРНАТОР. ЛЮБИТЬ ПО-РУССКИ-3» 16+
00.05 «Вещий Олег». Док. фильм 12+
01.30 «РУСЬ ИЗНАЧАЛЬНАЯ» 12+
03.50 «СВЕТЛЫЙ ПУТЬ» 12+
05.30 «Хроника Победы» 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 6 июнь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Марат Әмирхан. «Бибимәмдүдә». Моноспектакль. 1–2 нче өлешләр
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 7 июнь

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.20 «Вместе за безопасность»
18.30 Эстрада музыкасы концерты

Чәршәмбе, 8 июнь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 «Вместе за безопасность»
7.20 Туры элемтә
7.45 «Юлларчатында»
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
11.40 Прокуратура разъясняет
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Ренат Еникеев әсәрләре (тууына 85 ел)

Пәнҗешәмбе, 9 июнь

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 Илдар Юзеев шигырьләренә җырлар

Җомга, 10 июнь

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на чувашском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 «Дәшә безне Сабан туйлары!» Концерт

Шимбә, 11 июнь

8.10 «Котлы булсын Сабан туйлары!» Радиокомпозиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал. (Сабантуйлар – җанда якты уйлар!)
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Ренат Харис. «Узоры Сабантуя». Радиокомпозиция

Якшәмбе, 12 июнь

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты. (Сабантуйга багышлана)
13.10 «Татарстан дулкынында». «Егет Сабантуйда сынала». Әдәби-музыкаль композиция
15.10 «Тел күрке – сүз»
15.35, 16.10 Айгөл Әхмәтгалиева. «Туташ». Романнан өзек. 1–2 нче өлешләр

ЕРЫК АВЫЗ

Бензин кыйммәтләнүнең нигездә өч төрле сәбәбе бар:

1) нефть бәясе арткач, бензинның да хакы, билгеле, үсәргә тиеш;

2) нефть бәясе төшкәндә, нефтьчеләр, күргән зыянны каплар өчен, бензин бәяләрен арттырырга мәҗбүр;

3) нефть бәяләре үзгәрмәгәндә, бензин бәясенең артуы инфляциягә бәйле.

***

Ир:

– Бүтән болай була алмый! Аерылышабыз, дигәч, аерылышабыз!

Хатын:

– Юк инде, кадерлем. Тол килеш алдың, тол итеп калдырып китәрсең.

***

– Доктор, миндә дуңгыз гриппы түгел микән?

– Әлбәттә, дуңгыз гриппы. Иртәнге сәгать 4тә температура 36,8 булганда, «скорый» чакыртып китерү ул дуңгызлык кына булырга мөмкин.

***

– Күрәм, өйләнгәнсең икән.

– Каян белдең?

– Синең бөтен төймәләрең дә тагылган.

– Әйе, хатыным мине беренче көннән үк ямау ямарга һәм төймә тагарга өйрәтте.

АРМИЯГӘ ТҮГЕЛ ЭШКӘ

ӨТЕРНЕ ЕШРАК КАЯ КУЯЛАР?

Россия Конституциянең 59 маддәсендә әйтелгәнчә, Ватанны саклау – шушы ил гражданинының бурычы. Әмма бу изге бурычны парашюттан сикермичә, кулга мылтык тотмыйча, марш-бросок чапмыйча гына да кайтарырга мөмкин. Россиядә хәрби хезмәтне үтәүнең башка юлы бар. Ул – альтернатив гражданлык хезмәте. Анысы хәрби хезмәттән нәрсәсе белән аерыла? Мондый төр хезмәткә әләгү авырмы?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Каршы килмиләр

Татарстанда 2021 елда альтернатив хезмәткә 30 кеше алынган. Хәер, бу сан ел да шундый түгел. Чагыштыру өчен: 2018 елда бары тик 18 кеше генә андый хезмәт юлын сайлаган. Ил буенча ел саен меңләп ир-егет бу мөмкинлектән файдалана.

Санга карасаң, әлеге төр хезмәт популярлык казана дип әйтеп булмый шикелле. Барыбер дә егетләрнең шинель киеп карыйсы, «армиядә хезмәт иттем» дигән атлы буласы килә әле. Республиканың хәрби комиссары Сергей Погодинның да бу җәһәттән:

– Комиссариатлар альтернатив гражданлык хезмәтен узарга теләге булган яшьләргә каршылык күрсәтми. Нигездә, анда хезмәткәр табарга кыен булган, аз хезмәт хакы түләнгән һөнәр төрләре. Һәркем яшәү урыны буенча хәрби комиссар исеменә, чираттагы чакырылышка ярты ел кала, гариза тапшырырга хокуклы. Хәрби хезмәт узуның инануларына яки диненә каршы килүен расларган дәлилләр китерергә кирәк, – дип әйткәне бар.

Закон нигезендә Россиянең аз санлы халыклары саналган, традицион яшәү рәвеше һәм традицион хуҗалык эшчәнлеге алып барган затларга да альтернатив хезмәтне сайлау мөмкинлеге бирелә.

Кемнәр армиягә бармый?

Хәрби хезмәткә чакырылудан кичектерү түбәндәге затларга бирелә:

▶▶ әгәр ир-егет авыру туганының даими карауучысы саналса (закон буенча авыруны карарга тиешле башка затлар булмаган очракта);

▶▶ балигъ булмаган бертуган абыйсы яки апасының опекуны булып торса (башка затлар булмаган очракта);

▶▶ баласы булса һәм аны баланың анасыннан башка тәрбияләсә;

▶▶ ике һәм аннан да күбрәк баласы булса;

▶▶ өч яшькә кадәр инвалид балалары булса.

Хәрби хезмәткә чакырылудан азат итү мөмкин:

▶▶ сәламәтлегенә бәйле рәвештә хәрби хезмәткә яраклылыгы чикле дип табылган;

▶▶ хәрби хезмәт яки альтернатив гражданлык хезмәте узучы яисә инде узган зат;

▶▶ Россия халыкара килешүендә каралган очракларда хәрби хезмәтне башка дәүләттә узган кешеләр.

Күптән түгел Россия Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы альтернатив граждан хезмәтен узу өчен һөнәрләр исемлеген раслады. Исемлеккә 126 төрле һөнәр кергән (2021 елда – 124. – **Авт.**). Министрлык исемлек төзегәндә хезмәт базарындагы вазгыятьне дә исәпкә алырга тырышкан.

Шулай итеп 2022 елгы исемлек агрохимик, тынлы, халык уен кораллары һәм эстрада-симфоник оркестр артисты, тулай торакта тәрбияче, табиб-педиатр, теш табибы, концертмейстер, эпидемиолог кебек һөнәрләр белән тулыланды. Бик үзенчәлекле дип саналганнары да бар. Мәсәлән, болан караучы. Моңа өстәп курьер, аяк киемен ремонтлаучы, янгын сүндерүче, тәрбияче ярдәмчесе, торак пунктларны төзекләндерү буенча эшче, агач белән эшләү остасы кебекләре дә бар исемлектә.

– Кемдер – хәрби, ә кемдер галим, химик, инженер, артист, медицина вәкиле булыр өчен туган. Альтернатив гражданлык хезмәте хәрби хезмәткә чакырылу һәр егеткә үз юлын сайлау һәм тормышта үзләрен күрсәтү мөмкинлеге бирә. Мин мондый хезмәтнең уңай якларын гына күрәм, – дип саный бу уңайдан Россия Дәүләт Думасының Куркынычсызлык һәм ришвәтчелеккә каршы көрәш комитеты рәисе урынбасары, депутат Анатолий Выборный.

24 яшьлек Казан егете Наил дә (исеме үзгәртелде) – моннан берничә ел элек альтернатив хезмәт үткән кеше. «Армиядә бары тик махсус әзерлекле, чын профессиональ хәрбиләр генә хезмәт итәргә тиеш дип саныйм. Йә булмаса, килешү нигезендә. Шуңа альтернатив хезмәткә күчеп булмасмы дип гариза яздым. Комиссия минем гаризамны кире какмады. Мин почтальон булып хезмәт иттем. Эшемне намус белән, яратып башкардым, дип әйтә алам. Коллектив та шәп иде, бик ягымлы ханым-туташлар белән эшләдем. Алты көн эшләп, бер көн ял итә идем», – дип сөйләде ул.

Тарих битләреннән

1917 елның Октябрь революциясеннән соң Совет Россиясе, Бөекбритания һәм Дания белән беррәттән, үз гражданнарының намус күзлегеннән хәрби хезмәттән баш тартуга хокукын таныган беренче илләрнең берсе була. Әмма, вакыт узу белән, әлеге хокуктан файдалана алырдай затлар даирәсе шактый тарая. Ә 1939 елда, Икенче Бөтендөнья сугышы башлангач, СССРда альтернатив хезмәтне бөтенләй гамәлдән чыгаралар.

Андый мөмкинлекне яңадан торгызу турында СССР таркалганнан соң гына сөйләшә башлыйлар. 1993 елда, хәрби хезмәтне альтернатив гражданлык хезмәте белән алыштыру хокукы бар дип, акка кара белән язалар, ягъни бу хокукны Конституциядә ныгыталар. Шуннан башлап бу юнәлештәге законнар да даими рәвештә яңарып, һөнәр һәм белгечлекләр исемлеге дә өстәлеп тора.

Фикер

Евгений КАБЫШ, Әфганстандагы сугыш инвалидларының иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе:

Бәхеткә, армия хезмәтеннән качып калырга теләүчеләр саны азайды. Соңгы 10 ел белән чагыштырганда аеруча. Хәзер бер ел хезмәт итәләр, шартлар да, технологияләр дә, корал да – башка. Армия бөтенләй бүтән. Егетләрнең дә акыллылары, белемлеләре кирәк. Күпләр хезмәт юлын узганнан соң, килешү төзеп тә кала.

Альтернатив хезмәткә дә барысы да бара алмый бит. Аның билгеле бер кагыйдәләре, таләпләре бар. «Мин шулай телим» дип кенә булмый. Шартлары үтәлгәндә, нигезле булганда, альтернатив хезмәт мөмкинлеген хуплыйм. Андыйлар да бик кирәк.

Ватанга бурыч кайтару дигән сүз юк. Һәр ир-егет армиядә хезмәт итәргә һәм Ватанын сакларга тиеш ул. Соңгы арадагы вакыйгалар үз теләкләре белән хәрби хезмәткә алынучылар күплеген дә күрсәтте.

Хокукый нигезе

– Альтернатив хезмәткә әләгү – бик катлаулы эш, – дип кисәтә Казанның «Хәрби хезмәткә чакырылучылар хокукларын яклау» үзәге җитәкчесе, юрист Оксана Продан. – Иң элек, армиягә чакырылганчы, ярты ел кала (көзен чакырылыш 1 октябрьдән 31 декабрьгә кадәр, язын 1 апрельдән 15 июньгә кадәр уза. – **Авт.**) хәрби комиссариатка гариза бирергә кирәк. Тапшырылган гаризадагы дәлилләр шактый ышандырырлык булса да, хезмәткә алынырмын дип уйларга ашыкмагыз. Комиссия вәкилләре баш тартырга да мөмкин, чөнки урыннар саны чикле. Асылда, альтернатив хезмәт юлын сайлауның нигезендә дини яисә шәхси карашлар, инанулар ята. Әгәр кешенең дине кулга корал тотарга рөхсәт итми яки аның үзенең армиягә барырга теләге юк икән, ул төрле предприятиеләргә, социаль оешмаларга эшкә урнаша ала. Бу оешмаларның федераль яисә җирле хакимият канаты астында булуы мөһим.

Киез итек, шинель кию генә егеттән солдат ясамый шул әле. Асылда, альтернатив хезмәт – эшкә йөрү кебек. Аны җиңел дип уйлау да дөрес түгел. Шулай ук бу юлдан киткәннәрне армиядән качучылар дип санау да – ахмаклык. Мондый калыплашкан фикер безнең халыкта аеруча еш йөри. Ватан алдындагы бурычын берничек тә үтәмәүчеләр белән альтернатив хезмәтне сайлаучылар арасында аерма юк түгел.

Бу хезмәтнең үзенчәлекләрен барлыйк.

Альтернатив гражданлык хезмәте хәрби хезмәткә караганда ике тапкыр озаграк дәвам итә – 21 ай. Бу вакыт аралыгына өстәмә яллар, шул исәптән юлга киткән вакыт, эшкә килми калулар, шулай ук арест астында үткәрелгән вакыт керми.

Эш урынын хәрби комиссариат билгели. Эшне калдырырга яисә хезмәтне ташлап китәргә рөхсәт юк. Югыйсә җинаять җаваплылыгы яный (Россия Җинаять кодексының 328 маддәсе).

Хезмәткәр булгач, димәк, хезмәт хакы да түләнә, эш стажы да языла дигән сүз. Буш вакытта белем алу мөмкинлеген бирү дә тыймый. Альтернатив хезмәт юлын үтүче егет Ватан алдындагы бурычын Россия Хезмәт кодексы нигезендә кайтара. Ягъни хезмәткәр буларак, хокуклары да яклана дигән сүз. Закон нигезендә, аның эш вакыты атнасына 40 сәгатьтән артмаска тиеш. Калган вакытын ул ирекле файдалана.

Хәрби хезмәтне альтернатив гражданлык хезмәтенә алыштыру гаризасын нинди очракта кабул итмәскә мөмкиннәр? Бердән, гариза бирү вакытын бозган яки чакыру комиссиясенә ялган мәгълүматлар күрсәткән очракта. Сәбәпсез генә комиссия утырышына килмәгән өчен дә егетне сайлау хокукыннан мәхрүм итәргә мөмкиннәр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ҖИР КЕМГӘ КИРӘК?

Бүген авылның киләчәге турында кем иренми – шул сөйли. Авылда яшьләр калмавына бик борчылалар.

Күптән түгел Арчага кайтып, хакимият башлыгы Илшат Нуриев янына кереп, үзем дә шул турыда сүз кузгаткан идем. Миңа җавап итеп бер кызык сөйләде ул. Туган авылы Апазга кайткач, өлкән яшьтәге бер абзый белән авылның киләчәге турында сөйләшә башлаганнар болар. Теге абзый: «Илшат энем, бер дә борчылма, безнең Арча гомер-гомергә укымышлы булган. Кеше укымышлы булган саен югарырак үрмәли бит инде ул, аның шәһәргә китеп, тагын да укымышлы буласы килә», – дигән. Район башлыгы моны көлә-көлә сөйләде. Ә аннан соң: «Авылдан яшьләр китә, дип мин дә зарланып утырсам, ничек була инде ул? Җитәкче кеше зарланырга түгел, килеп туган һәр мәсьәләне чишү юлларын эзләргә тиеш», – диде.

Тынгысызлык нәтиҗәсе

Бүген Арчада 17 агрофирма, 67 крестьян-фермер хуҗалыгы, 12 меңгә якын шәхси ярдәмче хуҗалык бар. Район җыелган ашлык күләме буенча республикада беренче урында бара. Дөрес, бу чәчүлек мәйданының зур булуы белән дә бәйле. Әмма гектарыннан чыккан уңыш белән исәпләсәң дә, районның 10–12 нче урыннардан түбән төшкәне юк. Сөт җитештерү буенча – 7 нче урында. Кыскасы, Арча – авыл хуҗалыгы продукциясе белән үзен тулысынча тәэмин итүче, артыгын сатарга да хәленнән килгән район. Тик менә «әлеге дә баягы Сәрби әби таягы» дигәндәй, Илшат Габделфәрт улының барыннан да канәгать булып тынычлана йөргәнен күргәнем юк. Аңа һәрвакыт нидер җитми. Мин килер алдыннан гына Кукмарадан мәртәбәле киңәшмәдән кайткан булган. «Кукмара халкы җиргә якынрак кебек. Әле менә 24 баш сыерга кечкенә генә фермалар төзеп, шуны терлек карау хәленнән килгән гаиләләргә бирә башлаганнар. Безгә дә тотынасы булыр», – ди. Мин: «Бер ваклау, бер эреләндерү белән шөгыльләнүдән файда булыр микән?» – дип, бик белдекле кыяфәт белән сүз кыстырган булам. Ә ул: «Читтән карап утырудан да файда юк, иртәгә үк егетләрне җыеп киңәшмә үткәрәм әле», – ди. Үзе сәгатенә караштыргалый. Миңа бераз уңайсыз булып китте, чөнки Арчага җыенуымны әйткәч: «Мине күрәсе итсәң, иртәнге җидегә кил, ярты сәгать – кырык минут вакыт табарбыз», – дигән иде. Мин исә бераз иркенәеп киттем, ахрысы. «Ярый, кузгалдым алайса...» – дип урынымнан тора башладым. Ә ул: «Вакытың булса, районны урап кайт!» – дип озатып калды.

Әти тәрбиясе

«Районны урап кайтуда» минем юлдаш, гадәттә, район газетасында эшләүче Ильяс Фәттахов бит инде. «Глава»дан чыккач та аңа шалтыраттым, ә ул, киләсемне белгәнгә, мине редакциядә көтеп утыра икән инде. «Кая барабыз?» – диюгә, шундук: «Корайванга, әлбәттә», – дип, анда Фәнис атлы бик уңган егет яшәвен, крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчеләре арасында быел республикада җиңүче дип танылуын, Кукмарада узган киңәшмәдә диплом һәм 100 мең сум премия белән бүләкләнүен бер тында сөйләп тә бетерде.

Без килгәндә Фәнис Әхмәтханов тракторы белән тирес эттереп маташа иде. Кабинадан сикереп төште дә, ике куллап күрешеп, өйгә чәйгә чакырды. Чәй эчертү – татарның гасырлардан килгән матур гадәте. Җирдә эшләү, җирне ярату да мәңге бетмәс асыл сыйфатларыбызның берсе булыр кебек. Һәрхәлдә, үзем моңа ышанам.

Хакимият башлыгы Илшат Нуриев та заманында бүгенге Арча җирендә төрле халыклар яшәгәнен, тора-бара аларның җиңел тормыш эзләп кайсы кая таралып бетүен, бүген исә районда, нигездә, татарлар яшәвен сөйләгән иде. Ерак тарихка кагылганын, галимнәр әйтүенчә, дип сөйләде ул. Әмма, тегеләй борсаң да, болай итсәң дә, татарның җир кешесе булуы хак инде ул.

Әлбәттә, авыл тормышы оҗмах түгел. Фәнис әйтмешли, һәркемнең иртәнге дүрттән торып эшкә тотынасы килми һәм авылда эш кичке җиделәргә-сигезләргә хәтле тукталмый. Шуның өстенә авыл кешесенә ал да юк, ял да юк, бәйрәм көннәре дә юк. Кунып кайтырга берәр җиргә кунакка да чыгып китә алмыйсың. Шуңа күрә бүген дә авыл шактый кеше өчен сагынып кайту, җырларга салып моңлану өчен кирәк ул. Ә менә Фәнис калган. Хәер, калган, дип әйтү бик үк дөрес тә түгел. «Минем киткәнем дә юк, пропискам бер генә – Корайван. Мин – җир кешесе, әти шулай тәрбияләгән», – ди. Бишенче класстан көтү көтә башлаганын да өстәп куя.

Балачакта көтү көтмәгән авыл баласы

Ильяс Фәттахов

сирәк инде ул. Көтүче җитмәгәндә чират буенча авыл көтүе көтәргә дә туры килә иде. Әмма, партия чакыруларына җавап итеп, «класс белән авылда калу» дигәннәре булмады. Бүгенге авылга ул хәтле кеше кирәк тә түгелдер, бәлки. Бүгенге бер куәтле техника элекке унны алыштыра, йөзләгән сыерны бер кеше сава. Әмма Апаз авылы карты телгә алган акыллы кешеләр бүген авылга да кирәк. Кеше хезмәтен робот алыштыру заманына таба да барабыз бит әле.

Фәнис 60 баш терлек асрый, шуның 25е – савым сыерлары. Аларны Фәнискең хатыны Гүзәл сава. Балалары да кул астына керә башлаган. Өч егет үстерә Әхмәтхановлар. Олысы Сәйдәшкә 18 яшь, Тәтештә, колледжда, Фәнис әйтмешли, «МЧС»лыкка укый. Фәнис: "Уртанчысы – Кәрим җиденче класста», – дигән иде. Гүзәле: «Алтынчы класста», – дип төзәтеп куйды. «Менә балалар ишле булгач, ничә яшьтә икәннәрен дә белеп бетереп булмый», – дигән булам. Өченче уллары Инсаф беренче классны гына тәмамлый. Фәнис аны авылда калдырып булмасмы дип хыяллана. Татарда төпчек малайны әти нигезендә, авылда калдыру турында язылмаган закон бар. Бәлки, шул закон эшләп куймасмы тагын.

Тормышларыннан канәгать булуы Гүзәлнең йөзенә чыккан. «Шөкер, бөтен нәрсә бар, дөньялар тыныч булсын да шулай матур гына яшәргә язсын!» – дип кенә тора. Өйләре менә дигән, шәһәр фатирлары бер кырыйда торсын. Ванна бүлмәсе, бәдрәф өйдә, мунчага да өйдән генә кереп китәсе.

Фәнис, ир кеше буларак, бик егылып төшми инде, тормышыннан канәгать булса да, артык мактанмый. Аның җитәкчелеккә үпкә-дәгъвасы да бар әле: авыл кешесенә пенсия яше башкача булырга тиеш дип саный. «Авыл кешесе утыз ел эшләдеме – аңа пенсия бирергә кирәк. Ирләр 65 яшькә хәтле эшли аламы, хатын-кыз 60 яшькә хәтле сыер сава аламы? Юк! Җегәреннән килгәне эшләр дә үзе, әмма пенсиясе дә барса, яхшы булыр иде. Авыл өчен аерым законнар кирәк», – ди Фәнис. Моның ише тәкъдимне ишеткәнем юк иде әле. Пенсия мәсьәләсен хәл итү Татарстан җитәкчелегеннән генә тормый шул. Без инде күптән федераль законнар буенча яшибез. Хәтта моннан берничә ел элек Корайван авылының «Кер-хайван» дигән ямьсез исемен бүгенгесенә алыштырырга да Мәскәү рөхсәте кирәк булды.

Җирдә эшләүнең рәте

Гаилә фермасы оештырып маташкан берәү миңа: «Исәпләп-исәпләп карадым да, керемнәр чыгымнарны капларга гына җитә, табыш ваабше юк», – дип зарланган иде. Моны Фәнискә дә әйттем. Ул: «Димәк, әлеге егет җирдә эшләүнең рәтен белми. Җир бит ул – зур байлык, тарихка күз сал, бөтен дәүләтләр җир өчен сугышкан. Җир һәркемгә кирәк, әмма һәркем җиргә кирәк була алмый», – дип куйды. Гади генә итеп әйтелгән бу сүзләрдә авыл хезмәтенең асылы ята иде. Син җирне яратмасаң, җир дә сине яратмый.

Фәнис Әхмәтхановның 350 гектар җире бар. Терлек азыгы өчен печән, бөртекләләр чәчә ул анда. Көн саен 400 литр сөт сата. «Кая куйыйм?» – дип аптырап йөрисе юк, Арча сөт комбинатына илтәсе дә тапшырасы. Иң мөһиме, кулай, тотрыклы бәяләр булсын. Бездә, гадәттә, әнә шул тотрыклылык җитми. Бер чиктән икенче чиккә ташланып яшәү хас безгә. Бүген сөтнең литрын 31 сумга алалар. Шуны 400 литрга тапкырласаң, айлык кредитны, ягъни 130 мең сумны 10 көн эчендә каплап була. Фәниснең әле 35 баш сугымлык малы да бар. Айга бер үгез суя, үзеннән артып калган итне сата. Әле кош-корт та асрый. Аларның өстәлендә, үзе әйтмешли, бар ризык үзләренеке, «натуральный». Үз итеннән бер авылда колбаса да ясата. Кабып карадык та, вәт, ичмасам, чын колбаса, дип куйдык.

Фәниснең күңелендә дөге бөртеге хәтле дә өметсезлек юк. Авыллар бетү, кечәрәю турында сүз чыккач та: «Авылдан китәсе кеше элек тә киткән, хәзер дә китә. Каласы кеше элек тә калган, хәзер дә кала», – дип кенә куйды. Ә авыл хуҗалыгының бүгенге хәленнән канәгать Фәнис. Үз сүзләре белән әйтсәк, «Авыл хуҗалыгы хәзер барыбер әйбәт бара». «Кая барып чыгар бит!» – дип киресен сукалыйсы килеп киткән иде дә, дәшмәдем. Бары тик: «Фәнисләр булганда авыл яшәр», – дип кенә уйлап куйдым.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Сан



▶ Республикада **470** меңнән артыграк шәхси ярдәмче хуҗалык, **4** меңнән күбрәк фермер хуҗалыгы һәм **300**дән күбрәк куллану кооперативы эшли. Алар Татарстан авыл хуҗалыгы продукциясенең гомуми күләменең яртысыннан артыгын җитештерә.

▶ Ел саен кече хуҗалыкларга ярдәм итүгә грантлар һәм субсидияләр рәвешендә **2** миллиард сумнан артыграк акча бүлеп бирелә. **2016** елдан шәхси ярдәмче хуҗалыкларга дәүләт ярдәме турында республика законы гамәлдә.

▶ Быел агросәнәгать комплексына ярдәм итүгә тулаем **13,2** (узган елдагыга карата үсеш – **106,5%**) миллиард сум җибәрү күздә тотыла. Федераль үзәк катнашында барлыгы **5,3** миллиард сумлык **28** чара тормышка ашырылачак. Шулардан **3,8** миллиард сумы (**71,7%**) – федераль бюджет хисабына, **1,5** миллиард сумы (**28,3%**) – республика бюджеты хисабына. «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасын финанслауга **1,5** миллиард сум күздә тотылган.

▶ Агымдагы елга «Агростартап» программасы кысасында **160,4** миллион сум бүлеп бирелгән. Узган елда **60** җиңүче үз проектларын гамәлгә ашыру өчен **161** миллион сумлык ярдәм алды.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЯШӘТӘСЕ ИДЕ БАЛАНЫ!

Кукмарада яшәүче 10 яшьлек Регина Кәримуллинада сирәк очрый торган генетик авыру. Сабый тугач, икенче көнгә аның эче кабарып чыга. Табиблар эчәкләрендә нидер бар дип операция ясыйлар. Аннары башка хастаханәгә күчерәләр. Анда бала бер ай ята. Өйгә муковисцидоз дигән диагноз белән чыга. Гади тел белән әйткәндә, үпкәләр дөрес эшләми, какырык җыелып, бала аны үзе чыгара алмый. Моның өстенә тагын бер авыруы бар – Регинаның организмында бер фермент җитешми.

– Без баштарак кызыбызның авыру икәнен кешегә сиздермәдек. Бик читенсендек, – ди әтисе Илдар. – Табиблар, балагыз гомер буе дару белән яшәячәк, сезгә сабырлык һәм юлыгызда яхшы кешеләр очравын телибез, диделәр. Нишләргә дә белмәдек. Әле генә гаилә корып, кулыбызга алган беренче балабыз бит! Ничек кенә авыр булса да, хатыным Гөлнара белән бер-беребезне юатырлык сүзләр таба алдык. Үзебезнең бала, ничек тә тырышырбыз, дип яши башладык.

Кызын дәвалар өчен әтиләре икешәр эштә эшли. Елга ике тапкыр Регина әнисе белән Республика балалар клиник хастаханәсендә ятып чыгалар икән. Һәр иртә Регинага көчле дарулар белән ингаляция ясаудан башлана. Бер ел элек сабый организмына тагын бер вирус килеп керә. Сау-сәламәт кеше бу вируска каршы тора алса да, Регинага аны җиңәр өчен тагын бер дару өстәлә.

– Шул вирусны бетерергә дип 1 елга якын дарулар сулатабыз. Тик вирусның организмнан чыгасы килми. Үпкәләрдә генә түгел, тамагында да барлыкка килгән инде хәзер. Дарулы да кыйммәт әле. Бер айлык курс 100 мең сум тора. Аны интернет аша табабыз. Башка төбәкләрдә яшәүче шушындый авыру белән интеккән кешеләр үзләренең даруларын кайчак безгә сатып бирә. Башкача мөмкин дә түгел, – ди Илдар. – Бу дару Россиядә бушлай бирелә, Татарстанда юк. Кая гына бармадык инде. Рецепты кулда, даруы юк. Баланы тилмертеп булмый бит инде. Сатып алырга туры килә.

Регинаның какырык анализын ай саен Саратовка җибәреп торалар икән. Әмма әлегә аның нәтиҗәсе бер дә сөендерми. Үпкәләрне дәвалап булмый, бары тик бер юл – башка кешенекен күчереп утырту кала. Әмма сабыйлар операциягә чират көтеп өлгерми икән. Дөрес, вакытында дарулары булып торса, яшәрлек әле, ди Илдар.

Карап торышка Регинаны авыру бала дип тә булмый. Кечкенәдән интегүләр аны сабырлыкка өйрәткән. Башкалар кебек мәктәпкә дә йөри. Моңа кадәр аңа ярдәм кирәгән сыйныфташлары да, аларның әти-әниләре дә белмәгән. Кәримуллиннар гаиләсе, чарасызлыктан, серләрен чишәргә булган.

– Үзебез генә булдыра алмый башлагач, кешегә әйттек. Моңарчы туганнарыбыз ярдәм итте. Якын дуслар ташламады. Әле Регинаның авыруы турындагы хәбәрне интернетка куйганга бер тәүлек тә юк. Эшемә барырга да оялып торам. Әллә ничек, кешедән ярдәм сораудан да читене юк икән. Ир кеше буларак, кулдан килгәнне эшлим, тормышны үзем алып барам, – ди Илдар. – Безнең тагын ике балабыз үсә: Ралинә белән Әскәр. Аларны алып кайтыр алдыннан кат-кат тикшерендек. Карындагы балаларны да яхшылап карадылар. Курыкмадык инде. Аллага тапшырдык. Улыбызны да Регина кебек булырга мөмкин дип куркыткannар иде. Шөкер, алар сау-сәламәт. Бер генә теләк белән яшибез – Регинаны савыктырасы иде. Бөтенләй үк булмаса да, интегүләрен киметәсе иде баламның. Бер тәүлек эчендә инде акча салучылар бар. Аларның һәркайсына чиксез рәхмәтебезне җиткерәбез.

Кәримуллиннар гаиләсенә ярдәм итәргә теләүчеләр өчен исәп-хисап реквизитлары: Илдар Кәримуллин исемендәге Саклык банкы картасы да, Ак Барсныкы да **89393894705** телефон номерына беркетелгән.

Авырудан яман ялгызлык

Аның кебекләр кулын селтәр, тормышның авырлыкларына бирешеп, түбән тәгәрәр иде. Әмма ул үзендә яшәр көч таба. Ә бит моннан 15 ел элек булган фаҗига Зәйдә яшәүче Рамилнең тормышын икегә бүлә. 14 метр биеклектән егылып төшкәч, табиблар аны бернигә дә өметләндерми, йөри алмаячаксың, диләр. Үҗәтлек, тормышны ярату егетне аякка бастыра.

Рамилнең умырткасы, бот сөякләре сына. Башы каты бәрелә. Чәрдәкләнгән сөякләрдән аягын көчкә җыялар. Ул бер ел урын өстендә ята. «Хатыным бер минутка да янымнан китмәде. Мине баладай карады», – дип сөйли Рамил Бакиев.

Урында ятканда ул аякка басу турында хыялланырга да курка. Әмма Гатифәсенең җылы карашы, кадерләп тәрбияләве һәм табибларның ярдәме белән атлап китә.

– Бер ел урында ятканнан соң, аякка баскач, еладым да еладым. Шатлык яшьләре иде бу. Кабат йөрү бәхете биргән өчен Аллаһы Тәгаләгә чиксез рәхмәтле идем. Шул рәхмәт мине мәчеткә китерде дә инде, – дип искә ала Рамил. – Дингә килүемне хатыным да хуплады. Әкренләп гарәпчә укырга өйрәндем, намазга бастым. Гатифә белән изге Болгар җиренә барырга ярата идек.

Икәү бергә матур итеп йөрүләрен сагынып сөйләргә генә калган. Ике ел элек Гатифәсен югалта ул. 46 яшендә хатыны үлеп китә.

– Гатифәмнең күзләре начаррак күрә иде. Без аның белән гел бергә булдык. Кешеләр, әллә сез туганмы, бер-берегезгә бик охшагансыз, диләр иде. Күпме генә теләсәк тә, балабыз булмады. Ялгызыма бик читен. Хатынымны уйламаган көнем юк. Өйдә ялгыз гына калсам, елыйм да елыйм. Күңелемә тынычлыкны мәчеттә генә табам, – ди ул. – Анда бар

борчуым онытыла. Кизү дә торам. Дога укытырга килгән кешеләрнең зарларын тыңлап, аларны юатам. Кешегә җылы сүзләр таба алсам да, аларны тыңлап, үз йөрәк яраларым кузгала.

2020 елда Гатифәсе кинәт авырый башлый. Хәлсезләнә, ашаудан кала. Аяклары йөрмәскә әйләнә. Ире аны Зәй хастаханәсенә сала. Табиблар коронавирус диагнозы куя. Ул шуннан тернәкләнә алмый... «Бик матур яшәдек, – ди Рамил. – Әле дә хатынымның бер киемнә тимәдем. Аларны кадерләп саклыйм...»

Хәзер ул үзенә шөгыль дә тапкан. Гатифәсе элек тараклар ясый торган була. Шул эшне өйрәнгән. Әнә шулай күңеленә юаныч таба.

ВТ

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

Оештыручылар – «Ватаным Татарстан» газетасы, Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте

Үзегез яшәгән җирлектәге имамнар, аларның күркәм хезмәтләре турында «Ватаным Татарстан» газетасына «бәйге» дигән тамга белән язмалар юллый аласыз.

Бәйгедә өч урын билгеләнәчәк. Аларны бүләкләү түбәндәгечә:
I урын – 10 мең сум;
II урын – 7 мең сум;
III урын – 5әр мең сум күләмендә ике премия.
Бер җиңүчегә Татарстан Диния нәзарәтеннән 10 мең сум күләмендә махсус премия тапшырылачак.

Бәйгенең төп иганәчесе – Яшел Үзән районының Бакырчы авылыннан Бәхтияровлар гаиләсе.

БӘЙГЕНЕҢ ШАРТЛАРЫ:
«Безнең авыл имамы» бәйгесенә язмалар 2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 10 июленә кадәр кабул ителә. Нигезләмә белән **www.vatantat.ru** сайтында танышырга мөмкин. Бәйгегә башка матбугат чараларында басылган язмалар кабул ителми. Язма күләме басма форматта 3 биттән (юл арасы – 1,5 интервал) артмаска тиеш.

Материаллар 420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт адресы буенча яки **konkurs_vt@mail.ru** электрон почтасына кабул ителә һәм кире кайтарылмый. Хатта авторның исем-фамилиясе, яше, торган урыны күрсәтелергә тиеш. **Белешмә өчен телефон: (843) 222-09-70, 8 917-927-00-40.** Бәйгедә катнашучының 2022 елның икенче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына язылган булуы шарт, квитанция күчермәсе редакциягә язма белән бергә җибәрелә. (Исегезгә төшерәбез: һәр айның 15 нче числосына кадәр язылган очракта газета киләсе айдан килә башлый.)

Бәйгенең нигезләмәсе, тулырак мәгълүмат www.vatantat.ru сайтында.
2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 1 августына кадәр дәвам итә.
Оештыручысы – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Реклама. 16+

ФИРАЯ ӘКБӘРОВА:
«КАРТАЙМЫШ КӨНЕМДӘ ЧӘЧӘК АТТЫМ»

Сәхнәдән нур чәчкәнгә, каршыңа гел елмаеп килеп чыкканга, аның эчендә ни ятканын берничек тә белеп булмый. Характерлы рольләр остасы, тамашачының сөйкемле сөяге – Татарстанның халык артисты Фирая ӘКБӘРОВА әнә шундый. Бүген без аның рольләренә бәя бирмибез, хатын-кыз буларак ачабыз. Сәхнә нинди корбан таләп итә? Артистның гаиләсе нинди сынаулар аша уза? Тук артист моңлы була аламы? Әнә шундый сорауларга җавап эзләдек.

:: Фирая апа, театр ул сезнең өчен нәрсә?

– Бөтен булмышым, шатлыгым, кайгым, табышларым, кайчакта югалтуларым да. Монда минем гомерем уза. Дусларым, якыннарым да биредә. Ә бит театрдан китеп торган вакытым да булды. Ирем, я мин, я театр, дигән шарт куйгач, гаиләмнең бөтенлеген сайлаган идем. Иң авыр вакыт әнә шул булды. Бер елдан соң Марсель Сәлимҗановның, театрга кайтса, кире алам, дигән сүзен җиткерделәр. Йөгерә-йөгерә кире кайттым. Ник дигәндә, театр ул – гомерлек чир. Бер йоктырдыңмы, аннан котылып булмый. Мин яшьләргә, театр артисты кияүгә бала белән чыга, дип тә әйтәм. Чөнки театр ул – синең ияреп килгән балаң. Булачак ирең шуны кабул итсә, тормышың әйбәт була. Әгәр юк икән инде...

:: Әгәр бала икән, театр атлы балагыз газиз балаларыгызга тиешле игътибарны үзенә күбрәк алмадымы?

– Ничек кенә ала әле! Театр ул – бик көнчел бала. Яратуыңны башка кешеләр белән бүлешүне яратмый. Әгәр бүлешәсең икән инде, үчләшергә дә күп сорап тормый. Бер интервьюда ике улымның ничек үскәнен дә хәтерләмим дип тә әйткән идем, балаларым шуңа бик озак төрттерделәр. Әни безнең ничек үскәнне хәтерләми дә, белми дә ул, дип үчеклиләр иде. Шаяртып әйткән сүз булса да, аның нигезендә хаклык ята. Баштарак үзең белән юлда йөртәсең, аннары исәя төшкәч, өйдә үзләрен генә калдырасың. Бигрәк тә театр каршында оешкан балалар студиясендә эшли башлагач хәлләр катлауланды. Өлкән бала спорт белән шөгыльләнә, ә кечкенә улым үз иркендә калды. Без Казанның яңа районнарының берсендә яшәдек. Кечкенә улымның мәктәбе гади, алга китеп шунысын да әйтик: сыйныфтагы 18 баланың берничәсе генә тормышта үз урынын таба алды. Олы улым, әни, болай барса, без Данияны югалтабыз бит, диде беркөнне. Шуннан соң андагы 3 бүлмәле фатирны үзәктәге 2 бүлмәлегә алмаштырдым. Инде балаларга күз-колак булып була. Эштән бушаган арада өйгә кайтып киләм, мәктәптән соң балалар да еш кына театрга киләләр иде. Шөкер, икесе дә акыллы, тәртипле булып үстеләр. Хәзер икесе дә гаиләле, миңа оныкларны сөю бәхетен дә бүләк иттеләр.

:: Әлфия Авзалова, тук кеше җырчы була алмый, аннан моң чыкмый, дигән. Яшьтән үк бер кыерчык икмәккә тилмергән артистларның да рольләре моңлы була, димме...

– Артист тук булырга тиеш түгел дигәнне бездән башка да белүчеләр бар бугай инде (*көлә*). Әлфия апа чыннан да хаклы. Биографиясе булган, тормышның ачысын да, төчесен дә татыган кешенең тавышы моңлы була, тамашачыга әйтер фикере дә саллы аның. Андый артистны тулы савытка охшатып була: бүген ул тамашачысын бер йотым шатлыктан авыз иттерә, иртәгә гыйбрәтен әзерләп куя. Өлкән буын артистларны кара: тормыш күргән кешенең энергетикасы нинди! Чыгып басу белән сәхнәне тутыра бит ул! Гомумән, артисттан да тырыш халык юктыр ул дөньяда. Үзләрен гел яңа яктан сынап карый, алып баручы булып китә, укытучылык һөнәрен үзләштерә, тагын әллә нәрсәләр... Шунсыз дөнья алып барып булмый.

:: Әнигә үпкә саклап буламы?

– Юк, билгеле. Әни бит ул, синең аңа кыек караш ташларга да хакың юк! Әти белән әни аерылганда миңа нибары ике ай булган. Биш яшемә кадәр мине әтинең әнисе – дәү әни үстергән. Аңа рәхмәттән башка сүзем юк. Әйтик, менә миңа ике айлык бала калдырып киттеләр ди, нишләр идем, ничек үстерер идем? Юк, мин булдыра алмас идем. Ә ул мине яратты. Әгәр аның яратуы булмаса, анда уздырган биш ел гомеремдә әтинең биш тапкыр өйләнүен гади бер хәл кебегрәк кабул итмәгән дә булыр идем, мөгаен. Сабый шул инде... Ә дәү әни бик кызык кеше иде ул. Әле хәзер дә йомшак ястыгы, тәм-томнар сакланган, ачкыч белән бикләнә торган сандыгы күз алдында. Әтиләр өйдә булганда, әби гел авырый, аның әле бер төше, әле икенчесе тота. Ул гел ятып тора. Әтинең чыгып китүе була, әби сикереп тора, йөгереп самавырын куя, тегә сандыктан җимешләр, тагын әллә нинди тәм-томнар чыга, баздан каймакны алып менә дә без бик тәмләп чәй эчәбез. Әтиләр кайтыр вакыт җитәрәк, барысын да үз урынына урнаштыра да тагын ястыгына ухылдап барып ята.

:: Әти яклавына кызыгып үскәнсездер.

– Минем бик тә әтиле буласым килә иде. «Нигә минем әти юк?» – дип елаганым да истә. Әтием белән бик озак еллар аралашмадык. Әнинең аны минем алда ямьманлавы күңелгә кечкенәдән сеңеп калган, күрәсең, аннан читләшә, кача идем. Авылга кайткач, әтиең бигрәк әйбәт кеше, дип әйтсәләр, ышанмый идем. Бигрәк матур җырлый, дисәләр дә, әллә ни кызыксынмадым. Әти белән аралаша башлаганда, минем ике балам бар иде инде. Буләккә күлмәк тә алган идем, тапшырырга өлгермәдем. Әти бакыйлыкка күчте. Әле аралаша башлагач та, аралар якынаеп китә алмады. Ул да миннән уңайсызлана, мин дә читенсенә идем.

Әтинең башка балалары да бар. Зәйтүнә апаны ул ике мәртәбә алды, аннан өч баласы бар. Наил исемлесе белән аралаштык, ул да минем шикелле ачык иде. Ләкин ул да бакыйлыкта шул инде. Ул гаиләдән кызлары гына исән...

Яшәгән саен үземдә әти белән уртак якларны күбрәк табам. Җырлау, сәнгатькә тартылу да шуннан түгелме икән? Хәер, әнием дә бик матур җырлый иде. Холык та әтидәндер дип уйлыйм. Әнине исә тормыш шулкадәр кыйнаган, ул кешеләргә ышанмады. Кешеләргә ачылып бетмә, синең проблемаң кемгә кирәк, көләрләр генә, дип өйрәтте. Аның хаклыгына яши-яши төшендем. Минем проблема – ул минеке генә. Аны миннән башка беркем дә хәл итмәячәк. Әни – сак кеше, бөтен нәрсәне бик сагаеп кабул итте. Ирем белән аерылышам дигәч тә, сагаеп калды: «Алай итмә инде, әнисе дә ир белән яши алмады, кызы да, диярләр», – диде. Мин исә: «Ярар, әни, бер ай сөйләрләр, ике, өч, ярты ел – бер туярлар әле. Унҗиде ел дүрт кешелек арбаны берүзем тарттым, җитәр инде», – дип җавап бирдем. Ирем театр дигән үги баламны башта ук кабул итмәде шул, бәлки яшәп тә киткән булыр идек. Аерылышуның инициаторы олы улым булды. «Аерыл, әни, әгәр инде кыерсытылып яшәү ошый икән, яшә, ләкин миңа башка зарланма», – диде. Аерылам, дигәч тә бер ел яшәдем әле, аннары араны өздек инде. Әйтүе генә җиңел, аерылу – бик авыр ул.

:: Ә менә Асия Хәйруллина кебек данлыклы апаң булу җаваплылыкмы?

– Бик зур җаваплылык! Мин аның йөзенә кызыллык китермәдем дип уйлыйм. Дөрес, ул мине әллә ни күреп, сынап өлгермәде. Ә менә ире Халит абый (театр тәнкыйтьчесе Халит Кумысников. – **Ред.**) мине яратып кабул итте, рольләремне югары бәяләп, берничә мәкалә дә язды. Асия апа да кабул иткәндер дип уйлыйм. Әмма безнең туганнар сикереп төшеп мактый торганнардан түгел. Алар артык ачылып та китми, шатлыкны да, кайгыны да сабыр кабул итә. Ә театрга барам дигәч, Асия апа хупламады. Сабыр гына, сеңлем, төс-кыяфәтең героиняларныкы түгел, рольсез утырырсың бит, диде. Миңа героинялар төс түгел, әмма характерлы рольләрнең бетеп торганы юк.

Асия апаны да аңлыйм. Ник дигәндә, үзем дә – балаларыма, театр дип авыз ачмагыз, дип әйтеп куйган кеше. Тамашачы бит һөнәрнең матур ягын гына күрә. Күпме тир, күпме күз яше түгелгәнен артист үзе генә белә. Аннан килеп, артист калын тиреле түгел. Ул сүзләргә бик сизгер, хәтта караштан да нидер сизеп ала, борчыла, бөргәләнә башлый. Белә торып ничек инде туганыңны яки балаңны шулардан сакламыйсың ди...

:: Фирая апа, без – сезнең «Ромашкалар» җырын тыңлап үскән буын. Җырларыгыз тансык, әмма сирәк ишетелә. Үзегезне җырчы-артистка буларак ачылып бетмәгән артистка дип санамыйсызмы?

– Бердән, җырлы рольләр бик булмады. Аннан килеп, мин үземне җырчы дип санамыйм. Җыр минем балачакта ук еракка яшереп куйган сыйфатларымны тышка чыгарырга ярдәм итә. Шуңа тиз җырлар башкара алмыйм, миңа моңлы җырлар булсын. Күрәсең, иркенлек кирәктер. Шунысы кызык: җырлый башлавым театрга кирәк булыйм дигән теләктән булды. Рольләр юк чак иде, театр артистлары концертларында катнашыр өчен Фоат абый Әбүбәкеров белән репетиция ясап карадык. Шуннан китте инде. Рольләр күбрәк булса, җырламаган да булыр идем. Миннән: «Ник хәзер дә җырламыйсың?» – дип тә сорыйлар. Шәхсән үзем яше барган юан гына апаларның сәхнәгә чыгып мәхәббәт турында җырлауларын берничек тә кабул итә алмыйм. Оялам хәтта. Бигрәк тә селкенә башласалар, карый алмыйм. Үземнең дә шулай булуымны теләмәгәнгә җырламыйм. Чөнки минем ватан турында, авыл турында җырларым юк. Һәр нәрсәнең үз вакыты була. Дөрес, тагын бер дисклык җырларым бар, ләкин аны хәзер кем чыгара инде?.. Ә теге дискны бүләк иткәндә, кешеләргә, елыйсыгыз килгәндә тыңларсыз, дип әйтеп бирәм. Җырлары шундый аның.

:: Театр дигән балага унар ел рольсез утыртканы өчен үпкә сакламыйсызмы?

– Яшьлектә, көч-дәрман булганда рольсез утыру бик авыр. Мин аны Марсель абыйга да әйтә идем. Ул исә: «Син минем запас юлдагы бронепоезд», – дип җавап кайтарды. Һич кенә дә аңламый идем шушы җавабын. Берсендә, тутыга бит инде запастагы бронепоезд, дип тә карадым. Күрәсең, ул минем язмышны бик дөрес чамалаган булган. Яшь чакта чандыр гәүдәле булгач, малайларны, кызларны уйнадым. Аннары олыракларны уйный башладым. Бик җиңел күчтем аңа. Күпчелек артистлар картаймас борын әбиләрне уйнауны бик авыр кичерә, минем алай булмады. Әби образында шулкадәр популярлашып киттем, бик еш кына, Фирая апа, безгә әби кирәк иде, дип шалтыраталар. Театр тулы әби ләбаса, дисәм дә, сез кирәк, диләр. Ул реклама өчен дә, клип өчен дә, фильмнарга да. Картаймыш көнемдә чәчәк аттым. Әби ролендә.

:: Равил Шәрәфиев, алтмышта ул самый уйнар чак, дип әйтергә ярата. Сезнең дә иң бәрәкәтле чорда икенче сулыш ачылды, фильмнарда берсеннән-берсе кызыклы образларны башкардыгыз. Иң истә калган фильм кайсы булды?

– Фильмнарда үземне, гомумән, карый алмыйм. «Рәхәт яшибез» сериалын алыйк. Үземне бөтенләй ошатмадым.

Ичмасам бертуган апам, «Көтелмәгән кунак» фильмын карагач: «Карале, бөтенесе дә матур, нигә син шулкадәр ямьсез соң?» – дип әйтеп куйды. Шул да җитә калды. Күпмедер вакыт узгач кына «Рәхәт яшибез»не карый алдым. Дөрес, җитешмәгән яклары да бар, ә тулаем алганда, начар хезмәт түгел. Ул безнең сериал төшерүдә беренче чирканчык иде. Ахырга таба җаен да таптык, ләкин дәвамы булмады. Әмма безгә бик зур мәктәп булды. «Бер-бер хәл» фильмында мин бөтенләй үземә охшамаганмын. Истә калганы дип анысын әйтергә дә була. Холкым буенча мин шыр, ә анда җитди. Бик авыр булды, билгеле. Әмма бу образ мине кирәкле сыйфатларга баетты. Һәр роль – артист өчен гыйбрәт ул. Әйтик, киленнәр белән мөнәсәбәтләрне яңадан карарга мәҗбүр итте. Яшерен-батырын түгел, бер киленем белән бер-беребезгә бик авыр ияләштек. Җавап бирсәм, минем дә телем бик ачы, әмма олы кеше сабыр булырга тиеш. Хәзер, шөкер, бер-беребезне бик яхшы аңлыйбыз. Баштагы мәлләрдә талашып китсәк, яшь гаилә белән ни булып бетәр иде? Яшь вакытта үзебез дә өйрәткәнне, тормышка кысылганны яратмадык лабаса.

:: Һәр гаиләнең кадерле ядкәре була. Сездә ул нәрсә?

– Дәү әнинең кулмәген, чиккән сөлгеләрен кадерләп саклыйм. Чулпыларым бар. Иремнең әтисенең медале саклана. Кадерле көмеш кашык та бар… Аларның һәркайсы белән гомеремнең ниндидер бер сәхифәсе бәйләнгән. Менә шул көмеш кашык – дәү әтинең энесе Закир бабайныкы. Мин аны матур бабай дип тә йөртә идем. Биш яшемдә әни мине Казанга алып килгәч, аларда яшәдек. Приказчик булып эшләгән бабайның йорты да ике катлы. Чөнки үзе хезмәт иткән бай вафатыннан соң, аның тол хатынына өйләнгән һәм байның байлыклары аңа калган. Андагы матур шәмаилләр, борынгы китаплар, үзе бер сәнгать әсәре булып тоелган шкафлар, зур көзге!.. Бабай кырысрак иде, әмма сорап килгән бер кешене дә кире бормады. Безне дә әни белән үзенә прискага кертте. Ә бу – ул чактагы иң четерекле мәсьәләләрнең берсе. Мине үзендә калдырырга рөхсәт итте итүен, әмма күрмим дә, ишетмим дә үзен, диде. Шуңа күрә ул өйдә булганда бүлмәмнән чыкмый идем. Елау, чабышу турында әйткән дә юк. Ул тарихи йорт хәзерге Курчак театры урынында, аны сүттеләр инде. Хәер, сүтелгәнче үк мөлкәте пыран-заран килде. Абыстай вафатыннан соң матур бабай яшь хатын алды да, анысы йортны заманча җиһазлады. Шәп җиһазлар чүплеккә очты, китаплар юкка чыкты, өй пычкы чүбеннән ясалган заманча мебель белән тулды. Бу хәлләр башланганда, әни нидер чамалап, бабайның үги кызыннан бер көмеш кашыкны истәлеккә сорап алды.

> Безнең нәсел – һөнәрчеләр нәселе. Без барыбыз да куллы кешеләр, шөкер. Шуңа күрә нәрсәнең бәһасез икәнен тиз чамалыйбыз. Сүз уңаеннан, миндә дә кул эшенә маһирлык бар. Әмма аңа илһам кирәк. Бу арада илһам килми әле.

:: Киләчәккә нинди планнар корып куйдыгыз? Үзегезне сынап карамаган тагын нинди өлкә калды?

– Шуны эшләргә кирәк дип ниятләп куйган эшләр бар, анысын алдан кычкырмыйк әле. Чөнки кызыксынучан кеше мин. Артист һөнәрен сайлагач, башкача булырга мөмкин дә түгелдер инде ул. Шул кызыксынучанлык аркасында кино өлкәсенә кереп киттем. Юкса бит фотога төшә белмим, тамашачы килеп, бергә төшик әле дисә, карточкагызны бозасыгыз килсә, минем белән төшегез, дип әйтәм. Әмма кеше үземә тартыла. Тәҗрибәләр ясатам. Кайчак аларның ахыры хәерле дә булмый, ләкин бит аны сынап карамыйча белә алмыйсың.

:: Кеше миңа тартыла, дисез. Ә нишләп алайса яңадан кияүгә чыкмадыгыз?

– Үземне яхшы белгәнгә андый адымга бармадым. Холык начар минем. Кешегә җайлашам, үз мәнфәгатьләремне иң арткы планга куям. Аннары шуның өчен ул кешене дә, үземне дә яратмый башлыйм. Кибеткә керсәм дә, һаман да үземә әйбер ала алмыйм. Башта якыннарны кайгыртам. Ә бу дөрес түгел. Чөнки мин әни белән генә яшәдем һәм ир-ат белән ничек яшәргә икәнен күреп үсмәдем. Шуңа күрә балаларга да, әтиле кызларга өйләнергә тырышыгыз, дип әйттем.

:: Туган көнне яратасызмы?

– Менә быел яратмый башладым әле. Яшь саны ошап җитми бугай. Аннары ияләшермен инде. Ә болай, шаушулы мәҗлесләрне яратмыйм. Ялгыз калып ял итәргә яратам. Бу балачакта күргәннәр тәэсиредер инде. Мин, чәчрәп чыгып, үз хокукларымны даулый торган кеше түгел. Сәхнә әнә шул йомылып яшәп туйганнан соң ачылу урыны булганга якындыр миңа.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

МАРАТ ӘМИРХАНОВ

ШӘҺРЕ БАНУ

< Ахыры. Башы 12, 20, 27 май саннарында

* * *

Даирәнең үз арасында да Болгардагы бу үзгәрешләрне кабул итмәүчеләр, үз мәнфәгатьләрен алга сөрүчеләр бар икән.

Мәҗлестә Ибне Фазлан Исегел әмире белән дә аралашып алган иде. Тәхет тотуына ике-өч кенә ел икән әле. Яшь, чибәр, күрекле углан.

Ибне Фазлан аны бәйрәм белән котлады.

– Мин бик рәхмәтлемен, – диде Әмир, – без, барсил кабиләсе иярченнәре, мәшһүр барс-җанварга табынабыз. Һәм ата-бабаларыбыз рухына тугрылыклы булып калачакбыз да.

– Исегел Болгар дәүләте вилаяте түгелме соң? – дип җилкәсен сикертеп куйды Ибне Фазлан.

– Әйе, – диде әмир касәсен җулпычтай киң учлары арасында әйләндергәли-әйләндергәли, – киләчәктә дә бергә булачакбыз, аркадаш булып, бер-беребезгә терәк булып яшәячәкбез. Ә менә кайбер мөселман әмирлекләре, белүемчә, башка чыгу сәясәтен алга сөрә.

– Мәсәлән?

– Мәсәлән, Суар…

Әңгәмә шушы урында өзелде. Әйтерсең лә, әңгәмәне ишетеп-тыңлап торган, озын торыклы, какча гәүдәле Суар әмире Вираг бәк үзе яннарына килеп сәлам бирде.

– Әссәламегаләйкүм, мөхтәрәм илче. Ходай хәерле гомер, мәртәбәле эш-гамәлләр насыйп итсен! – дип билен бөкте.

– Вәгаләйкүмәссәлам, хөрмәтле әмир. Үзегез дә иң изге теләкләремне кабул итегез.

Исегел әмир аларның икесен генә калдырып, китеп барды.

– Сезгә йомышым бар иде, – диде Вираг әмир, – мөмкинме?

– Бик рәхәтләнеп, әмир.

– Болгар дәүләтендә ике җәмигъ мәчете булырга тиеш, дип саныйм, – диде әмир, – берсе – Биләрдә, икенчесе – Суарда. Безнең мәчетебез бар, тик аны җәмигъ мәчете таләпләренә туры китереп, киңәйтү зарур. Шушы уңайдан мин сезне Суарга чакырам, барысын да үз күзләрегез белән күрерсез.

Исегел әмирнең суарлыларның башка чыгу омтылышы турындагы гайбәткә тартым сүзләре Ибне Фазлан күңелендә зур кызыксыну уяткан иде. Чакыруны бик теләп кабул итте.

– Бик хуш, тик бераз соңрак, – диде. – Чиратта – Кызлар каласы.

– Рәхмәт, өметләребез акланыр, дип ышанам.

Ибне Фазлан, әлбәттә, әүвәл мәгълүмат туплады.

Дөрестән дә, Исегел әмиренең сүзләрендә хаклык бар икән. Суарлыларның мөстәкыйльлеккә тартылуы берәүгә дә сер түгел, диделәр. Үз акчаларын сугу хәстәрен дә күрәләр, имеш. Бу инде – башка чыгудан битәр, аерылып чыгу омтылышы дигән сүз.

Алай да ул, Суарда йөреп кайтканнан соң, Вираг әмирнең Болгар дәүләтендә ике җәмигъ мәчете булдыру турындагы тәкъдимен хуплавын белдерде. Кала бу ташламага лаек иде. Матди ярдәм күрсәтү мөмкинлеген дә таптылар.

Шулай, Багдад өчен яңа мәчетләр төзү, ислам диненең колачын киңәйтү халыкларның үзара тынышу-тынышмауларыннан өстен иде.

Тарихи белешмә:

«Бүре башын табакка салсаң да, урманга карар» дигән мәкаль, әйтерсең лә, суарларга атап чыгарылган. Суар әмирлеге тартыша торгач, барыбер Болгардан аерылып чыга һәм утыз алты ел (940–976) мөстәкыйль дәүләт буларак яшәп ала. Габдулла ибне Микаил, Талиб ибне Әхмәд хакимнәр исеменнән Суар акчасы да сугыла. Әйтергә кирәк, әлеге акчалар киң таралыш таба, археологлар аларга ерак Дания җирләрендә дә тап булалар.

* * *

Җәгъфәр падишаһ ямьле җәй көннәрендә үзенең гаиләсе һәм якыннары белән матур табигать кочагында, балыклы су буйларында ял итәргә ярата иде. Бу хозурда еш кына даирә дә катнаша. Даирә бергә җыела икән, димәк, бу инде – гомумдәүләти чара.

Июнь аеның соңгы атнасына билгеләнгән мәҗлес тә көн үзәгендәге бик зарури мәсьәләләрне күздә тотып ниятләнгән иде.

– Бисмилла иррахман ирахим, җәмәгать, Багдад илчелегенең Болгарда булып китүенә бер ел тулды, инде бу игелекле сәяхәтнең тәүге нәтиҗәләре турында фикер алышырга вакыт җитте, – дип башлады сүзен илтәбәр, – шулай да, ошбу сөйләшүне башкалабызны яңача кору, бигрәк тә Җәмигъ мәчетен пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең туган көне, Мәүлид бәйрәменә өлгертү хәлләренең торышына багышласак, тагын да урынлырак булыр.

– Афәрин!

– Бик мәгъкуль, падишаһ!

– Бик хуш, алайса, иң элек Биләр бистәсенең баш кешесе Туйгуҗа бәкне тыңлап үтик, аннан…

– Падишаһ, гафу, падишаһ, – дип, Бану бикә урыныннан торып басты, – миңа иравыл яугирәләрем янына китәргә рөхсәт итсәң иде, әллә нигә күңелем урынында түгел, чәршәмбе – бакырбашларның тышаудан ычкына торган көне, Аллаһ, сакланганны гына саклармын, дигән, ул-бу була күрмәсен, димен…

– Яугирәләрдән тыш та сак ишле бүген, бикә, – диде Җәгъфәр, – борчылырга урын юк.

Илтәбәр сүзе арасына, бака ботын кыстыргандай, башка берәү кереп тыгылган булса, үзенең кем икәнлеген күрсәтер иде, әлбәттә, тик мәмләкәтнең күз өстендә каш булып саналган олы абруй иясе Бану бикәне атасы Силки мәлик кебек үк үзе дә бик ихтирам итә иде. Шуңа күрә сак кәсәфәтендә чамасы чамага туры килеп бетмәсә дә, калын иреннәрен кыйшайтыбрак елмайгандай итте дә:

– Көне дә матур күренә, бар, бикә, җилләнеп кайт, – диде.

Бикәнең күңеле исә бүген, киресенчә, матурлыклардан ерак тора иде, киселгән эпекәй кебек җәрәхәтле иде аның күңеле.

Хәләле Ярмәк угланны югалткан кайгылы вакытлардагы кебек төне буе саташып-бастырылып чыкты. Башта Айтулы кыз белән төшләнде. Ләкин ул күрергә күнеккән «Айтулыга тиң булырмы йирдә адәм баласы» тасвирламасына якын да килми иде. Чәче-башы тузган, йөзе чалшайган, тешләре ыржаюлы…

Акай күзләрен уйнаткалап, коры сөяккә калган куллары белән аның муенына чытырмандай ябышты да:

– Әйдә, мин сине үз дөньяма алып китәм… китәм… китәм… – дип, сулкылдый-сулкылдый янавын белде…

Ә аннан соң яшьлегендәге упкын төбенә мәтәлгән толпары пәйда булды.

– Алаяк, син исәнмени, Алаяк?!

Ә Алаякның күзләр тонган, тону гынамы, вәлфәҗер укый. Чабуы чабу түгел, көндәш кәҗә тәкәседәй арт сынын сикертеп килде дә тибеп тә җибәрде.

– Гоп!

Шунда гына күзләре ачылды. Карап бакса, өстәл өстендәге сулы чүлмәкне башына аударган икән.

Ул юеш урын-җирен читкә этәреп куйды да тышка чыкты.

Таң сызылып килә иде инде. Гадәттә, таң пакьтән-пакь алсу челтәрләр япмасын нурландырып ярала иде. Бүген исә офык читенә томан дисәң, томан түгел, болыт сәләмәсе дисәң, болыт сәләмәсенә охшамаган ниндидер карасу-саргылт ябышкак боламык сыланган иде.

Кояш шул ябышкак боламык кочагыннан котылырга тырыша: тетрәнә, дерелди, суккалана…

Тартыша торгач, ниһаять, урак сыртын күрсәтеп алды, бәгырь. Тора-бара тулышты да. Тик, ни гаҗәп, гүя кырлач кояшы ике колаклы иде.

Якында гына яшелле-зәңгәрле килешсез тавышы белән күңелгә шом салып чыңгырау торна кычкыра. Үзе бии, үзе кычкыра. Ә бу – фаҗигале фал. Ник дисәң, чыңгырау торна таптаган урында үлән дә үсми.

Көн әнә шулай туарга теләмичә генә туды.

Бу хәлләр тикмәгә түгел, дигән нәтиҗә чыгарды Бану, итәк-җиңнәрне җыебрак йөрү мәслихәт булыр.

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»нан ай саен бер бүләк

1 ЯЗЫЛ!
2022 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына язып

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ЖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘК ОТ!
30 июньгә кадәр газетага язылучылар арасында **ТАНДЫР** уйнатабыз

6–16 июньгә кадәр газетага ташламалы бәядән язылып була!

П2435
җомга саны
423 сум 48 тиен
гадәти бәясе – ~~488 сум 10 тиен~~

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
942 сум 18 тиен
гадәти бәясе – ~~1099 сум 32 тиен~~

Май ае өчен бүләк 9 июнь көнне уйнатылачак, квитанцияләр 8 июньгә кадәр кабул ителә. Июнь ае бүләге – тандыр. Квитанцияләр 5 июльгә кадәр кабул ителә. 7 июль көнне уйнатыла.

Акция 2022 елның 29 апреленнән башлап 17 июлена хәтле дәвам итә. Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Тулырак: vatantat.ru 16+

Реклама

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕЛӘРЕ

Тандырда пешкән ризык тәмле һәм затлы! Иң күп сайлау мөмкинлеге – «Тандыр 24» кибетендә. Сезнең барлык сорауларыгызга җавап бирерләр.

«Тандыр 24», ТР, Казан шәһәре, Зәкиев урамы, 4 нче й., сул канат, 2 нче кат

тел.: +7-917-919-80-01

Реклама

Корыч казаннар, әфган казаннары, мангал, казаннар өчен мичләр. Безнең кибеттә табигатьтә ризык әзерләү өчен бөтен төр товарлар да бар.

тел.: +7-905-020-00-39

«Мир казанов 116», ТР, Казан шәһәре, Җиңү проспекты, 100 нче й., элмә тактасы – «ЭКОМАРКЕТ»

Реклама



Рәис Габдулла

27 май санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: Мәмәшир, хорафат, крона, драм, Ана, Ольга, дүдәк, ифрат, кәкшү, литавра, иганә, аеру, Йосыпов, Ита, Зинин. **Вертикаль буенча:** кси, йөз, Рәүфә, Клаксон, Мөхәммәтшин, үтә, пин, Марк, пот, Арал, Фива, Ван, шифоньер, ре, Гана, авар, рута, Ает.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Беренче басма татарча китап ничәнче елда нәшер ителә?
А) 1801;
Б) 1917;
В) 1556.

2 Зиннәт Моратов – ул...
А) Камал театры бинасы архитекторы;
Б) опера җырчысы;
В) 1943 елда КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре.

3 Бу елны Мәскәү университетына нигез салына.
А) 1800;
Б) 1755;
В) 1945.

4 Россиянең империя булып танылган елы.
А) 1917;
Б) 1700;
В) 1721.

Җаваплар: 1) А; 2) В; 3) Б; 4) В.

ТӨЗЕЛЕШ һӘМ РЕМОНТ БРИГАДАСЫ

барлык төрдәге төзелеш эшләрен башкара

ЯЗГЫ ТАШЛАМАЛАР

Үзебезнең яки заказчының материалын кулланабыз.

Коймалар, терраса, фундамент, сайдинг, түбә эшләре, мунча, беседка, хуҗалык корылмалары, өй күтәрү, бүрәнәләрне алыштыру, отмостка, борыс имитациясе эшләре.

Өйләрне блок-хаус белән тышлау эшләре һ.б.

Пенсионерларга 15-20% ташлама!

Мөрәҗәгать иткән көнне үк килəбез!

тел.: 8 968 618 37 78, 8 905 199 99 79

Реклама

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 16016 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 277

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+